PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 ДЕКАБРЬ № 12

Сөембикә

ISSN 0869-1398

БАЙЛЫК УРЫНЫНА – БӘХЕТ

кем нәрсә сайлый

АП-АК КАРЛАР ЯВА

бу – шагыйрь кышы

ШЕФ-ПОВАР ИЛЬЯ ФРОЛОВ СЫЙЛЫЙ:

Яңа ел торты

Альбина АСЫЛГӘРӘЕВА:

– ҺӘРКАЙСЫБЫЗ АТЛЫЙ ХЫЯЛ АРТЫННАН...



PRESSA.RU

2017

ГЫЙНВАР

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

ФЕВРАЛЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	
П	2	9	16	23	
Җ	3	10	17	24	
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

МАРТ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	31
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

АПРЕЛЬ

Д		3	10	17	24
С		4	11	18	25
Ч		5	12	19	26
П		6	13	20	27
Җ		7	14	21	28
Ш	1	8	15	22	29
Я	2	9	16	23	30

МАЙ

Д	1	8	15	22	29
С	2	9	16	23	30
Ч	3	10	17	24	31
П	4	11	18	25	
Җ	5	12	19	26	
Ш	6	13	20	27	
Я	7	14	21	28	

ИЮНЬ

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	
Я	4	11	18	25	



Намазлык чигешенең фрагменты. Луиза Фәсхетдинова эше.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мљхђррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәмматова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Альбина Асылгәрәева
Фото: Нуршат Әсхәдуллин

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 9.12.2016 ел.
Заказ М-3214.
Тираж 5535.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77


Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU







Ленар ШӘЕХ

Яңа ел җыры




Бит кызарткан уйнак җилдән
Яңа ел исе килә.
Җилләр белән, җилләр белән
Бергә биисе килә!

Яуган кар бөртекләренә
Яңа ел төсе керә.
Бәйрәм безгә, бәйрәм безгә
Ак бәхетләр китерә!

Нидер көткән, өмет иткән
Йөрәк шашынып тибә.
Якты җиргә, якты җиргә
Күкләр мәхәббәт сибә!














Илсөяр ИКСАНОВА

* * *

Тагын бер ел үтте.
Тагын бер ел
Китеп бара,
күчә тарихка –
Шатлык-көенечләр,
мәшәкатьләр,
Иске дуслар, яңа танышлар.

Бары да үтә...
Кала җанда Сөю
Һәм... соклану кала Дөньяга.
Күпме сулар эчмә,
гомер кичмә,
Бу дөнья көн дә өр-яңа.

Сокландыра,
Моңландыра кайчак.
Уйландыра.
Сала утларга.
Кабатлана еллар,
фасыл, айлар,
Тик... һәр көне аның өр-яңа.



Яңа еллар килә...
Яңа еллар
Нинди булыр,
Ниләр күрсәтер?
Яхшыга тик юрыйк,
Исән булыйк.
Өзелмәсен өмет
һәм хәтер!










Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





18

ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ АСЫЛЫ БАР...
Г. Сафиуллина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8

ЯТИМНӘРГӘ ӘНИ УЛ!
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





22

«ТЫҢЛАГЫЗ, ТАЛЛИН СӨЙЛИ!»
Э. Закирова



14

ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ ВАХТА
Г. Сафиуллина

МӘДӘНИ ТОРМЫШ





26

ЯЗУЧЫ – МИЛЛӘТ ИЛЧЕСЕ
А. Юнысова



ЭЧТӘЛЕК



30 ЯҢА ЕЛНЫҢ ЯҢА КАРЫ
Ф. Дәүләтгәрәева

ЯШӘЕШ 

36 КҮК ТҮБӘЛӘР БИЕК ҺАМАН...
Ф. Хатипов





38 БӘХЕТКӘ АЛЫШКАН БАЙЛЫК
Л. Гәрәева

ШУЛАЙ УК: 

44 БӘБИ ЯЛЫНДА – ЭШТӘ
С. Гаффарова

50 МУКАМ САРАЕНДА...
Р. Кашапова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

58 ЯҢА ЕЛ ТОРТЫ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

СТЮАРДЕССА ЧУЛПАН. БЕЗНЕҢ КАВЕМ.

ФИРҮЗӘ ҖАМАЛЕТДИНОВА. «ОФЫК АРЪЯГЫ БОЛЫТЛАП ТОРА...»

РЕНАТ ИБРАҺИМОВ: «ХАТЫН-КЫЗ ИР-АТ КАБЫРГАСЫННАН ЯРАТЫЛГАН».

ЛӘЙСӘН МӘХМҮТОВАДАН – МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Адәм баласына бирелгән гомер бик кыска кебек. Ләкин үткән тормыш юлларына әйләнеп карасаң, аларның үтә дә катлаулы, озын булуын күрерсең.

Әнием Нурмөхәммәтова Миңлебану 1926 елның 26 декабрендә Чүпрәле районы Яңа Кәкерле авылында Сәнәтулла белән Фәхрибану гаиләсендә дөньяга килә.

«Безнең авыл зур иде – 760 йорт. Һәр гаиләдә унлап бала. Биш балалы гаиләләр ишлеләр рәтенә керми дә торган иде», – дип искә ала ул. Әбиемнәр гаиләсендә дә бер-бер артлы биш кыз бала туа.

Әнием җидееллык мәктәпне гел «бишле»гә тәмамлый. Ләкин «укытучы булам», дип канатланып йөргән кызның хыяллары кинәт кенә чәлпәрәмә килә. Шул елны сугыш башлана. Бабамны да беренче көнне үк фронтка алып китәләр, алгы сафка ут эченә җибәрәләр. 1941 елда ул каты яралардан вафат була. Фәхрибану әбием берсеннән-берсе кечкенә биш кыз баласы белән тол кала.

Аны «ирең сугышта һәлак булды, балаларың яшь, бер кызың дөм сукыр (икенче кызы 3 яшендә чәчәк авыруыннан сукырая)», дип тормыйлар, сыер асрарга хәлең бар, әйдә, колхоз эшенә, дип, элек ирләр башкарган хезмәткә алып китәләр. Шуның өстенә заем, налоглар да түлисе... Балаларны карау 14 яшьлек әнием җилкәсенә төшә. Бу вакытта инде ул мәктәптә укуын тәмамлап килә. Кызның булдыклылыгын күргән мәктәп директоры аны укытучылар әзерли торган кыска сроклы курсларга җибәрмәкче була. Ләкин тормышта берникди терәге калмаган әбием, балаларымны кем карый, дип, каршы төшә. Хәер, әгәр дә аның «кешеләргә аң-белем тарату» теләге тормышка ашмаган дисәк, бу бик үк дөрес тә булмас иде. Әнием бүген дә авыл халкы арасында: якты дөньяга килүчеләрне каршы ала, бакыйлыкка китүчеләрне озатып кала, авыл халкының кайгысы да, шатлыгы да аны читләтеп үтми. «Син бит дин тыелган заманда яшәгән кеше, бу белем каян килде?» – дип сораучыларга, әнисе Фәхрибануның балаларына төннәр буе дин сабагы өйрәтеп ятуын сөйли. Әнием ягыннан әбиемнең туганнары Төке авылыннан – муллалар нәселеннән. Бу нәселнең ир-егетләре инкыйлабта халыкка аң-белем тараткан, әбинең туган апасы исә кызлар укыткан. Әбием бик укымышлы кеше иде шул. Коръәнне яттан сөйләп чыга торган иде. Мисыр мәкаме белән укыган догалары әле дә исемдә.

Әниемә, кайгырып, эшсез утырырга туры килми. Аның математика белән дуслыгын искә алып, хисапчы итеп билгелиләр. Сабыйлыктан чыгып җитмәгән кыз бала иртәдән алып кичкә кадәр колхоз эшендә кайный, шуның өстенә ул сеңелләрен дә ашатып, тәрбияләп торырга тиеш була.

Сугыш тәмамлангач, авылга бер-бер артлы ир-егетләр кайта башлый. Инде күп кенә хатын-кызлар авыр йөкне ирләре җилкәсенә күчерә. Бары әниемнәр йортында гына барысы да искечә кала.

Ләкин тормыш алга барудан туктамый, ул үз агымы белән кеше язмышына ниндидер яңалыклар, һич көтелмәгән үзгәрешләр алып килә. Фронттан кайткан Нурмөхәммәт исемле егет, бер-ике шаярып сөйләшү белән, әниемне үзләренә килен итеп алып китә. Араларында мәхәббәт булганмы-юкмы, анысын белмим, ләкин алар гомер буе бер-берсенә тугрылык саклап, тугыз бала тәрбияләп үстереп, авыл халкы арасында хөрмәт казанып яшәгән кешеләр. Әти мәрхүм (сугыш яраларыннан озак еллар сыкрап яшәде, шул әрнүләр белән үлеп тә китте) бик кызу кеше иде; әни, киресенчә, сабыр, бер сүзен дә уйламыйча сөйләмәс, ләкин әйтсә, һәркем төшенерлек итеп, кабат бу мәсьәләгә әйләнеп кайтмаслык итеп аңлатып әйтер. Күршебез Мөбарәкҗан абыйның: «Синең әниең кебекләр сирәк була, аңа һәйкәл куярга кирәк», – дигән сүзләре авылдашларның аңа карата хөрмәтле мөнәсәбәтен күрсәтә. Әниемнең тагын бер матур сыйфаты – ул бездә әтигә карата олы хөрмәт уята белде. «Әтиегез кайта, тавышланмагыз», «Әтиегез белсә, нәрсә әйтермен?» Бу сүзләрдән, әти белсә нәрсә буласын без уйлап бетерми идек, әлбәттә, ләкин «әти» дигән кодрәтле, бөек көч каршында сак булырга кирәклеген аңлый идек.

Кешенең бәхете олыгайган көнен ничек үткәрүе белән билгеләнә, диләр. Фәхрибану әбинең намазниязлы нигезендә догалы мизгелгә туры килеп тугангамы, гомере буе башкаларга изгелек кылгангамы,

артык эшчән булгангамы, әллә инде кешеләрне яратkангамы (ә бу, чыннан да, шулай) әнием чын-чынлап бәхетле язмышлы кеше. Алай да үткәннәрне барларга яратмаган әниемне 90 яшен тутырган көннәрдә бик нык борчып торган бер әйбер бар. Ул – буш өйләр, корыган нигезләр. «Төннәр буе уйлап ятам, безнең урам буенча гына да фәлән кадәр йорт иде. Ә хәзер юклы-барлы биш-алты йорт. Анда да яшьләр юк. Быел беренче сыйныфка бары бер бала барган. Авыл бетә», – дип пошына авылның иң өлкән кешесе.

Еш кына әнием – мәктәптә укыган елларында төшкән рәсемендәге кебек мөлаем, сабыр карашлы, матур йөзле, калын кара чәчләрен икегә бүлеп, толымлап үргән кыз булып күз алдыма килә. Әнә ул (инде без үскәндә) тәрәзәне ике якка ачып куйган да, ярты гәүдәсе белән урамга сузылып, күрше апа белән нидер сөйләшә, шул арада шукланып йөргән энемә, йомшак кына итеп: «Сикермә, аягыңны авырттырырсың», – дип әйтеп куя. Гомере буе ягып та җылынмый торган авыл кибетендә эшләп, кышкы салкыннан күгәреп беткән куллары белән халыкка ризык үлчәп сата. Безне олы юлга озатканда, иң авыр сумканы ала да, җәһәт-җәһәт атлап китә, шунда ук: «Син, кызым, үзең дә беләсең инде», – дип, җайлап кына киңәшләрен бирергә дә онытмый. Күңелгә якын, җылы мизгелләр... Әнә шулар арасыннан билдән узган кара чәчен ике толымга үреп салган, башына ак яулык бәйләгән әнием сурәте янә калкып чыга.

Ак яулыклы әниемнәр буыны белән тулы бер чор артта кала... Олы яшьтәгеләр, гадәттә, «үтте-китте гомер», дип уфтанып утырырга, аһзарларын сөйләргә яраталар. Ул исә «хәлең ничек, әнием», дигән сорауга «яхшы», дип (мин аның начар дигәнен белмим), кыска гына җавап бирә дә, үзенең якын арада башкарган эшләрен, авылдагы яңалыкларны сөйләп китә...

Җае чыккан саен аның 8 баласы (берсе мәрхүм), 19 оныгы, 17 торыны туган нигезгә кайталар. Ә без, әниемнең балалары, үз чиратыбызда, җир йөзендә кеше булып яши белгәне өчен, 9 балага гомер биреп, тәрбияләп үстергәне өчен аңа олы рәхмәтебезне белдерәбез! Әниебез, сине Олы юбилееӊ белән котлыйбыз, сиңа сәламәтлек, тыныч, бәхетле көннәр, ике дөньяның рәхәтен телибез!

Әлфинур НӘҖИПОВА-ЗИННӘТУЛЛИНА.
Казан.

Шомланып, уянып киттем. Уянуымның сәбәбе дә юк сыман. Тормышымда бар да яхшы, гомер көземә кереп барганда әдәби иҗат белән янып йөрим.

Үзбәкстанда үткән балачагым, Гөлшат абыстайдан ишеткән Тукай шигырьләре искә төште. Тагын хәтеремдә калганы – аңлаешсыз, ләкин үтә дә моңлы авазлар – Коръән аятьләре. Намаз укыганда, янына утырып, тын гына тыңлый идем әбиемне. Ташкент хатын-кызлары арасында Гөлшат абыстай Коръән укуы белән аерылып торды. Ирләре сугышта булган хатын-кызлар еш килә иде аңа. Мине иң кызыктырганы алар алып килгән күчтәнәчләр иде. Шулардан авыз итү өчен самавыр куям, чәй ясыйм. Әби мине тырышлыгым өчен бик ярата иде. Әнием – аның кызы – укытучы буларак та, партия оешмасы секретаре буларак та өйдә бик аз була иде. Әтине исә, фронттан кайткач, 7 яшемнән генә хәтерлим.

1945 елда мине менә 70 ел буена әзәрлекләп килүче бер вакыйга булды. Сентябрь төне. Бер бүлмәдә гаиләбез белән йоклап ятабыз. Икенче бүлмәдә «эвакуированныйлар» яши. Төн уртасында уянып китеп, торып утырдым – бүлмә ишегеннән миңа кемдер карап тора. Караңгылык эчендә ул яктырып күренә, йөзендә елмаю. Бу җан иясе, бармагын ирене тирәсенә китерүгә, кычкырып җибәрдем: «Әни, ишектә кеше басып тора!» Өйдәгеләр сикерешеп тордылар. Әни «коптилканы» кабызып, ишеккә таба атлады. Ә теге кеше, миңа тагын бер елмайды да, юкка чыкты. Ул югалгач, мин елап җибәрдем. Әти, мине юатырга теләп, ишектәге ачкычны борып, коридорга алып чыкты. Анда беркем дә юк иде. Иртән алар бу хәлне минем саташуыма сылтады. Әби генә колагыма пышылдады: «Ул синең фәрештәң иде... улым!»

Ул елларда атеизм көчле иде. Әнием, коммунист буларак, шул идеяне алга сөрсә дә, күңелендә Аллаһка ышану яшәде. Әмма ул моны беркемгә дә сиздермәде.

Инсульт булып, башта госпитальдә, аннары өйдә дәваланганда тагын бер серле вакыйга булды – балачакта күргән теге серле зат тагын пәйда булып, ишек кысасына басты да, өч кенә сүз әйтте: «Бар да яхшы булыр». Өч-дүрт көннән үземдә яшәрлек көч-куәт тойдым.

Әбием 86 яшендә дөнья куйды. Ул вакытта мин Баренц диңгезендәге су асты көймәсендә хезмәт итә идем (1967 ел). Мине әбиемне җирләргә җибәрмәделәр. Хезмәтемнең иң авыр мизгелләрендә миңа гел фәрештәм ярдәм итте.

Сугыш елларында шәһәребездә Анна Ахматова яшәде. Әтинең сеңлесе Мәскәү университетын тәмамлап кына кайткан вакыт. Анна Андреевнага дуслары күчтәнәч җибәргән. Аны тапшырырга барганда, мин дә иярдем. Шунда шагыйрә кулын башыма куеп: «Ой какой рыжик!» – дигән иде. Шул рәвешле әдәби иҗатка фатиха биргәндер, мөгаен.

Гөлшат әбием 75 яшем тулганда төшемә керде. Яныма килде дә: «Сиксән алты», – диде. Шуның кадәр генә яшисең, диюе булса, күп калмады инде, 9 елдан 86 тула.

Фәрештәмнең иң зур игелеге – тормыш юлдашым Гөлчәчәгем белән очраштыруы. Олыгаеп барганда гына булса да «Татар дөньясы» газетасы редакторы Ринат Мөхәммәдиев, шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Валентин Сорокин, Людмила Щипахиналар белән танышу да насыйп булды миңа.

Әхәт МӨХӘММӘТОВ.
Мәскәү.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

БУ ЙОРТТА ЧЫН МӘГЪНӘСЕНДӘ ГАИЛӘ АТМОСФЕРАСЫ: БЕР-БЕРЕҢНЕ ЯРАТУ, КАЙГЫРТУ, ХӨРМӘТЛӘҮ СИЗЕЛЕП ТОРА.





Мәдинә АВЗАЛОВА

ЯТИМНӘРГӘ ӘНИ УЛ!

Утыз ел гомерен ятимнәр тәрбияләүгә багышлаган, караучысыз-яклаучысыз калган шул сабыйлар өчен әти дә, әни дә булган җитәкче ханымга: «Ә кирәкме соң ул балалар йорты?» дигән сорау биреп тормадым. Әнә бит кирәклеген ул үзе сөйләп тора. Әлегә кирәк. Чөнки әлегә җәмгыятебез ул йортларсыз яшәргә әзер түгел. «Баланың бу йорттан чыгып китеп, инде үз тормышы белән яши башлагач та, кайтып керер җире, «минеке» дип, атлап керер бусагасы булырга тиеш. Безнекеләр шулай итә. Уйламаганда гына кайтып керәләр дә бөтен дөньябызны шау китереп йөриләр. Кочаклашып елашып та алабыз шунда...» Һәр җөмләсен Аллаһы Тәгалә исеме белән башлаган Рузалия Хәбибулла кызы ВӘЛИУЛЛИНА шулай ди. Биредән чыгып китеп, зур һәм тынгысыз тормыш юлына аяк баскан егет һәм кызлар өчен ул гомергә кадерле һәм якын кешеләрнең берсе булып калыр.

Балага әни кирәк!

Ерак-еракларга җәелеп аккан Кама елгасыннан кул сузымында гына урнашкан Лаеш балалар йорты үзенә чал тарихы белән генә тартмый. Бер карауга ук тышкы һәм эчке кыяфәте ялт итеп торган әлеге йортта тәрбияләнүчеләр турында «ятимнәр» дип әйтергә тел әйләнми. Кайсы киң-йомшак диванга утырып телевизор караган, кайсы компьютер белән мәш килгән, ә кайсы төрле бизәкләр уйнаклап торган ял итү бүлмәсендә психолог белән шөгыльләнгән бала-чаганың үз-үзен тотышына караганда, берсе дә өйләрен, әниләрен сагынып елап утыра сыман тоелмый. «Сагыналар... – ди, уйларымны укыгандай җитәкче, – без аларга нинди генә шартлар тудырмыйк, балага әни кирәк. Әнисез булмый». Барысы җиткән, барысы да булган, бер уйласаң. Ә әни кирәк!

Заманында безнең илдә балалар йортлары булмаска тиеш. Бала гаиләдә яшәргә тиеш, дип мин дә күп яз-











дым. Гаиләдә, димәк, чит гаиләдә түгел, үз гаиләсендә, үз әти-әнисе янында... Һичьюгы тәрбиягә алган гаиләләрдә. Ятим, вакытлыча әти-әни вазыйфасына алынган тәрбиячеләренә ул изге сүзне әйтмәсә дә, гаилә учагының – әнигә булышуның, өй эшләренең ни икәнлеген күреп-белеп үсә. Мин тиктомалдан китермим бу мисалны. Казаннан бик читтә урнашкан нефть районнарының берсендәге балалар йорты тәрбиячесенең: «Алар бит бәрәңге дә әрчи белмиләр», – дип әйткәне әле дә хәтердә. Ә гаиләдә үскән бала, бигрәк тә кыз бала ашына, пәрәмәченә кадәр пешерә. Дәүләт тәрбиягә алучы гаиләләр өчен барын эшли. Бала өчен аена шактый гына күләмдә акча түләнә. Бер уйлаганда, ул акчаларны чит гаиләгә әрәм иткәнче, баланың үз гаиләсенә бирсәң, эчкече әнисен дәваласаң, әтисен эшкә урнаштырсаң, күпкә файдалы һәм дөрес булыр иде. Бертуктаусыз гаилә кыйммәтләре турында сөйлибез түгелме?!

Шулай. Республикада соңгы вакытта бу юнәлештә эзлекле һәм нәтиҗәле эшләр алып барыла барылуын. «Аеклык ноктасы» программасын гына алыйк. Бу – мөһимнән-мөһим проблема. Елына 45 әнине айнытсаң гына да күпме бала гаиләдә кала дигән сүз. Ләкин янә илдә барган хәлләрне күз алдына китергәндә, күлдәге бер тамчы гына ул. Минемчә, җирлекләрдәге опека һәм иганәчелек бүлеге хезмәткәрләре үзләренә беркетелгән гаиләләрдәге вазгыятьне, үзара мөнәсәбәтләрне гаилә таркала башлаганчы ук күреп алырга, кичекмәстән, чарасын күрергә тиеш. Үзегез беләсез, эчүгә сабышкан әнигә беркем дә, берни дә кирәкми.

Россия Президенты Владимир Путин: «Үз баласын яклый алмаган җәмгыятьнең иртәгәсе дә, киләчәге дә юк».

Җиңүчеләр тәрбияли

«Балага балалар йортында рәхәтме-юкмы, бирedә ул үзен уңай хис итәме-юкмы икәнлеге күпне күргән сабыйның мәгънәле йөзеннән беленә. Аның хәл-хәятен чырае, килеш-килбәте үк күрсәтеп тора», – ди Рузалия Хәбибулловна. Ул җитәкләгән коллектив, чыннан да, башкаларга биргесез. Аның балаларга инклюзив тәрбия бирү тәҗрибәсе дә бар. Балалар әллә чыннан да барысы да сәләтле, әллә тәрбиячеләр аларны шундый итә: һәркайсы түгәрәкләргә, спорт секцияләренә йөри, район, республика, Бөтенроссия бәйгеләрендә, олимпиадаларда катнаша, җиңү яулый. Коридорда стена буйлап тезелеп киткән төрле дәрәҗәдәге дипломнар, Мактау кәгазьләре, спорт ярышларыннан алып кайткан кубоклар шул хакта сөйли. Начар күрүче балалар исә дзюдо буенча Россия беренчелегендә һәм чемпионатларында призлы урыннар алган. Балага кайда яхшы, кайда начар булуын әнә шул күрсәткечләр сөйли инде!

Белгәнебезчә, бүген ятимнәрне гаиләләргә бирү формасы өстенлек итә. Ләкин биредә сак булырга, артыгын тырышып ташларга ярамый. Чамасын белү

PRESSA.RU

кирәк. Балалар йортларын ябу очраклары да бар хәзер. Әмма эш күрсәтү өчен генә балаларны тизрәк гаиләләргә тарату димәгән. «Алсыннар гына» принцибы балалар йортларына икеләтә мәшәкатьләр белән әйләнеп кайта. Ә кире кагылган баланың кичерешләре турында әйтеп тә тормыйм. Аңа бер хыянәт иттеләр ич инде, хәзер менә тагын «кирәкми» диләр. Мәче баласын да теләсә кемгә бирмибез, әйбәт хуҗаларга гына... Шул рәвешле, социаль ятимлек проблемасы уңышлы хәл ителгән сыман тоела. Чынында алай түгел. Миңа калса, балалар йортларын ябып кына ятим балалар проблемасы хәл ителми. Социаль ятимлекнең сәбәпләрен ачыкларга кирәк биредә. Тормышлар кыенлашкан саен, авыр хәлдә калган балаларның саны арта бара. Татарстанның Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау, Сәламәтлек саклау, Мәгариф һәм фән министрлыклары әлеге проблема белән бик күптәннән шөгыльләнә. Җыеп әйткәндә, ятимнәрнең язмышы шушы өч министрлык кулында.

«Мәче баласын да яхшы кулларга тапшырырга тырышабыз. Ә бала ул мәче баласы түгел».

«Балалар яхшы гаиләгә эләксә, бик куанам», – ди Рузалия Вәлиуллина.

Кызганыч, ләкин сабыйларны кире кайтару очраклары да бар. Кайберләрен хәтта икешәр мәртәбә кайтаралар. Бусы инде, минемчә, тәрбиячеләрнең, уллыкка-кызлыкка алу үзәкләренең булачак әти-әниләр белән җитәрлек һәм тиешле эш алып бармавы нәтиҗәсе. Кайбер ата-ана баланы ел буе күзәтә. Өенә алып кайта, гаилә шартларына күнектерә. Шуннан соң гына катгый бер карарга килә. Шулай диюгә, җитәкче гыйбрәтле бер хәлне искә төшереп ала: «Бервакыт шулай абыйлы-энеле ике баланы алып килделәр. Чирләп торгач, килүгә үк аларны хастаханәгә салдык. Эзләренә үк басып, уллыкка алу үзәгеннән бер әни килеп җитте. «Балалар кая, алып китәм», – ди. Сез аларны күрмәдегез дә бит әле. Бәлкем ошатмассыз. Хастаханәгә барыгыз, танышыгыз башта, дип карыйм. «Минем алай итеп йөрергә вакытым юк», – дип кырт кисә әни кеше. Район башлыгына кадәр барып җитте. Бирмәдем балаларны. Нинди әни чыксын андый кешедән? Район җитәкчесе әйткән шул чагында: «Директор тәҗрибәле кеше. Ул үз эшен белә», – дип. Шулай да була.

«Яратмагач ник алдыгыз?»

Сүз үзеннән-үзе ятимнәрне тәрбиягә алган гаиләләргә барып тоташа. 2002 елны балалар йортында тәрбияләнүче бер малайны төзелеш институтына әзерли башлыйлар. Институтка керер өчен дизайн мәктәбендә шөгыльләнгәне турында документ кирәк икән. Шул вакыт Рузалия Вәлиуллина бу малайга репетитор яллый. Егет әйбәт кенә дәрескә йөри башлый. Репетитор – җитәкчегә: «Бу малайларны (алар абыйлы-энеле) үзем тәрбиягә алыйм әле», – ди. «Аларның әниләре ана хокукыннан мәхрүм ителмәгән. Ничек бирим?» – ди җитәкче. Ә малайларның әниләре моннан берничә ел элек төрмәдә утырып кайткан. Егетнең олырагы исә: «Мин әни янына кайтмыйм. Ана хокукыннан мәхрүм итегез аны. Минем алга таба да укыйсым килә», – дип аптыраштa калдыра. Шулай итеп, ике малай да шушы гаиләгә килеп эләгә. Баланың зурысы институтка керә, аны тәмамлый. Теләгенә ирешә.

Ә менә кечерәген профтехучилищега бирәләр. «Шул малай яныма килде дә күз яшьләре белән елый, – дип тетрәнеп искә ала Рузалия Хәбибулловна. – «Минем институтка керәсем килгән иде, кертмәделәр. Үз балаларын керттеләр, ә мине юк, ди. Нигә мине гаиләгезгә алдыгыз? Сезнең бит минем белән булашасыгыз килми, мин бит сезгә – барыбер...» – дигән. Бала гаиләдә үзенә карата булган мөнәсәбәтне күреп, гарьләнеп үскән. Яратмауларын күреп торган. Шуңа күрә балаларны икенче бер гаиләгә тәрбиягә биргәндә йөз мәртәбә уйларга, аңа кайда яхшы булачагын бала мәнфәгатеннән чыгып эш итәргә кирәк».

Үзеңнеке итсәң генә...

Гомумән дә, алай булырга тиеш түгел. Бала ул тауар түгел. Ятимнең аннан башка да сүнәм-сүнәм дип торган өметен юкка чыгарырга ярамый. «Биш бала янына тагын өчәү генә сыяр әле», – дигәнебез, көннәрдән бер көнне ятим өчен чын мәгънәсендә фаҗигагә әйләнә. Әни кешенең чит баланы үз итә алмавы ятимне үз эченә бикләнергә, кешеләргә ышанычын югалтырга мәҗбүр итә. Анда нәфрәт уяна. Уллыкка-кызлыкка алу үзәкләре иң элек бала мәнфәгатен күз алдында тотарга бурычлы. Берара Мөслим якларында тәрбиягә бала алырга җыенган әниләр өчен махсус курслар эшли башлаган иде. Аны психологлар, педагоглар алып барды. Белмим, хәзер ничектер, әмма ул дәресләр үзенең уңай нәтиҗәсен бирмичә калмады. Ул төбәктә ятим бала тәрбияләүчеләрне гаиләләп түгел, авылы-авылы белән санарлык бүген. Бәхәсләшмим, ятимне үз баласыдай күреп, яратып үстергән гаиләләр дә бик күп. Андый әти-әниләргә рәхмәттән башка сүз юк. Ләкин үзенең биш-алты баласы янына унышар ятим алучылар да юк түгел. Үзеннән-үзе: «Ни өчен алалар? Нинди максатны күз алдында тоталар?» – дигән сорау туа.

БЕЛЕШМӘ

Лаеш районы үзәгендә – элеккеге хатын-кызлар монастыре биләмәләрендә – табигатьнең гаҗәеп матур почмагында урнашкан әлеге балалар йорты республикада иң борынгылардан санала. 96 еллык тарихы булган ул йорттан шул вакыт эчендә 3 меңнән артык егет һәм кыз зур тормышка киткән. Бу йортның сәламәтләндерү лагере, үз ярдәмче хуҗалыгы, җылытылган гаражы, автобусы, машинасы бар. Укыту-тәрбия эшләре өчен зур спорт һәм концертлар залы, хоккей мәйданчыгы, сенсор бүлмәсе, кирәкле булган барлык җиһазлары, аудио-видео аппаратуралары бар! Иң мөһиме – аның тарихи музее бар! Читтән күзәтеп торган кешегә биредәге мөмкинлекләр аеруча сәләтле балалар өчен интернат-мәктәпне хәтерләтә.

Бала күрмәгәннән түгел бит инде. Билгеле инде, андый гаиләләрне акча йөртә. Кире кайтарылган баланың яңа әти-әниле булырга теләмәве аңлашыла. Аңа балалар йортында булу уңайлырак. Һәрхәлдә, ул үзен кимсетелгән итеп хис итми. Хакыйкатькә яши-яши төшенәсең. Кызганыч, әмма ләкин тормыш бүген шуны күрсәтә.

«Китәм дидем, тагын калдым»

Әңгәмәдәшем – Лаеш балалар йорты директоры, Халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы Рузалия Вәлиуллинаның иң зур теләге – балаларны үз гаиләләрендә яшәтү! Әлбәттә, моның өчен җиңнәр алдан ук сызганулы булырга тиеш. Без әйткән «уңышсыз гаиләләр» бер генә минутка да күз алдыннан югалып тормасын.

– Мәктәптә практика үткән чагым, – дип искә ала, үткәненә әйләнеп кайтып Рузалия Хәбибулловна. – Дәрес бара, ә коридорда кемдер кычкырып-кычкырып елый. Чыгып карасам, безнең бала. «Ник елыйсың?» – дим. «Минем балалар йортына китәсем килми. Әнием белән каласым килә», – ди малай, күз яшьләренә буылып. Балалар йортыннан качып кайткан икән, өстебашы пычранып беткән. Дөньяда ятим балалар да барлыгын беренче мәртәбә шунда белдем. Мине шушы йортка эшкә чакыргач, күз алдыма иң элек шул бала килеп басты.

Ул үзе дә җиде балалы гаиләдә туа. Аңа ике яшь ярым чагында әтисе үлеп китә. Әнисе Кафия апа җиде бала белән кала. Кыз яхшы укый. «Дүртенче сыйныфта укыганда өйгә район мәгариф бүлегеннән килделәр. Әнигә әйтәләр: «Кызың математикадан бик көчле. Казанга җибәрик. Интернаты да бар. Үзеңә дә бераз җиңелрәк булыр», – диләр. «Юк, беркая җибәрмим. Алты балага ашарга-эчәргә тапканны, аңа гына табармын», – ди әни. Әйткән сүзләренең мәгънәсенә еллар үткәч кенә төшендем».

Кайгырту, ярату булганда...

Аның укытучы буласы килә. Институт тәмамлагач, туып-үскән Әлки якларына кайтып, шунда укытасы килә. Аңарчы әле аңа техникум тәмамларга, шул арада ике мәртәбә институтка барып, өченчесендә генә хыялын тормышка ашырырга туры килә. Ул югары уку йортын тәмамлаганда – инде студентлар отрядының командиры. Кызны Казанда калырга үгетлиләр, балигъ булмаган балалар комиссиясенә эшкә чакыралар. Әнисе моны белүгә бер генә җөмлә әйтә: «Син нәрсәгә укыдың?» «Минем өчен әнинең сүзе бөтен нәрсәдән өстен иде, шундук районга кайтып киттем», – дип елмая Рузалия Хәбибулловна. Ике ел мәктәптә, аннары – комсомолда өченче секретарь, партия район комитетының оештыру бүлеге җитәкчесе һәм ниһаять, Рузалия Вәлиуллина әйтмешли, «күктән төшкән әмер»дер – 1986 елның 4 сентябрендә ул Лаеш балалар йортына аяк баса. Ятим балалар белән эшләүнең никадәр катлаулы, никадәр җаваплы эш булуына ул тора-тора төшенә.

БЕЛЕШМӘ

Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса СУЛИМА:

«Без инде унынчы ел ятимнәргә фатир бирәбез. Шушы вакыт эчендә 1947 ятим бала тораклы булды. Бу максатларга дәүләт тарафыннан 2 миллиард сумлап акча бүлеп бирелде. Программа Татарстан Президентының шәхси кайгыртуы буенча тормышка ашырыла. Яшьләрнең беренче чиратта үзләре теркәлгән муниципаль районда фатир алу мөмкинлеге булса да, Алабугага күчәргә теләүчеләр күбрәк. Чөнки бирелгән төзелгән фатирларда көнкүреш өчен кирәкле булган бөтен җиһаз да бар».

2004 елда бер китәргә дә җыенып карый. Әмма 1 сентябрьдә Бесланда булган хәлләр аны туктатып кала.

– Ни өчен? Беслан кайда да, без кайда? – дим.

– Менә шулай, – ди ул, үзе дә ни әйтергә белмичә. – Ул вакытта бөтен ишекләрне тимергә алыштырдык, коймаларны төзәтеп чыктык. Миңа гел Бесланның җиле безгә дә килеп кагылыр сыман тоелды. Балаларыма авыр чагында хыянәт итәм кебек тоелды.

> *Ул нинди генә булмасын, балага үз әнисе белән рәхәт, үз гаиләсендә тыныч.*

– Балаларыма, дидегез... Үзегез уллыкка, йә кызлыкка бала алырга теләмәдегезме соң?

– Булды андый хәл, – ди ул. – Бер кыз баланы алмакчы идем. Авыру бала иде ул. Безгә килгәндә йөри дә алмый иде. Ә соңыннан аягына басты, спорт залыннан чыгарып булмады үзен. Алам дигәч, дусишләр бу уемнан кире кайтарды. «Әгәр дә син аны алсаң, бөтен игътибарың шул балада гына булачак. Ә калган ятимнәр нишләр?» – дигәч, килештем. Алар минем бүген унтугыз бала. Һәркайсы кадерле, һәркайсы якын. Мин аларның сулышларына кадәр тоям. Нәрсә кирәклеген, ни әйтергә теләгәнен күзләреннән укыйм. Алар биредә бәхетле. Мин моны бөтен җаваплылыкны тоеп әйтәм. Балаларыма әниләрен эзләргә булышкан чакларым булды. Табабыз, яннарына баласын җитәкләп барабыз. Ә алар подъезд төбенә төшәргә дә теләмиләр, фатирларыннан чыгарга иренеп яталар. Бар шундыйлар да. Бер сүз белән әйткәндә, балалар йортларында ятимнәргә җылы караш, сөю-ярату булганда, аларның һәр адымын кайгыртып, алар өчен борчылу күрсәтеп яшәгәндә бала эчкече әнисе янына, гаугалы-низаглы тормышка әйләнеп кайтырга ашыкмый. Аның инде нәрсә яхшы, нәрсә начар – чагыштырып карар мөмкинлеге була. Тик кабатлап әйтәм: балалар йортларында чын мәгънәсендә гаилә атмосферасы: бер-береңне ярату, хөрмәтләү, кайгырту булганда гына шулай.

– Сезнең өчен иң авыры нәрсә?

– Баланың елавы. Ул бит тиктомалдан еламый.

PRESSA.RU

Димәк, ул авырый яисә ниндидер борчуы бар. Андый чакта шундый авыр булып китә. Мин барын да йөрәгемә якын кабул итәм. Шуңа да бирегә килеп эшли башлаган өч ел эчендә чәчләрем тоташ агарды. Ятимнең килүе дә, 18 яшен тутырып, мөстәкыйль юлга аяк басуы да безнең өчен зур вакыйга. Алар киткәндә җанымның бер кылы өзелә. Мин гел нидер югалтам сыман. Гәрчә, «өйләренә» әледән-әле кайтып, безгә йә түбә ябарга, йә койма тотарга, йә ут кертергә булышып йөрсәләр дә... Безнекеләрнең барысы да техникумнарда, институтларда укый. Барысы да белемле, җитеш, үзенә күрә шәхес.

Опека һәм иганәчелек бүлеге хезмәткәрләре үзара мөнәсәбәтләрне гаилә таркала башлаганчы ук күреп алырга, кичекмәстән чарасын күрергә тиеш.

Ул бу йортта элеккеге Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән Россия Федерациясенең хөкүмәт башлыгы Дмитрий Медведев булып китүен, ятимнәргә «Соболь» пассажир автобусы бүләк итүен, ә балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең берсен: «Кердең дип исәплә», – дип, Мәскәүдәге хәрби музыкаль училищега тәкъдим итүен шатланып сөйли.

Ул егетебез – Андрей Кадеев хәзер Казанда, Югары хәрби училище оркестрында солист. «Балачагым бәхетле булды. Унбиш әнием генә бар иде», – дип искә ала ул Лаеш балалар йортында үткән көннәрен. Дини китаплар язучы Александр Печенкин турында да ишеткәнегез бардыр, мөгаен. Күп алар, әйтә бит, һәркайсы – үзенә бер шәхес...

– Киләчәкне ничек күзаллыйсыз? – дигән соравыма ул бераз уйланып тора. «Йортыбызны сәламәтлеге чикле булган ятим балалар өчен көйләргә уйлыйбыз, – ди җитәкче планнары белән уртаклаша башлап. – Моның өчен бөтен мөмкинлекләр бар: безнең белән янәшәдә генә бассейнлы спорт комплексы, коррекцион интернат-мәктәп бар. Якында гына реабилитация үзәге һәм техник-икътисадый техникум урнашкан. Балаларга медицина ярдәме кирәк була калса, кул сузымында гына төрле медицина үзәкләре булган Казан шәһәре. Ходай үзе кушкан безгә шуны эшләргә...

Бала мәнфәгатьләре өчен ул утка да, суга да керергә әзер. «Ятимнәр мәнфәгате» дигән сүзне ул төрле югары мөнбәрләрдән әйтә килә. Эшенең гел уң килеп торуын ихластан укыган догалары белән бәйли. Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән дигән сүзне дә ул бертуктаусыз кабатлый.

...Гомерен, Лаеш балалар йорты җитәкчесе шикелле, авыр язмышлы балаларга багышлаган кешеләр сирәк алар. Бу сөйләшүдән һаман бер сүз искә төшә: «Алар киткәндә җанымның бер кылы өзелә. Мин гел нидер югалтам сыман...» – дигән иде ул. Әниләргә генә хас тойгы бу. Бик тә яхшы аңлыйм мин аны...

СОЦИАЛЬ ЯТИМЛЕКНЕҢ СӘБӘПЛӘРЕ

Бу – җәмгыятебезнең мөһим проблемаларыннан берсе. Тормышларның көннән-көн авырая, катлаулана баруы әнә шулай авырткан җиребезгә килеп кагыла: гаиләләр таркала, балалар ятим кала. Әчкече әти-әниләрне, ахыр чиктә, опека һәм иганәчелек бүлеге хезмәткәрләре ата-ана хокукыннан мәхрүм итә. Караучысыз калган сабыйлар ятимнәр йортларына килеп эләгә.

Ә бит социаль ятимлекне кисәтергә, алдан чарасын күрергә дә була иде. Авыр хәлдә калган шундый гаиләләр белән даими элемтәдә торганда, вакытында ярдәм кулы сузганда мондый фаҗигане читләтеп үтәргә дә мөмкин бит.

Мәгълүматларга караганда, былтыр 48 гаиләдән 122 бала алынган. Шулардан 98 баланың әти-әнисе йә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән, йә аларның хокуклары чикләнгән. Әлеге факт үзе генә дә кисәтү эшләренең тиешенчә алып барылмавы турында сөйли.

■ Ата-ана хокукыннан мәхрүм итү тәҗрибәсенең һәр яктан уйланылган булмавы да социаль ятимнәр саны артуга китерә. Балага үз гаиләсендә рәхәт булуын истән чыгармаска, аның мәнфәгатен истә тотып, гаиләне саклап калу өчен булган бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк. Башта ата-ананың хокукларын чикләп карыйлар, бу кисәтү дә тәэсир итмәсә, мәхрүм итәләр. Узган ел 131 кешенең ата-ана хокуклары чикләнгән.

■ Ата-ана хокукларын кайтару эшләре дә бик сүлпән бара. Кызганыч, хокуклары кайтарылган ата-аналарны бүген бармак белән генә санарлык. Былтыр андыйларның саны, соңгы биш ел белән чагыштырганда, күпкә кимеде. Мисалга, 2014 елда суд аша 59 кешегә ата-ана хокукы кайтарылган булса, 2015 елда нибары 37 кешенең хокуклары кире кайтарылды.

Былтыр ел азагына ятимнәрнең һәм караучысыз калган балаларның саны 11784 булган. Хәзер тәрбиягә алынган балалар арта бара. Узган ел балалар йортларында тәрбияләнүчеләрнең саны 12 процентка кимегән. Соңгы елда дүрт балалар йорты (Бөгелмә, Казан, Яшел Үзән, Чаллы) ябылган.

Былтыр 1120 ятим бала гаиләләргә урнаштырылган. Балалар йортларында тәрбияләнүчеләрнең 53 проценты инвалид булуын истән чыгармыйк. Аларны гаиләләргә бирү һәм, иң мөһиме, биргәндә ялгышмау өчен «Балага видеопаспорт» эшләнде.



ӘТИЛӘР КАЧЫШЛЫ УЙНЫЙ

Алимент түләмәс өчен алар төрле хәйләгә бара. Андый хәсрәт-әтиләрнең бурычы бүген 2 миллиард сумнан артып киткән. Республикада алимент түләү бурычы булган ир-атларның саны 9 меңгә якын. Бала балигъ булу яшенә җиткәч, алимент үзеннән-үзе ата кешенең бурычына әверелә. Димәк, барыбер түлисе.

Алимент сүзен ишетүгә күз алдына әтисез бала килеп баса. Бәхетсез бала, әти назыннан, әти тәрбиясеннән мәхрүм бала. Ул кимсенеп, яшьтәшләре арасында җәберсенеп үсә. Әгәр дә без яңа өйләнешкән парларның һәр дүртенчесе аерыла дип кисәтәбез икән, алимент мәсьәләсендә алга таба да, кем әйтмешли, көрәселәр бар әле.

Саннар да, фактлар да шул хакта сөйли. Татарстанда Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина һәм республиканың баш суд приставы Радик Ильясов катнашында оештырылган кабул итү көне әлеге мәсьәләләргә багышланды. Мөрәҗәгать итүче әниләрнең һәркайсы иренең алимент түләмәвеннән зарланды. Хәер, аерылышкач, ире түгел инде ул аның. Ләкин баласы өчен ул бит әти.

Дөрес, әтиләрнең дә төрлесе була: кайсы үзе теләп түли, баласын тәрбияләүдә катнаша. Кайсы газизенә акча бирмәс өчен качып йөри. Илдән чыгып китәргә дә күп сорамас иде. Чыгармыйлар гына, ул инде күптән приставларның кара исемлегендә, аңа карата «исполнительный лист» күптән тутырылган. Баш суд приставының әйтүенә караганда, приставлар кулында шундый характердагы 21 мең эш (аларча, лист – *авт.*) ята. Өстәвенә, алименттан качып йөрүчеләргә карата 80 җинаять эше кузгатылган. Монысы инде «злостный», ягъни барып чыккан алиментчылар. Уйлап карагыз инде: гаилә кыйммәтләре кая таба тәгәри... Татарстан Фәннәр академиясенең «Гаилә һәм демография фәнни-тикшеренү үзәге» мәгълүматларына караганда, соңгы вакытта әтисезлек очраклары нык артып киткән. Һәм бу хәлне (һәлакәткә илтә торган, дип әйтер идем – *авт.*), әлбәттә инде, акча белән генә җайга салып булмый.

Баланы ялгыз тәрбияләгән анага һәрьяклап авыр. Бу хакта әйтеп тә торасы юк. Тамагың тук, өстең бөтен генә түгел бит, баланы тәртипле, җәмгыятькә кирәкле шәхес итеп тәрбияләү дә бик мөһим. Ә моның өчен, үзегез беләсез, акча кирәк, матди якны кайгыртырга кирәк. Закон буенча балага тотылган чыгымнарның яртысын – әти, яртысын әни түли. Бары шул чагында гына әти кеше картайган көндә баласына, «карамыйсың» дип, дәгъва белдерә ала. Кайчандыр газизен бар дип тә белмәгән ирләрнең гомерләре баешка борылган бер мәлдә балаларын искә төшереп, ярдәм сораган мисаллар да аз түгел. Менә шуңа да әниләр алимент түләми тилмерткән юньсез әтиләрне ата хокукыннан мәхрүм итүдә булышуны үтенеп киләләр дә. Нурлат шәһәрендә яшәүче Гөлүсә ханым да шундый гозер белән килгән. «Ирем белән аерылышканда балага нибары 11 генә ай иде, – ди ул. – Хәзер аңа 16 яшь. Шул вакыт эчендә әтисе нибары бер мәртәбә, балага 15 яшь тулган көнне килеп китте. Алимент түләми. Ә бала түләүле уку йортында укый. Укыту өчен акча кирәк, дип әйтеп карыйм, аңламый». Хәзер әти кешенең баласы алдында 500 мең сум бурычы бар. Баш суд приставы ханымны игътибар белән тыңлый, киңәшләрен бирә. Ата хокукыннан мәхрүм итү өчен судка мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итә.

Мондый очракта суд та, законнар да әни мәнфәгате ягында. Шуңа да карамастан, «алимент-әтиләр» ул законнарны читләтеп үтү җаен табып торалар.

«Ирем мине бала тууга ук ташлап китте, – дип сөйли Альбина ханым. – Өч айдан аерылыштык. Алиментка бирдем. Эшләгән җиреннән 10 мең эш хакы алуы турында белешмә җибәрделәр. Ә мин беләм аның ничек яшәвен: әле генә кредитка фатир сатып алды. Машинада йөри. Бер дә мохтаҗлыкта яшәми. Суд приставлары янына бардым, алар да тынычландыргыч, өметләндергеч сүз әйтмәделәр. Болай караганда, барысы да закон буенча, диләр». «Юк сез хаклы түгел, – дип сүзгә кушыла Радик Ильясов. – Балага акчаның күпме тотылуын нигезләп аңлатырга, саннар белән дәлилләп күрсәтергә кирәк. Аена 10 мең китә икән, димәк 5 меңен әти түли». Ул ханымга, иренең эш хакын күзәтү астына алсыннар өчен, Дәүләт хезмәт инспекциясенә мөрәҗәгать итәргә кирәклеген әйтә.

Рәсми рәвештә беркайда эшләми дип исәпләнүчеләр дә байтак. Нинди чара күрергә соң моның ишеләргә? Ни акчасы юк, ни мал-мөлкәте дигәндәй. Төрмәгә утыртырга була. Монысы инде соңгы чара. Андый җәзадан берәүгә дә җиңеллек килми. Яисә элеккеге совет чоры заманнарындагы кебек, ирексезләп дәүләт предприятиесенә эшкә урнаштырырга. Зарарлы эшкә булса да ярый. Тырышып эшләп, тизрәк әйбәтрәк урынга урнашу җаен карарлар.

Алименттан качып йөрүчеләргә карата чыгарылган законнар бик кырыс хәзер. Алимент түләми икән, машинасына, фатирына арест салына, ягъни ул инде руль артында кинәнә алмый, аларны, әйткәнемчә, чит илгә дә чыгармыйлар.

Ә шулай да... гамәлдәге законнарда гына түгел хикмәт. Язылмаган законнар да бар бит бу дөньяда: балаң барын онытмау, аны кайгыртып, яратканыңны белдереп яшәү. «Спас районында яшәүче бер ир суд приставларына килеп, баласына булган 362 мең сум бурычын калдырып киткән», – дип сөйли баш суд приставы. Шәхси транспортта йөрүне чикләү турында закон чыкканнан бирле суд приставлары тарафыннан 584 шундый карар кабул ителгән, 5 меңнән артык кисәтү ясалган. Нәтиҗәдә, алименттан баш тартып йөрүчеләрдән 9 миллион сум акча кайтарылган. Димәк, качып котылам димә.

Никадәр алиментчы – шуның кадәрле үк әтисез бала. Ир тәрбиясе күрмәгән баладан сорау да шулхәтле генә. Әлбәттә, мин аерылышулар турында әйтәм. Шуның ише күңелсез хәлләр булмаса, алимент турында сөйләшеп утырыр идекме без бүген?!

Мәдинә КАШАПОВА

PRESSA.RU



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Фото: Ксения Богданова

ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ ВАХТА

– БАШКАЛАРГА ТИГӘН ЙОКЫНЫҢ БЕЗГӘ ЯРТЫСЫ ГЫНА ЭЛӘКТЕ!



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Уенын-чынын бергә кушып сөйлиләр. Әйе, «Төнге сменадан эштән кайттым», – дип, кайсы хатын-кыз көндез урынга менеп ята, ди, инде?! Өйдә ире, бала-чагасы, кайнана-кайнатасы – тавык та чүпләп бетермәс эше көтә бит әле аны. Йокысыз уздырган төн озын көнгә кушыла да китә шулай. Ә ул «йокысыз төннәр» арасында таң беркайчан атмас кебек булып тоелганнарын искә төшерсәң?! Тыңлаган саен инана барам: эшләре, мин уйлаганга караганда, күпкә катлаулырак аларның! Җаваплылык турында әйтмим дә!

– Безгә яңа приборларны 2000 елны куйдылар. Кышка керер алдыннан булды бу хәл. Ә аннан, Яңа елдан соң, кинәт кенә суытып җибәрде. Төнге сменам иде. Көнен дә хәтерлим – 15 гыйнвар... Башта бер прибор катты, аннан икенчесе, өченчесе... Чиратлап бөтенесе катып беттеләр! Суыкка көйләнмәгәннәр. Иртәнге сәгать дүрт. Приборлар күрсәтмәгәч, нишләргә дә белмибез: әллә ачарга краннарны, әллә кысарга... Беркайчан акмаган урыннан, кап-кара булып, нефть тасмасы агып төшә башлады... Искә төшкәч, йөрәк хәзер дә «жу-у» итеп китә. Света белән икебез дә кычкырып-кычкырып еладык шулчак...

– 1984 елның кышы иде, – монысын Зинира апа Шакирова сөйли. – Минем әле установкага күчкән генә вакытым: күп эшнең җаен-рәтен дә белмим. Янып торган факел бар иде ул чакта, һәм аны беркайчан сүндерергә ярамый иде. Әлеге дә баягы, төнге смена. Факел сүнгән! Флера апа белән киттек кар ерып: аякта итек, кулда керосинлы чиләк. Барып җиттек, ут кабызып, атып карыйбыз – буебыз җитми. Аптырагач, ярамаса да, «обваловка»ның эченә кердек. Кабыздык факелны. Шул вакыт, бензин чәчрәп, бөтен дөньяга ут капты! «Синең яшь балаң бар – алдан йөгер!» – дип Флера апа мине сукмакка таба төртте. Кулымдагы керосинлы чиләгемне тоткан килеш йөгерәм икән, ул: «Ташла!» – дигәч кенә бәреп калдырдым. Көчкә чыгып җиттек... Оператор бүлмәсеннән карап торучылар: «Бетте, яндылар болар...» – дип уйлаган. Шуннан соң төнлә факел кабызуны туктаттылар. Сүнсә – иртәнгә кадәр сүнгән килеш торып торды. Хәзер без аны авария вазгыяте килеп туса гына яндырабыз. Анда да ерактан торып кына кабызабыз.

«Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенә алар эшкә 19 яшьлек яшь-яшь кызлар булып килгәннәр. Җир маеның әле ни икәнен дә белмичә... Рушания апа Хәйретдинованы ул чакта ярдәмче итеп алалар. Аңа остаз итеп билгеләнгән Рәис абый Кәлимуллин: «Мин сине өлкән оператор булырлык итеп өйрәтәм әле», – ди һәм сүзендә тора. Нефть һәм газның, химик реагентлар һәм бензинның физик-химик сыйфатларын, нефтьне газ һәм судан аеручы җайланманы, аның эшләү тәртибен, контроль-үлчәү приборларының үзенчәлекләрен... тагын әллә ниләр аңларга, өйрәнергә туры килә кызга. Үҗәтлек, тырышлык җитәрлек була аңарда. Ул инде күптән, остазы күрергә теләгәнчә, өлкән оператор.

Идарәнең Рушания һәм Зинира апалар эшли торган нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру цехы – куркыныч производство объекты дип санала. Бирегә аерым рөхсәт белән һәм тикшерү үткәннән соң гына кереп була. Ярый әле кышын килдек. Җәен килсәк һәм аягымда биек үкчәле туфли булса, үкчә асфальтка ышкылып очкын чыгу ихтималы бар, дип, ишек төбеннән кире борырлар иде. «Ярамый»лар тагын бар әле: кесә телефоныннан сөйләшү рөхсәт ителми, тәмәке тарту...

Аларга нефть өч фаза – су, газ һәм җир маеннан торган сыеклык булып килеп керә. Башта бу сыеклыктан газны аерып алалар. Аннан чират суга җитә. Инде ике компонентлыга гына калган сыеклык резервуарларда ламинар режимда тондырыла: су авыррак – ул аска төшә, нефть җиңел – анысы өскә күтәрелә. Моннан соң алар икесе ике резервуарга бүленә. Буферларда җыелган нефть установкага китә. Бу җайланмада башта аны 70-80 градуска кадәр җылыталар, тондыру бассейнында тотып, калган сулардан аралыйлар, аннан киресенчә, төче су кушып, тозларын юдыралар һәм кушылган ул судан кабат аералар. Җылылык алмашу торбалары аша үткән нефть, җылытылып, мичкә барып җитә. Ә анда кызулык 200 градус! Нефть монда метан, этан, пропан кебек җиңел фракцияләрдән арына. Аннан суытыла һәм товар бүлегенә юл ала. Девон нефтенең язмышын магистральләр аша кайсы якларга юл аласын исә «Транснефть» хәл итә.



Рәсим МУСИН, нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру цехы җитәкчесе.

– Безнең коллективның 80 проценты хатын-кызлардан тора. Эшебез зур җаваплылык, игътибар таләп итә, ә бу аларда, чыннан да, күбрәк бугай. Арада Рушания апа Хәйретдинова кебек гомер буе эшләүчеләребез бар. Алар нефть тармагында эшли башлаган чорда һәр көнне нииндидер яңалык кабул итәргә, аңа өйрәнергә туры килгән. Яңа реактивлар кергән, технология үзгәргән. Көн туган саен яңа бурычлар куелган, һәм алар гел катлаулана барган. Бүгенге яшьләргә күпкә җиңелрәк: Рушания апалар белгәнне алар тәҗрибә аша тупламый, китаптан гына укып өйрәнә.

«Татнефть» акционерлык җәмгыятендә тәртип шундый: яшь кеше эшкә урнашканда, аның гаризасында остазы кем булачагы да күрсәтелә. Рушания Хәйретдинова – иң яхшы остазларыбызның берсе. Эш дигәндә, «юк» дигән сүзне бөтенләй белми ул. Аңа нииндидер эш йөкләнә, бурыч куела икән – җаның тыныч була ала – үтәячәк. Теләсә кем белән уртак тел таба, яшьләр шуңа да тартыла аңа. «3 миллиард тонна Татарстан нефтен табу уңаеннан» медален Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов кулыннан юкка гына ул алмады бездә.

Цехта эш процессы күптән автоматлаштырылды. Әмма аның бер өлешен барыбер кулдан башкарырга туры килгән очраклар бар. Андый чакта Рушания кебек өлкәннәрнең тәҗрибәсенә таянасың. Технологик параметрларны саклау, технологияне ритмик режимда тоту – аларның төп бурычы. Алар моны җиренә җиткереп, барлык кагыйдәләрне истә тотып башкара. Нииндидер тайпылышлар була икән, бу сыйфатка да тәэсир итми калмый. Нефтьнең бәясе исә сыйфатка турыдан-туры бәйләнгән.

PRESSA.RU



Яшьләрнең эшкә өйрәнергә атлыгып торганнары бар – андыйларга тәҗрибәңне куанып тапшырасың.

Рушания апа һәм аның хезмәттәшләренең ни белән шөгыльләнгәне аңлашылсын өчен сөйлим боларны. Көне-төне берөзлексез хәрәкәттә булган шушы катлаулы механизмны көйләп эшләтү – алар кулында. Урамда яңгырмы, кармы, күз ачкысыз буранмы – һәр ике сәгать саен алар установканы карап әйләнергә тиеш: температура саклнамы, басым төшмәгәнме яисә күтәрелмәгәнме... Өстә – бушлат, аякта – кирза итек, башта – бүрек. Муенда – противогаз, кулда – рация: һәр тикшергән объект турында оператор бүлмәсенә хәбәр итеп баралар. Судан һәм тоздан аеру установкасы җитәкчесе Чулпан Зыятдинов: «Әйдә ярар, икенче тапкыр чыкканда карармын әле, дип йөри торган җир түгел бу, – ди. – Әнә стабилизацион колоннаның биеклеге 60 метр – һава торышы нинди булуга карамастан, алар көн саен анда да менәләр. 5-6 ел элек гел хатын-кызлар гына иде вахтада. Шланг тишелсә дә, пар бәреп чыкса да – бар эшкә дә үзләре иде. Соңгы вакытта егетләр дә килә башлады».

– 37 ел буе шушында, бер урында эшләдем! – ди Рушания апа.
– Иң авыр вакытларда...

Компьютерлар булмаган чаклар турында әйтә ул. Бүгенге приборларның берсе дә юк дип күз алдына китерсәң, үзләренә дә куркыныч хәзер. «Ничек эшләдек икән?!» – дип шаккаталар. Басым күтәрелгәнен дә нефть агып чыккач кына белгәннәр бит.

– Берсендә насос бүлеге нефть белән тулды. Тиздән! – дип сөйли Рушания апа. – Урамда 35 градус суык. Приборлар эшләми... Икенче тапкыр елавым шул чакта булды... Иртән җиденче яртыда цех начальнигы шалтырата. «Рәсим Сөләйманович, безгә нишләргә?» – дим. «Рушания, сөйләшергә дә хәлең калмаган бит, бар, кайтыгыз», – диде.

Нефтьне җыеп, носилка, чиләкләр белән махсус коега түгәбез. Авыр ул... Андый вакытта үзебез нефтькә баткан үрдәк бәбкәләре кебек булабыз. Бер-беребезне танымаслыкка әйләнәбез! Нефть киемгә сеңә, кул астында бензин булып, шунда ук чистартмасаң, бетерәм димә! Элек кием-салымы да җунле түгел иде бит.

Ир-атлар түзми шул бу эшкә, бер-ике көн эшлиләр дә, юк, бу минеке түгел, дип күбесе китеп бара. Ә мин эштән-эшкә күчеп йөрергә теләмәдем... «Фонарик» катты берсендә. Кыш көне гел карап торырга кирәк, нәзберек ул: ачмасаң – ката, ачсаң – агып чыга. Ул вакытта пар да юк иде, су белән җылытабыз. Сигез сәгать буе җылыттым! «Бүген сменаны тапшырсам, җылыта алсам, иртәгә үк эштән китәм», – дим үз-үземә. Иртәнгә «фонарик» җылынып бетте, һәм гариза язу да онытылды... Балалар кечкенә чакта, өйдән дә ял итмичә төнге сменага килгән вакытлар һәркайсыбызда булды. Андый көннәрне кызлар: «Бу вахтаны гына тапшырам да, китәм», – дип еш әйтәләр иде. Беребез дә китмәде.

Бар да тәртиптә булса, җайланманы ике сәгать саен карап әйләнергә тиешбез. Берәр нәрсә килеп чыкканда, урамнан 12 сәгать буе кермәгән чаклар да бар. Көчле җил чыкса, торбалар катарга 9-10 градус салкын да җитә. «30 градус суыкка да түзәрбез, җил генә чыкмасын», – дип теләп йөрибез без. Кыш безнең өчен шактый авыр вакыт шул... Берсендә банкоматтан акча алырга чират торам. Алдымда ике ханым баскан, өсләрендә матур, затлы туннар. «И-и, яратам да инде кышны, – ди берсе. – Бу суыклар тагын да озаграк булсын иде әле!» «Безнең эштә эшләсәгез, бер дә болай уйламас идегез», – дип торам эчемнән. Мин үзем гомер буе: «Бездә гел җәй булса икән ул!» – дип хыялландым. Җәй көне рәхәт бит: өстебездә кышкы авыр кием юк, аякта итек түгел, кар сөреп йөрмибез. Смена тыныч узса рәхәт инде. Мичләр янынннан үткәндә – аларны, насослар кырыннан барганда шуларын сыйпап йөрим, исән-имин генә эшләгез, дип. Минем яшьтәгеләр барысы да шулай итә...

Торба катып тилмерүләр сирәк була икән хәзер. Һәркайда яңа технология – алар операторлар бүлмәсендәге компьютерлар белән тоташкан: кайда нинди көйсезлек булуы шунда ук күренә. Вахтадагыларга, чыгып, борасын борып керергә генә кала. Эш җиңеләйгән, дисәм... «Бүгенге смена бик авыр булды, – ди әнә Рушания апа. – Бер насосның приборы дөрес эшләмәде. «Һава газ белән пычранган», – дип сигнал биреп кычкыра да кычкыра. Карап кердем, бар да тәртиптә. Ярты сәгатьтән тагын шул сигнал. Кабат чыгып киттем. Чынлап та шулай икән, шартларга да мөмкин бит. Кыскасы, төнге унбердән иртәнге дүртенче яртыга кадәр кереп-чыгып йөрдем. Ярты сәгать саен! Көрт бит, җитмәсә».

Ә йокы... йокы аларга чыннан да аз эләккән. «Төнге сменадан кайткан көнне бөтенләй йоклап булмый», – диләр. Зарланып сөйләмиләр, күптән күнгәннәр. Һәм иң гаҗәбе – бернигә дә карамастан, шушы эшләрен яраталар алар!

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Казанда «Татарстанның эшлекле хезмәттәшләре» форумы узды. Пленар утырыш алдыннан ТР инновацион проектлар аллеясы эшләде. Форумда катнашучыларны Президент Рөстәм Миңнеханов сәламләде. Ахырдан ҖЧҖ «Майский» теплица комбинаты, «Химград» технополисы объектларына экскурсия оештырылды. Форумда К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның 70 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды.

■ ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Парижга эшлекле визит кысаларында «Франция–Татарстан» бизнес-форумында катнашты. Анда Татарстанда үз проектларын тормышка ашырырга теләгән француз эшмәкәрләре белән аралашу булды. Президент аларны Сабантуйга чакырды.

■ Мәскәүдә Татарстанның Россиядәге вәкаләтле вәкиллегендә «Күренекле кешеләр тормышы. Биография дәвам итә...» сериясеннән Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә багышланган китапны тәкъдим итү булды. Анда Минтимер Шәймиев үзе дә катнашты. Китапны танылган журналист Игорь Цыбульский белән берлектә Татарстан Президенты матбугат хезмәтенең баш киңәшчесе Нурсөя Шәйдуллина язган.

■ Күренекле татар һәм төрек галиме, язучы, дәүләт эшлеклесе, беренче Төркия Президенты Кемаль Ататөрекнең киңәшчесе, Төркия Республикасы конституциясен язуда зур өлеш керткән Садрый Максудига Казанның «Истанбул» паркында һәйкәл ачылды. Проектның авторы – сынчы Асия Миңнуллина. Ачылу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Төркия Премьер-министры Бинали Йылдырым, республиканың Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Садрый Максудиның оныгы Гөлен Пултар һәм кияве Мостафа Пултар, туганнары, рәсми затлар катнашты.

МӘГАРИФ

■ Казанның 12 нче татар кызлар гимназиясендә Фатиха Аитова музее ачылды. Әтисе Габделвәлинең мирас акчасына 1906 елда татар кызлары өчен мәктәп төзеткән Фатиха Аитова турында анда истәлекләр тупланган. Гимназия үзе дә аның исемен йөртә.



■ Казанда «Татар кызы һәм татар егете-2016» шәһәр бәйгесенең йомгаклау туры узды. 9 нчы мәктәп укучысы Камилә Шәмсетдинова – «Татар кызы-2016», 7 нче лицей укучысы Муса Гаянов «Татар егете-2016» дип игълан ителде.

■ WorldSkills 2016 Европа чемпионнары, EuroSkills Россия җыелма командасы әгъзалары, гомумкоманда зачетында беренче урынны яулап, Швециядән җиңү белән кайтты. 28 илдән 500 яшь һөнәр иясе иң яхшы мастер исеме өчен ярышты. Казаннан Вадим Поляков «Суыткычлы техника һәм Кондиционерлау» компетенциясе буенча Россия җыелмасына алтын медаль өстәде.

КОТЛЫЙБЫЗ



70 яшен бәйрәм иткән көннәрдә Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллинага Татарстан Республикасы Президентының «Фидакарь хезмәт өчен» медале тапшырылды. К. Тинчурин театры бинасында узган юбилей концертын тамашачы югары бәяләде.

МӘДӘНИЯТ

■ ТНВ каналы татар әдәбияты классигы Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» бәяны буенча төшерелгән дүрт серияле фильм күрсәтәчәк. Фильмның продюсеры Фәрит Галиев, сценарий авторы Дан Дамаскин, куючы режиссер Рөстәм Рәшитов, икенче режиссер һәм тавыш режиссеры Илсөяр Дамаскин. Фильмда 50 ләп артист катнаша. 215 күренеш файдаланыла. Төп рольләрдә – Г. Камал театры артистлары. Гүзәл Минакова-Сибгатуллина – Галияне, Ришат Әхмәдуллин Искәндәрне уйный.

АВЫЛ

■ Татар авылларын берләштерә торган яңа сайт булдырылды. «Татар-авылы.рф» дип исемләнгән әлеге интернет-ресурс татар авылларын саклау һәм берләштерү максатыннан эшләнгән. Сайтта авыл җирлегендәге 400 оешма турында мәгълүмат табарга мөмкин. Авыл хуҗалыгы, фермерлык, спорт, бакчачылык, мәдәниятсәнгать, ял итү кебек рубрикалар аша татар эшмәкәрләре җитештергән әйберләр белән танышырга була.

СПОРТ

■ Казанда Конфедерацияләр кубогына җирәбә салу узды. Россия хөкүмәте вице-премьеры Виталий Мутко тантананы үткәрү урынын билгеләгән вакытта оештыру комитеты аның нәкъ менә Татарстан башкаласында узачагына шикләнмәдек, диде.

■ Россиядә футбол буенча ил чемпионаты башлану вакытын кирегә таба санауга старт бирелде. Татарстан башкаласы – мундиаль матчларында катнашачак шәһәрләрнең берсе. Вакытны кирегә санаучы сәгать туристларның яраткан урыны – Кремль яр буенда урнаштырылды.

PRESSA.RU



ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ АСЫЛЫ БАР...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

ИКЕ МИЛЛИОННАН АРТЫК КАРАУ! МИНЕМ УРЫНДА КЕМ ЯЗСА ДА, АНЫҢ ТУРЫНДА ЯЗМАНЫ БАРЫБЕР ШУННАН БАШЛАР ИДЕ.

Спорт турында соңгы яңалыкларны укып бетергәннән соң, үзен инде «кадр артында» дип белгән Альбина, режиссер белән сөйләшә башлый, ахырда җырлап ук җибәрә... «Туйдым!» дигән бу видеоролик интернетка эләккәндә кызның «Чаллы-ТВ»дан Казанга күчеп, «KZN» телерадиокомпаниясендә корреспондент булып эшләгән чагы була. Интернет ул көннәрдә гөж килә! Иң кызыгы, алып баручы ялгышкан дип санасалар да, бар да аңа сокланып, яратып яза. Ихласлыгына, үз-үзен тота белүенә, югалып калмавына, зәвыгына шаккаталар. Һәм ул дулкын хәзергәчә дәвам итә... Беренче апрель алдыннан аны Андрей Малахов эзләп табып, «Пусть говорят» тапшыруында катнашырга чакыра. Альбина АСЫЛГӘРӘЕВА бүген «Татарстан–Яңа гасыр» каналында эшли. Ул – «Татарстан хәбәрләре» тапшыруының рус чыгарылышы алып баручысы. Әлеге видео турында искә төшерергә дә яратмый. Без аны телгә алып кына китәбез дә, Альбинаның тормыш кагыйдәләре турында сөйләшүгә күчәбез.

Актерларның: «Бер иртәне популяр булып уяндым», – дигән гыйбарәләре бар. Шуның шикелле булды ул көн. 2013 елның 23 февралендә иртүк шалтыратулар башланды: «Күрдеңме?», «Карадыңмы?» Хатлар ява, чәчәкләр китерәләр, бүләкләр җибәрәләр... Ул видеоны интернетка кем куйганын ике елдан соң гына белдем.

Интернеттан видеоны үземнең караганым да юк, дисәм... Оят... Әгәр берәр репортажым дөньяны шулай шаулатса икән ул?! Ә бу бит гап-гади эш моменты. Әйе, камера төшереп торган, мин аны белмәгәнмен. Беренче каналда тапшыруда катнашып кайтканнан соң мине хәтта урамнарда таный башладылар. Халыкның шундый вак-төяккә игътибар итүе, дөресен әйткәндә, шаккаттыра. Аның туры эфир түгел икәнен белмиләр дә. Аңлата-аңлата арыдым инде...

Интервью алган санаулы минутлар эчендә кешенең күңелен дә ача алган чаклар сирәк була. Ә үзең аның алдында ачыласы килгән вакытлар – тагын да сирәгрәк. Ләкин андый минутлар да бар. Чаллыда үзешчән рәссам Валентин Самарцев белән танышырга туры килгән иде. 90 яшь иде инде аңа. Яз көне иде бу, тал песиләре чыккан вакыт. Без сөйләшә-сөйләшә әкрен генә парк буйлап атладык. «Бөреләр ачылганын күрәсеңме?» – диде ул. «Әйе», – дим. «Ишетәсеңме соң?» – «Юк...» – «Бәхетле булган мизгелдә син аны ишетәчәксең дә. Мин сиңа шуны телим», – диде ул.

Тиз гафу итәм, тиз онытам. Бәлки гафу итмәслек бернәрсә дә эшләгәннәре юктыр миңа? Ләкин гафу итә белүне барыбер зур эшкә саныйм, аңа өйрәнергә кирәк.

Бер үк китапны кабат-кабат укырга яратам. Фильмнарны да яңадан карыйм. Шулай эшләү дөрестер дип саныйм. Башта 15 яшьтә укыйсың, аннан – 30 да, аннан инде 50 дә. Аннан, бәлки, 90 дадыр... Һәр чорда ул китапны үзең өчен яңадан ачасың. Сэлинджерның «Над пропастью во ржи» китабын кабат табып алдым әле менә. Китаплар күп миндә. Үз йортым булгач, анда зур китапханә булачак... Тинчурин паркындагы «барахолка»га еш йөрим. Аннан алган китапларны аерата яратам – исләренә кадәр башка. Шул китапларны ремонтлаудан, төзәтү-ябыштырудан тәм табам. Юк, интернеттан китап уку минем өчен түгел.

Тормышта кайчак бөтен нәрсәне аңлап бетермәсәң дә ярый, диләр. Ә миңа һәммә нәрсәнең төбенә төшәргә кирәк! Тормышым катлаулана инде, әлбәттә... Тик яңа танышкан кешене, килеп туган хәлне ахыргача ачып, аңлап бетермичә барыбер туктамыйм. Монысы эшемдә булыша, билгеле. Ә күп уйлавым, анализлау белән мавыгуым гел файдага гына түгел.

Туган ягым Сарманга, Җәлил бистәсенә журналист булырга теләүче укучылар белән очрашуга чакырдылар. Алардагы иллюзияләр! Тик кешенең иллюзиясен җимерергә берәүнең дә хакы юк. Хыялы булмаган кеше кайсы якка атларга да белми ул.

Мин менә нәрсәләрдән туйдым: кулдан төшмәгән телефоннан, интернеттан, вакыт юклыктан... Хәтта ялкауланырга да вакыт юк! Кыш чынлап торып башланмаган, мин инде салкыннардан ялыгырга өлгердем.

Көз исе ошый миңа. Дымлы яфраклар исе... Мунча исен, кечкенә авыл һавасын сулау ошый. Авылда таң атканда чык исе күтәрелә тагын...

Бо-бо-бо-боа... Роликта мин Джордж Гершвинның атаклы бишек җырын көйлим. Яраткан фильмым «Все будет хорошо»дан ул. Ә болай мин кеше ишетмәгәндә, машинада барганда гына җырлыйм. Күңел җырлаганда җырлыйм инде һәм шуннан үзем өчен рәхәтлек алам. Моның өчен тамашачы, тыңлаучы кирәкми. Тик: «Нинди талантка ия булырга телисең?» – дип сорасалар, «җырлый беләсем килә» дияр идем.

Социаль челтәрләр аша үземә хат юллаган беркемне дә җавапсыз калдырмаска тырышам. Заманында Беренче каналның алып баручысы Екатерина Андреевага хат язганым булды. Һәм ул миңа кыска гына булса да җавап бирде! Миңа да күп вакыт: «Җавап язарсыз дип уйламаган идек», – диләр. «Игътибарыгыз өчен рәхмәт!» – диюнең бер авырлыгы да юк.



Ике әбием дә бик кызык кешеләр минем. Әнинең әнисе – Мәрьям әбиемә 93 яшь бүген. Шөкер, үз аягында йөри. Маргарет Тетчер ул безнең! Андагы принциплар, аның холкының ныклыгы! Бер нәрсә уйласа, аны әле дә эшләми калмый. «Урыска кияүгә чыксаң, авыл башыннан да кертмим», дигән әбием шушы инде... Сарман районы Игәнәбаш авылында әбине бөтенесе дә белә, хөрмәт итә.

Әнисә әбием Азнакай районы Әлкәй авылында фельдшер булып эшләгән. Аның мине табиб итеп күрәсе килде. Без аның белән озак-озак итеп дин турында сөйләшәбез. Ислам динен миңа ул ача.

Җәйләребез гел Мәрьям әби янында үтте – авылны шуңа яратам. Ул безгә беркайчан «юк» димәде, ачуланмады. «Улым, кызым, торырга кирәк!» – дип, иртән сыйпап уятыр иде. Урамда ашарга да рөхсәт итә иде. Ишегалдында безнең өчен кечкенә өстәл ясап куйды, таган асты. Умарта тота иде: ипигә бал-май ягып, урамга чыгарып бирә. Аның тәмлелеге!

Токмачны ничек басарга икәнен дә миңа беренче тапкыр Мәрьям әби күрсәтте. Гомумән, аш-суга аның янында өйрәндем. Бәрәңге кабыгын юкарак әрчергә кирәк, дип әле дә искәртеп тора. Әби мәктәбе!

Оператордан бик күп нәрсә тора: ул сине матур да күрсәтә ала, ямьсез дә, йокысы туйган кыяфәтле итеп тә, авыру чырайлы ясап та... Камера белән дуслар алар. Минем дә бурычым ул – камера белән дуслашу.



PRESSA.RU





Әти дә, әни дә: «Мин сине яратам, кызым!» – дигән сүзләрне көн саен кабатламыйлар, билгеле. Бездә алай төчеләнмиләр. Әмма яратуларын сизеп торам! Һәр тапшырудан соң иң беренче фикерне алар әйтә. Мактыйлар да, тәнкыйтьлиләр дә... Ярату – яраткан кешең турында кайгырту бугай ул. Күптән түгел бозлы яңгыр яуган көн безнең күңелләрдәге яратуны, бер-беребезгә игътибарны, күрәсезме, ничек сынады? «Иплә кенә йөр», дип шалтыратулар ул көнне тынып тормады. «Ашадыңмы?», «Шарфың җылымы?» дигән сораулар, «яратам» дигән сүзгә караганда кадерлерәк миңа.



Студиядәге камераларга кеше күзенә караган кебек карыйм: алар сине ишетергә, аңларга тиеш. Фотосурәттә, экранда матур күренү табигатьтән килә, диләр. Тик моңа тагын әле дөрес ракурста утыруны, утның дөрес төшүен, мимикаларны өстисе...

Үземә социаль челтәрләрдә язган хатларга мин кайчак смайлик кына җибәрәм. Җайлы нәрсә бит ул смайлик: бик күпне аңлата һәм... бернәрсә аңлатмый да.

Якын дусларга бай мин! Туган көннәргә, гадәттә, чакырусыз гына иң якын кешеләр килә бит. Без җиде-сигезәү җыелабыз. Дуслардан файда эзләмиләр, алар миңа шатлык китерүчеләр. Тик яшең олыгайган саен, күңелеңә яңа кешеләр кертү авырлаша икән.

Сабырсыз мин. Чиратларда тора алмыйм, сабырым җитми.

Без Альберт белән игезәкләр, Ул миннән 10 минутка гына соңрак туган. Аның белән бер-беребезгә бик нык бәйләнгәнбез: бер үк вакытта авырыйбыз хәтта. Гел онытмыйм: армиягә киткәндә ярты йөрәгемне алып киткән кебек булган иде... Альбертның улы Саматны үземнеке дип тә саныйм бугай – ул тугач, балалар ярата башладым.

Кеше савыт кебек: үзенең күңел байлыгын, җан җылысын башкаларга өләшә икән, ул аны кире дә тутырырга тиеш. Шул ук кешеләр белән аралашудан, табигатьтән, китаплардан... Китаплардан алган фикерне син башка беркайдан да ала алмыйсың! Соңгы вакыт шигырьләр язгалыйм. Үзем өчен генә... Высоцкий, Цветаева, Ахматова шигъриятен яратам. Алар яшәгән чор ошый, сайлау мөмкинлеге булса – шул вакытта туар идем.

Татар телен шомартыр өчен дә миңа китаплар ярдәм итә. Әмирхан Еникинең хикәяләре, мәсәлән.

Эшкә җавапсыз карауучы, сөйләшкән вакыттан соңга калып йөрүче кешеләр ачуны чыгара минем. Тагын машинаның пычраклыгы, ир-атның аяк киеме тузанга баткан булуы...

Туры эфирда яңалыклар уку – күптән җайга салынган механизм инде ул. Берүзем эшләмим, нидер булса, ярдәмгә килүчеләр күп анда. Эфир вакытында төчкерүдән куркам менә, йөткерүдән. Фаҗигале хәбәр укудан. Көлеп җибәрүдән! Махсус күнегүләре бар – төчкерүне туктатып калып була, ә көлүне юк!

Принципиаль булуым, хаклык яратуым күп вакыт яшәргә комачаулый. Алдашу, ялганлау, ялагайлану тирә-юньдә шулкадәр күп – боларга кереп чумсаң, чын дөреслекне бөтенләй таба алмаячаксың. Үземә дә бары тик дөреслекне әйтүләрен телим. Шөкер, янымда андый кешеләрем бар.

Үземне меңнәр, миллионнар каравын онытырга тырышам. Минем максат – текстны дөрес, ялгышмыйча укып чыгу. Чөнки бөтен команданың эше миңа бәйле. Мин аны ниндидер катлаулы, затлы ризык пешерү белән чагыштырам. Унлап кеше аны көне буе әзерли. Ә халыкка тәкъдим итүне, чыгаруны сиңа ышанып тапшыралар һәм бер ялгышың – әзер бәлешне кулдан төшереп җибәрү белән бер бу! – бөтен команданың эшен юкка чыгарырга мөмкинсең... Алып баручы ялгыша икән, бездә «тапшыру килеп чыкмады» дип санала. Кайчак бер сүзне, хәтта бер хәрефне дөрес әйтмәсәң дә.

Танылуга әзер булу кирәк. Ул, беренче чиратта, җаваплылык өсти. Чөнки син зур команданың бер вәкиле, сиңа карап «Татарстан–Яңа гасыр» турында



фикер йөртәләр. Моннан соң инде урамда, кибеттә, ял иткәндә – беркайда да начар күренә алмыйсың. Ә гел матур күренү өчен вакыт кирәк. Монысы – танылуның минусы. Казанда «Мәскәү радио һәм телевидение мәктәбе» ачылды, шунда укытырга чакырдылар мине. Аны плюс дип санасак, гаиләгә бүләсе вакытның тагын кимүен минуска кертергәдер.

Алып баручы югалып калмаска, секундлар эчендә ниндидер карар кабул итәргә әзер булырга тиеш. Туры эфир бит ул! Әйтик, суфлер эшләми башлый, ди. Безнең алда тапшыруның сценарие ята. Эфирга кергәндә, кайсы биттә нинди сюжет ятканын мин якынча белергә һәм, кирәк булганда, кәгазьләрне актарып эзләп утырмыйча да аны табарга тиеш.

«Техника эшендәге җитешсезлекләр өчен гафу үтенәбез. Чыгарылышны дәвам итәбез», «Бу сюжетны соңрак күрсәтербез, ул әлегә эфирга әзерләнә» кебек берничә җөмлә бар. Без аларны яттан белергә тиеш. Исәнләшү һәм саубуллашу сүзләре дә суфлерга язылмый: чыгарылыш теләсә кайсы мизгелдә өзелергә, тәмамланырга мөмкин – син исә аңа нокта куя белергә тиешсең.

Сөйләм тизлеге кемгә ничек киләдер, миндә ул – тумыштан. Дулкынлансам, бөтенләй тиз сөйләшә башлыйм. Гомер буе «әкренрәк сөйлә», диделәр. Хәзер дә шуны ишетәм: эфир кабалануны яратмый.

«Татарстан–Яңа гасыр»га эшкә килгәч, беренче эфирга чыккан көнне бик яхшы хәтерлим. «Хәбәрләр» башланырга ярты сәгать кала урамга чыктым да, үз-үзем белән сөйләшәм: «Син бит моны үзең теләдең... Менә хыялыңа ирештең инде. Хәзер артка юл юк! Ышанычны акларга кирәк. Үзеңне кулга ал!» – дим. Дөресен әйткәндә, торып качасы килгән иде. Текстны өч сәгать алдан укырга тотындым, ә безгә эфирга алай озак әзерләнергә дә ярамый – ятлау сизелергә тиеш түгел. Курыккан эш хәерле була – ялгышмадым!

Хатын-кыз кайчакта еларга, шулай җиңеләергә, бушанырга тиештер ул. Мин дә кеше күрмәгәндә еш елыйм. Күз яше гел сагыштан гына тормый бит...

Һәр хатын-кыз кебек минем өчен дә иң мөһиме – гаилә. Без кияүгә бәхетле булу өчен чыгабыз. Бала ул бәхетне тагын да тулыландырачак.

Мин кайчакта ялгыз калырга, үзем генә булырга яратам. Ул миңа хәтта кирәк тә.

Экрандагы образымның нинди булырга тиешлеген җитәкчелек хәл итә. Мин аларга ышанам. Әлегә минем имидж – аксыл озын бөдрә чәчләр. Кистер дисәләр, чәчне кисәргә дә туры киләчәк. Киемдә дә чикләүләр шактый: студиянең фоны белән бертөсле пиджак, чуар, шакмаклы киемнәр ярамый. Шәхсән үземә шәмәхә, куе кызыл төсләр килешми. Хәтта минем өчен иннек төсен дә башкалар сайлый. Эфирга чыкканда зур колак алкалары, брошкалар, йөзекләр, сәгатьләр тагарга ярамый. Дөрес, Беренче канал алып баручылары тага башлады инде, бәлки безгә дә киләчәктә рөхсәт итәрләр. Элек тырнакларны кызыл төскә дә буярга ярамый иде әле, хәзер мөмкин менә.

Экраннан кырыс күренәсең, диләр. Мин чыннан да кырыс, таләпчән, иң беренче чиратта – үз-үземә.

Эшем аркасында шактый кызык кешеләр белән танышырга туры килә кайчакта. Журналист булмасам, католиклар чиркәве башлыгы Диогенис Уркиза атакай белән дә юлым беркайчан кисешмәс иде, мөгаен. Интервью алганнан соң, болай, сөйләшеп, аралашып утырырга дип, мин бары тик аның янына гына икенче тапкыр бардым. Акыллы, зирәк, фикерле кеше, кызганыч, аны хәзер Саратовка күчерделәр. Аның белән әңгәмә кору – испанчамны чарлау да булды. Матур тел бу! Берәр кайчан Испаниягә барырга һәм иркен итеп испанча сөйләшергә хыялланам. Кеше, ким дигәндә, ике чит тел белергә тиеш дип саныйм.

Тышкы матурлык беренче тәэсир өчен генә мөһим. Сөйләшкәч, аралашкач та, фикерең үзгәрмәсә, ул кеше чыннан да чибәр була.

Мәскәү каналларында алып баручылар башкалар язган яңалыкны гына укый, ә без үзебез дә сюжетлар төшерәбез. Һәр яңалыкның эчендә кайныйбыз: үземне беренче чиратта журналист итеп хис итәм.


Фамилиямнең холкыма да, язмышыма да тәэсире бар кебек тоям. Ул мине көчлерәк итә кебек.



Видео һәм язманың тулы варианты – сайтыбызда.







PRESSA.RU







«ТЫҢЛАГЫЗ, ТАЛЛИН СӨЙЛИ!»



Эльмира ЗАКИРОВА

ЭСТОН ҖИРЕНДӘ АРМЫЙ-ТАЛМЫЙ ТАТАР МИЛЛӘТЕНӘ ХЕЗМӘТ ИТКӘН БУ ФИДАКАРЬ ХАНЫМГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ РӘХМӘТ СҮЗЕ ИРЕШТЕРГӘНЕН БЕЛӘ ИДЕК ИНДЕ. АНЫСЫ – РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР АША... Ә ЭШЛӘГӘН ЭШЛӘРЕ ТУРЫНДА ҮЗЕ СӨЙЛИ.

Җәй ахырында редакциябезгә Таллинда яшәп ятучы Фәүзия һәм Равил Һадиуллиннар йөгереп кенә кереп чыкты. Алар инде «Татар-информ» агентлыгында да булганнар, журналистлар белән дә аралашканнар, «Казан утлары»нда да йомышлары бар икән... Тик Казан тикле Казанга кил дә, ничек инде «Сөембикә» редакциясенә кагылмыйсың, ди! Ашыгып кына, тизгә генә кереп исәнләшеп чыгу да безгә әллә никадәр яңалык, Балтыйк буенда яшәп ятучы милләттәшләребез тормышы сулышын җиткерде.

Мин Фәүзия сөйләгәннәрне блокнотыма терки барам, ә үзем: «Иркенләп язар өчен кабат очрашасы булыр», – дип уйлап куям...

Кара бу Фәүзияләрне! Сайтта Эстония татарлары турында әле бер яңалык, әле икенчесе... Менә генә «Беренче театр»ны куйганнар! «Алтын көз» ярминкәсен үткәргәннәр. Эстоннар безнең өчпочмак, чәкчәк, пәрәмәчләрне инде белеп бетергән, ди! Бер акцентсыз, нәкъ безнеңчә итеп әйтеп, пәрәмәчне сорыйлар икән!.. Әлеге хәбәр-яңалыкларны Фәүзия җиткергәнен чамалыйм инде. Аның тиктормас, тынгысыз булуын, милләт

өчен җан атып яшәвен бер күрүдә аңлап алдым. Рәхәтләнеп сөйли. Үзләренең җәмгыяте турында да, татарча «сатып җибәрә» торган 3 яшьлек оныгы турында да, сагынып кайтулары хакында да... Ара-тирә телефоны шалтырап ала. «Сандугач, мин Казанда, матурым», – дип, Фәүзия тәмле сүзләре белән кайдалыгын да искәртә: бу аның соңрак сөйләшербез дигән ишарәсе инде. Әле танышып, бер-ике кәлимә сүз әйтүгә үк, сөйләше безнең якныкына охшаганын шәйләп куйдым. «Үзегез кайдан?» – дим сүз арасында гына. «Сарманнан», – ди! Әйтәм бит, Минзәлә сөйләше әллә каян үзен сиздерә! Дүсем авылы кызы икән ул. Алабуга пединститутына укырга килгәндә Яхина Фәүзия булган әле. «Дүсем, Фәрит Яхин... Әллә сездә бар да Яхиннармы?» – дип көләм. Фәрит Яхин белән кардәшләр икән. Студент елларына да тукталып алабыз. Уртак танышлар килеп чыга... Ул чорда Фәүзия Түбән Кама районы Тоба авылы кызы Һадиуллина Наилә белән аеруча дус була. Наиләнең Равил исемле энесе бар икән... Эстониянең Тапа шәһәрендә хезмәт итүче егет апасына хатлар язганда Фәүзиягә дә сәламнәр юллый... «Шушы уңганбулган Фәүзияне үзебезнең килен итәсе иде!» – дип хыяллана Наилә һәм дустын энесе белән таныштыра. Ләшәү-Тамак мәктәбендә бер генә ел укытып кала Фәүзия. Көннәрдән бер көнне инде Эстониядә эшкә урнашып калган Равил, авылына кайтып, туй ясый. Күрше район кызы Фәүзия, ак мендәрләргә басып, килен булып төшә. Аннары Таллин тормышы башлана. 37 ел инде алар шунда. Равил Балтыйк буе республикаларында билгеле «Мерко» зур төзелеш компаниясендә эшли. Фамилиясе Эстониянең мактаулы төзүчеләре исемлегенә кертелгән. Кызлары Альбинаның да, уллары Ренатның да үз тормышлары. Альбина эстон теле укытучысы була, турфирмаларда да эшли. Албан егетенә кияүгә чыгып, бүгенге көндә Грециядә, Крит утравында яшәп яталар. Уллары Альберт үсеп килә. Ренат – спортчы, җилкәнле көймәләр спорты белән шөгыльләнә. Анысы Норвегиядә яши.

Фәүзия татар телендә яратып радиотапшырулар алып бара. Эстон телен дә өйрәнгән. Эстон мәктәбендә, лицейда башлангыч сыйныфларда – рус теле, якшәмбе мәктәпләрендә татар теле укыткан. Эстониядә 1 миллион чамасы кеше яши, шуның 2 мең ярымы татарлар икән. «Җирле халык татарларга аерым хөрмәт белән карый, безгә мөнәсәбәт әйбәт», – ди Фәүзия.

...Блокнотымда Фәүзия сөйләгән кызыклы мәгълүматлар шактый.

Таллинда яшәүче татар гаиләсе белән 1981 елда таныштык. Кибеттә бер бабай оныгы белән татарча сөйләшеп йөри иде. Кем булуларын сораштым. Рәшит ага Мәһди икән. Кайтышлый ук өйләренә чакырды. Ул үзе Таллинда туып-үскән. Әтисе Сәгъди бабай сәүдәгәр булган. Әнисе, Мөнирә исемле кызын алып, сугыш башланыр алдыннан Америкага китә. Мөнирә ханым «Азатлык» радиосыннан татар телендә тапшырулар алып бара иде. Әти белән аны тыңлаганым хәтеремдә. Рәшит абыйның хатыны Гатия апа – Актаныш районы Әҗәкүл авылыннан иде. (Октябрь аенда 97 яшендә бакыйлыкка күчте.)

Казанныкылар «килгән татарлар» төркеменә керә иде. Рәсәйнең башка шәһәрләренеке кебек. Ә Рәшит абый белән Гатия апа күбрәк эстон татарлары белән аралаша! Алар, әлбәттә, үзләрен шушы илнең хуҗалары итеп тоя. Әмма безгә карата да бик мәрхәмәтлеләр, кече күңеллеләр.

1987 елда беренче тапкыр татарлар җыелыша дигәч, шатлыгыбызның иге-чиге булмады.

Таллинда үз җәмгыятебезне оештырдык. Чит илдә иң бәхетле көннәребез иде бу! 30 елга якын милләттәшләребез белән аралашып, туганлашып яшибез. 150 ләп кеше җыелабыз. Үзара татарча сөйләшәбез. Дини бәйрәмнәрне бергә уздырабыз, җомга намазларына йөрибез. Сабантуйлар, әдәби кичәләр, спектакльләр, күргәзмәләр, конкурслар, газетага мәкаләләр, татар, эстон язучылары, рәссамнары белән очрашулар... Санап бетергесез бу чаралар – тормышыбызның матур бизәкләре. Иң зур хыялым – татар телен укыту иде. Якшәмбе мәктәпләрендә озак еллар укытырга туры килде. 1997 елда татар мәдәнияте өлкәсендәге хезмәтләрем өчен «Эстония хөкүмәтенең лаеклы гражданины» дигән мактаулы исем бирелде. Күптән түгел Кохтла-Ярведа милли гореф-гадәтләребезгә багышланган күңелле бәйрәм узды. Чигүләр, кызыл башлы сөлгеләр, татарның көнкүрешен чагылдырган әйберләр безне үз дөньябызга алып кайтты да куйды! Әйтерсең, без авылда. ТНВдан Ләйсәнә Садретдинова килеп, тапшыру да әзерләп китте ул бәйрәмнән. Нарвада Тукай кичәсе уздырдык. «Фәридә–Алсу» дуэты җырларын тыңладык.

Эстон телен өйрәнергә туган телем ярдәм итте. Эстон теле бик йомшак яңгырашлы фин-угор төркеменә карый. Кызыбыз Альбина университетның эстон филологиясе бүлегенә укырга керде. Мин дә шул ук уку йортының педагогика һәм психология бүлегендә читтән торып укый башладым. Эстон телендә татар сүзләрен табып, реферат яздык. Охшаш сүзләребез бик күп икән. «Мин», «син» алмашлыклары бер төрле яңгырый: «ä», «ö», «ü», «h» авазлары безнеңчә. Җөмлә төзелеше охшаш, грамматик бәйлекләр юк. Кызыбыз хәзерге көндә – сигез, улыбыз алты тел белә. Нинди генә хезмәт башкарсаң да, эстон теленнән имтихан тапшырып, тиешле категория алмасаң, эшкә урнашуың икеле. Эстоннар аз санлы булсалар да, үз телләрен энҗе бөртегедәй сакларга тырышалар. И-и-их, безнең татарда да күбрәк булсын иде андый сыйфатлар!

«Дуслык» радиосы юктан гына барлыкка килмәде. Озак еллар «Көмеш чылбыр» циклында рус телендә

PRESSA.RU

тапшырулар яздырган идем. Тукайга, Җәлилгә, Казан тарихына багышланган тапшыруларны ничек әзерләгәннәрем һаман күз алдында. Ә берчак Таллинга Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Мөхәммәт Мәһдиев, Тәуфыйк Әйди, Равил Фәйзуллиннар килде. Алар бүләк иткән китапларны иң кадерле ядкарь итеп саклыйм. Университетта лекция барганда Тукай турындагы тапшыруым эфирга чыгасы иде, профессор үзенең лекциясен туктатып торып, студентлар белән бергәләшеп тыңлау җаен тапты. 2011 елда «Радио 4» дигән үзәк өч атнага бер тапкыр яртылаш татар һәм рус телендә тапшырулар оештырырга тәкъдим иткәч, тәвәккәлләп үзем алындым. Булдырырмын кебек: пединститутта укыганда «Укытучы» газетасының редакторы идем бит! «Татарча сөйләшә торган милләттәшләребез бик күп, гел татар телендә алып барыйк», – дигән үтенечемә директор да, тавыш режиссеры да каршы килмәде. Күк капусы ачылгандай булды! Без аны «Дуслык» радиосы дип атадык. Инде биш ел эшләп киләбез.

Безне Европадагы бөтен дусларыбыз тыңлый.

«Тыңлагыз, Таллин сөйли!» Тапшыруларымны әнә шулай саф татарча башлап җибәргәндәге горурлануларым! Телебезне, мәдәниятебезне саклау, дин, әхлак темасына да сөйләшәбез, язучыларыбыз иҗаты белән дә таныштырабыз. Темаларны сайлаганда милләттәшләрем белән киңәшәм, аларны төрле әңгәмәләргә чакырам. Бик кызыклы тапшырулар бар архивта. Күп язмаларымны бирелә яшәүче татарларга багышладым. Арабыздан бакыйлыкка китеп барган ышанычлы терәгебез Даян Әхмәт турында тапшыруны яздырганда, күз яшьләремне тыя алмыйча, озак кына тынычлана алмый утыруым истә. Бөтен уй-кичерешләрне, истәлекләрне барлаганда кылдан нечкә күңел кыллары сыкрамый калмый. Бу – авыл баласының табигый халәте. Нечкә күңелле булуымны белгән режиссер Галина Малютина тавышым үзгәргәнен шундук тоеп ала. Бергә эшләү дәверендә ул инде татарча аңлый башлады.

Европа Татар альянсы оешкач, офыкларыбыз тагын да киңәйде. Туганнар кебек аралашып яшибез. Рига, Вильнюс, Клайпеда, Брюссель, Гданьск, Париж, Брно, Вена, Прага шәһәрләре дә Казан, Таллин, Нарва, Кохтла-Ярве, Пярну кебек бик якын күңелгә.

Туган якларга кайтмый торсаң, сагынып үләрсең! Ике ел саен кайтып торабыз. Быел менә тагын кайттык. Авылдашларым матур очрашу оештырды. Рәхәт итеп аралаштык. Кайчандыр әнкәй йөреп ачтырган Мәдәният йортында «Бер күрешү – бер гомер» дигән очрашуда утырдык. Җырчы кызлар күңелнең әллә кайсы кылларына кагылырлык итеп җырладылар. Күз алдымнан балачагым йөгереп үткәндәй булды. Дүрт бала арасыннан иң шугы булсам да, бик иркәләп үстерделәр мине. Әти өч кызына да күлмәкләргә кадәр үзе текте, йомшак итекләр басып кидерде. Чәчем бөдрә булганга, әкрен генә үзе кыскартып кисә, тарый иде әти. Аның белмәгән эше юк. Оста гармунчы, җырчы булуы белән әниемне дә гашыйк иткән әле!

Казан танымаслык булып үзгәргән. Искитмәле! Ул урамнар, яшеллек... Мин Таллинга киткәндә Казан ханлыгы тарихларын өйрәтмәделәр. Тарихыбыз белән кызыксына, Сөембикә бәетләрен укый башлагач кына, күзләребез ачылды. Михаил Худяковның Казан ханлыгы турындагы китабы кулыма килеп эләкте дә, шаккатып укып чыктым. Татар булуым белән горурланып йөри башладым.

Кайсы илдә яшәсәң, шул халыкның телен белергә тиешсең. Эстониядә олысы-кечесе эстонча сөйләшә! Без дә килү белән үк өйрәндек. Телебезне дә югалтмадык. Ә бездә руслашу процессы бара икән. Сарманда кибетләрдә татарча сорыйсың, русча җавап бирәләр! Ошамады инде! Китап кибетендә татар китаплары бүлегенә керәм. Татарча сорыйм, русча җавап ишетәм. Аңлый бит инде югыйсә! Җавап бирергә ояламы, әллә сүз байлыгы шуның кадәр генәме – һич аңламадым. Гаҗәпләндергәне – авылда да, «папа», «мама» дип, русча сөйләшеп йөриләр бит. Кайткач, туганнарымны да сүгеп аттым әле. Авылларда татар мәктәпләрен бетерергә ярамый. Мин укыган мәктәпнең матди базасы бик яхшы иде. Соңыннан балаларны, автобуска төяп, укырга башка авылларга йөртә башладылар. Бик кызганыч, әлбәттә.

«Үзең сакламагач, телне мылтык тотып саклап булмый!» Ирем Равил ТНВ каналын карап утырганда шулай диде. Студиядә җанга ятышлы әңгәмә бара иде. Телне саклау мәсьәләләре турында сөйләшәләр. Былтыр улым Лаешка ярышларга кайткан иде. «Капкалап алырга кергәч, ике өчпочмак сорадым. Сатучы үзе татар кызы, үзе: "Вам два треугольника?" – дип, русчалап кайтарып сорап тора. «Юк, миңа ике өчпочмак бирегез!» – дип әйттем», – дип гаҗәпләнеп сөйләгән иде.

Таллинда хәтта татарлар урамы да бар. XVIII йөздә үк татарлар Эстониягә килеп урнашкач, мәктәпләр оештырганнар, мәчетләр төзегәннәр, татар зиратлары булдырганнар. Кадриорг паркында борынгы бер йорт бар. Татарлар яшәгән анда. Сәүдәгәр татарлар йорты дип тә йөртәләр аны. Бөтен бәйрәмнәрне шунда уздырабыз. Үзебезнең фатир Теллискиви урамында. Күршеләребез эстоннар безнең. Сабантуйларда кигән милли киемнәребезне күреп, кызыксыналар. Әле менә соңгы арада «Идегәй» тарихи героик-эпик поэмасын эстон теленә тәрҗемә итү мәсьәләләре белән йөрибез. Ул китапны матур итеп бизәп чыгарырга кирәк. Бар ике кеше: берсе Артур Лааст – татар халкының тарихын, әдәбиятын, борынгы әсәрләрен өйрәнгән, төрки теллардәге әсәрләрне эстон теленә тәрҗемә итү өлкәсендә билгеле бер тәҗрибә туплаган галим; икенчесе шагыйрь Пеетер Илус.

Хельсинкига утырмага барып кайту берни түгел. Ике сәгатьлек юл анда. Чәй мәҗлесләренә чакыралар

еш кына. Финляндиягә чыгып керәбез шулай. Аяз көндә Таллиннан диңгез аша карасаң, еракта-еракта Хельсинки йортлары шәйләнә хәтта.

Бала баласы балдан татлы икән шул! Оныгыбыз Альбертны әйтәм. Нәни философ кебек инде ул. Татарча, грекча, эстонча, албанча сөйләшә. Белмәгәне юк. Уйлавы – татарча. Кызыбыз албан егетенә кияүгә чыккач, борчылган идек. Киявебез тырыш, тәрбияле, акыллы булып чыкты. Безгә татарча эндәшә башлады. Бала тууга ике телдә дә сөйләшер, дип вәгъдә иттеләр. Кызым авырга узу белән Криттан Эстониягә кайтты. Бала тудыру йортында бергә «тулгак тотып», икәүләшеп таптык сабыйны. Тәһарәтләремне алып, сабыйның кендеген үзем кистем. Мин аның кендек әбисе дә әле! Теле бик иртә, унбер айдан татарча ачылды. Кызык сүзләрен дәфтәргә терки бардык. Йомшак йомгагыбызны гел җырлап йоклатабыз, әкиятләр укыйбыз. Иң бәхетле мизгелләр инде бу өйдә! Уйнамаган уен калмады! Крит утравы яры буенда «Чума үрдәк, чума каз»ны Альберт белән кычкырып җырлап йөреп, милләттәшләребезне дә таптык әле. Бик бәләкәй булса да, йоклар алдыннан гел айны күрсәт дип сорый иде. Болыт капласа, төрле әкиятләр уйлап чыгарабыз. Йомры ай, түгәрәк ай, урак ай, көләч ай... «Бүген нинди соң бу ай?» – дип сорасаң, әйтә дә бирә. Бер могҗиза икән оныкларны үстерү! Әби-бабайлар, әти-әниләр дә нечкә күңелле итеп үстергән безне. Татлы, матур сүзләр генә ишетә идек алардан. Бер тапкыр да тавыш күтәреп эндәшкәннәре булмады. «Су анасы» белән «Шүрәле» куркыныч әкият бит. Ник ошый икән миңа алар?» – дип сорый оныгым берчак. «Тукай язганга», – дип аңлатам. Зөһрә кыз турындагы әкиятне сөйлим, бераз тыңлый да, «юк, «Су анасы»н сөйлә», – ди башлый. 3 яшь ярымлык балада хәйлә дә бар. Гадәттә, «бабай» дип эндәшә, кирәк әйбере булса, «бабам»га күчә. «Бабай, син беләсеңме, суыткычта шоколад озак торса, бозыла икән, – дип ерактан башлый да сүзен, – бабам, бер шоколад бир әле!» – дип тәмамлый. Әйе, әйе, суыткыч, туңдырма ди. Шигырьләр, табышмаклар күп белә. Әле бу кайтуымда да бер чемодан китап җыйдым шул балага. Бабасы барып килер инде яннарына.

Эстония телевидениесендә дә татарлар турында күп мәгълүмат чыга.

Сабыйда туган телгә мәхәббәт уяту ана карынында ук башлана. Дөньяга яңа күзе ачылган сабый чит сүзләргә мохтаҗ була димени? Әти белән әни безгә соңгы сулышларын алганда да «бәбекәм» дип эндәштеләр. Балага гына әйтә торган сүз бит югыйсә. Бу тылсымлы сүз гомер буе диңгез ягыннан искән салкын җилләрдән саклады, чит илдә сагыну сагышыннан тамган күз яшьләрен матур хискә әверелдерде, туры һәм тугры юлыбызны табарга ярдәм итте.

«Хәерле көн, милләттәшләр!» Мин борынгы Таллинның үзәгендә, яраткан эшемдә утырам. Халкыма үз туган телемдә сәламемне, уй-фикерләремне җиткерәм, җыр-моңнарыбызны ирештерәм. Чикләр, диңгезләр, илләр аша үтеп, эфир дулкыннары газиз сүзләребезне, әткәм-әнкәм телен ерак-еракларга алып китә.



ЛИДЕР СРЕДИ РАДИОСТАНЦИЙ ВЕЩАЮЩИХ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ*

*По данным ЗАО «ТНС ГЭЛЛАП МЕДИА» («TNS Gallup Media»), отчет от 27.09.2016 г. По договору №К048/2016 от 1 августа 2016 г.

**Казань 100,5 фм

РЕКЛАМА

PRESSA.RU



ГАДӘТТӘ, ВАЗЫЙФА КАМЫТЫН КИЕП ЙӨЗ КӨН УЗГАЧ, БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘР ЯСАЛА.

2016 елның 25 июнендә Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе вазыйфасына Данил Салихов сайланды. «Сөембикә» журналында урнашкан традиция буенча, без яңа җитәкче белән абунәчеләребезне ел азагында таныштырабыз. Сезнең хозурда – Данил Хәбибрахман улы САЛИХОВ!



Асия ЮНЫСОВА

ЯЗУЧЫ – МИЛЛӘТ ИЛЧЕСЕ

Данил әфәнде, ялгышмасам, син унөченче рәис бугай. Татар өчен бәхетле сан инде бу. Синең элгәрләреңнең һәркайсы бу урынга килгәндә, мин халыкка, бигрәк тә язучы халкына, хезмәт итәчәкмен дип килә булыр. Канлы заманнарны да кичкән, данлы дәверләрне дә күргән татар әдипләрен ни белән кинәндерергә уйлыйсың, Данил? Ни нәрсәләрне максат итеп килдең?

– Беренчедән, мин әфәнде түгел. Ягъни каләм әһеленең хезмәттәше. Әмма терәге, таянычы була алырмын дип тә өметләнәм. Дөрес, язучыны язарга өйрәтеп булмый. Аннары өйрәтә, киңәш бирә башласаң, аның бик тиз хәтере калырга да мөмкин. Минем иң олуг максатым – язучыга карата якты карашны, хөрмәтле мөнәсәбәтне тергезү. Икенчедән, хөкүмәт белән язучы арасындагы күперне ныгыту. Язучылар берлеген сәяси оешма итәргә тырышуларга да каршы мин. Унөч саны, чыннан да, бәхетле сан ул. Миңа кадәр эшләгән рәисләргә рәхмәт. Туфан Миңнуллин зиннәтле бина алып калдырган иде. Аннан соң сайланган рәисләр яхшы ремонт ясатуга ирештеләр. Язучылар берлеге корабын сәяси диңгез рифларына бәрдерми генә исән-сау, таркатмый алып чыга алдылар.

Язучының җәмгыятьтәге урынын тергезүне яңа рәис нидән башларга уйлый икән?

– Монысы, өченчедән, дигәне булыр инде. Пропаганда бүлеген тергезербез дип торам. Халык арасына чыкмый булмый бит инде. Моны кемдер башлап йөрергә, сөйләшүләр алып барырга, маршрутлар сайларга тиеш. Язучы – милләт илчесе бит ул. Туган халкының кайда, ничек яшәгәнен күрми, белми торып, язучы ни рәвешле илче була алсын?! Әйтик, язучыларның туган якларына сәфәрләр аша Башкортстанда, Удмуртиядә, Чуашстанда яшәүче милләттәшләребезнең хәлен белә алыр идек.

Милләт хәлен белү генә аз. Туган ягына язучының иҗатын гына түгел, шәхесен дә алып кайту зур нәрсә ул. Менә бит нинди хәл: Такташ татар язучысы йөрәгенә ничек кенә якын булмасын, Сыркыды авылы ерагайды. Фатих Кәримнең Бишбүләге дә җырда гына калып бара. Исхакыйның Яуширмәсенә дә сәфәрләр сирәгәйде. Тора-бара Оренбургтагы Мостафага – Җәлил төбәгенә барулар да туктап калмагае. Татар әдәбиятына зур-зур әдипләрне биргән, җырларыбыз, риваятьләребез, әкиятләребез, каһарманнарыбыз уртак булган карендәшләребез яшәгән Башкортстанны да үз итәргә кирәк! Данил Салиховтан бераз алдарак булган узаманнарыбыз, тугандаш әдәбиятлар дигәннән, төрекләрне, казакъларны күздә тоталар иде кебек.

– Дөрес, безгә иң әүвәле үзебезнекеләрне барлыйсы, туплыйсы бар. Төрек тә, әзәрбайҗан да ят түгел анысы. Бөтен төрки дөнья әдәбияты хәл белешеп, аңлашып, бер-берсенең иҗатын белеп, бәяләп яшәр көннәр турында хыялланам мин. Егерменче йөз башында шулайрак булган да бит.

Ниятләрне чынга ашырыр өчен Язучылар берлеге рәисе республика җитәкчелеге белән аңлашып эшләргә тиештер дип беләм.

– Әлбәттә, шулай. Президент Рөстәм Миңнехановның яңа сайланган рәисне икенче көнне үк кабул итүе үзе дә күп нәрсә хакында сөйли. Ул безгә ярдәм итәргә әзер. Күп нәрсә язучылардан тора. Иҗатыбыз заманга лаек кимәлдә булырга тиеш. Һаман кичәге идеаллар белән яшәп яту, балачагыңны гына сагыну, колачлы итеп фикер йөртергә әзер булмау безнең әдәбиятны бер урында таптанырга мәҗбүр итә. Без хәтта ирешелгән үрләрне дә «тапшырабыз» бугай. Узган гасыр корифейлары – Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Галимҗан Ибраһимов, Аяз Гыйлаҗев, Нурихан Фәттахлар йолдызлыгы әле һаман иң якты йолдызлык.

Ә драматург Данил Салиховның «йолдызы» кем?

– Туфан Миңнуллинны бик сагынсам да, хөрмәт итсәм дә, «йолдыз» дигәч, Нәкый Исәнбәт диясем килде.

Президент белән татар язучысының матди хәлен яхшырту хакында да сөйләшкәнсез булыр. Хәзер инде торак мәсьәләсе кузгатылмый бугай. Әлеге дә баягы, каләм хакы, ял итү тирәсендә сүз куергандыр. Бәлки әле, лаек дип табылган каләм ияләренә гомергә бер бирелә торган премияләр күләмен арттырырга вакыт җитте, дип тә әйтеп куйгансыңдыр. Ни дисәң дә, Тукай премиясе 60 меңнән 500 меңгә күтәрелде. Ә Такташ, Хөсни, Алиш премияләренең сумасы һаман элеккечә кала бирә. Премия күләме язучының учы акча күргәнлеген тоярлык булырга тиеш ләбаса!

– Бөтен сөйләшкән сүзләрне дә түгеп салырга җыенмыйм. Премияләр сумасын күтәрү хакында уйлашабыз. Иҗат йортын асрау кадәресе дә Мәдәният министрлыгы өчен артык зур чыгымлы нәрсә. Ә менә тендер откан шифаханәләргә юлламалар санын тагын ишәйтеп, аларны бүлүдә гаделлекне саклап булыр кебек. Аккош күлен кузгатырга уйласаң, ул хәзер милекчеләр кулына күчеп бетте инде. Бу хакта сөйләшү урынсыз. Ә менә татар китабын укучыга ирештерү юнәлешендә сөйләшергә кирәк. Китап сату нокталарын күбәйтәсе иде бит. Бу эшкә дәррәү тотынсак кына инде. Әле күптән түгел генә дүрт язучы – Нәбирә Гыйматдинова, Рифә Рахман, Ләбиб Лерон һәм мин Екатеринбургта, Свердловск өлкәсендәге авылларда йөреп кайттык. Зур-зур татар авыллары татар китабына зар-интизар булып яшәп яталар. «Китап җибәрегез безгә!» – дип гозерләнделәр. Китаплар җыйнап куйсак, килеп алырга да ризалар. Андый авыллар, төбәкләр никадәр бит! Шул гамәлгә тотынырбыз, мөгаен. Һәр кеше үз авылын шефка алса да ярый, дип беләм.

Данил Салихов бу җәһәттән бәхетлерәк. Ул язган 33 пьесаның һәркайсы спектакль рәвешен алып, адресатын эзләп таба ала. Инде менә үзеңә прозаик язучы «күлмәген» дә үлчәп карадың. «Казан утлары» журналында «Чукрак» дигән пьесаңның роман вариантын укыдык.

– Ие шул. Гариф Ахунов белән Аяз Гыйлаҗев бу пьесаңны роман итеп яз син, Данил, дип кодалаганнар иде. Мин иҗат дөньясына сәхнә кешесе булып аяк баскан идем. Баритон тавышлы Актаныш егетен җырчы итеп күрергә теләүчеләр арасында Мәсгуть Имашев та, Зөләйха Хисмәтуллина да булды. Ә мин музыка училищесын ташлап, Марсель Сәлимҗанов кул астында драма сәхнәсе серләрен өйрәнергә киттем. Остаз мине Камал театрына чакырды. Ничек инде бармыйсың?

Синең пьесаларың, спектакль булып, Татарстан чикләрен атлап чыкты. Хәтта Дагстандагы Ногай театры да уйный икән. «Миңлекамал»да Вера Минкина гына уйный торган Малай ролен уйнап башлаган егет инде зуп-зур драматург булып үсеп җитте. «Пуля»ң белән, әнә, Санкт-Петербургта да кызыксынучылар бар икән. Инде исеме танылган драматург җитәкчелек сыйфатлары белән дә иҗат берлеге тарихында матур эз калдыра күрсен иде!

PRESSA.RU

Таңчулпан... Шундый исемле хатын-кыз, әлбәттә инде, шигырь дөньясыннан буладыр. Әйе, шулай! Һәм нинди генә шагыйрә әле!
Укучылар Чулпан ӘХМӘТОВА дигән журналистны кыю язмалары, гадел бәяләре, туры сүзләре белән хәтерлидер.
Дәүләт хезмәтендәге даими эше исә бик тә җаваплы һәм тынгысыз: Татарстан Республикасы Дәүләт Советының матбугат үзәгендә Чулпан Шәрип кызы массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән эшли, парламент белән матбугат арасындагы бәйләнешкә җавап бирә.
...Ә күңелдә барыбер хыял, сөенеч, сагыш, ярату шигырь булып яна!









ТАҢЧУЛПАН



КҮҢЕЛЕМДӘ – БОЗЛЫК ЧОРЫ

Бозлык чоры

Туңгандыр, – дисең, – йөрәгең,
Бәлки чындыр, туңгандыр...
Күңелемдә – бозлык чоры,
Язлар чорым узгандыр...

Кырыс дөнья кыршавында
Яралардан сулгандыр.
Ялганмагач яралары,
Үлмәс өчен туңгандыр.

Туңган йөрәк – тынган түгел,
Бәлки бер эрер әле.
Миңа баккан күзләреңдә
Мәхәббәт күрер әле.

Миндә әле – бозлык чоры,
Бәллүр боздай күңелем.
Үзем дә көтәм шул бозның
Челпәрәмә килүен.

Хыянәт

Төне буе күктән йолдыз яуды,
Кемдер туды, кемдер өзелде,
Күзем алмый көттем, иптәш итеп
Күзгедәге ялгыз үземне.

Төне буе күктән йолдыз яуды,
Яңгыр булып юды күңелне.
Җан ярасы әрнеп, сыкрап, сызлап,
Йолдыз яңгырына күмелде.

Төне буе күктән йолдыз яуды,
Гөрләвекләр генә акмады...
Әче таңда,
Йолдыз эзләренә баса-баса,
Җирән ата мәче атлады.
Нәкъ синеке иде атлавы.

* * *

Тагын бер ел гомер үтеп китте...
Мәңгелеккә табан атлаган.
Үткәннәрдәниләр күрмәгән дә,
Югалтмаган, ниләр тапмаган.

Тагын бер ел гомер үтеп китте...
Сизелми дә калды, тоймадым.
Авырлыклар булса – калды артта,
Мин яшәүдән әле туймадым.

Тагын бер ел гомер үтеп китте...
Өтер куйдым, нокта куймадым.
Яшьлек дәрте җанны уйнатканда
Сөю, сөелүдән туймадым.


Тагын бер ел гомер үтеп китте...
Тәү мәртәбә сиздем узганын.
Йөрәккәем минем, бәгырькәем,
Озак типче, яшәп туймадым.

* * *

Нәрсә языйм?
Нинди сүзләр табыйм –
Йөрәк тавышына торырлык...
Җанга яңгыр яумый,
Кар да төшми –
Җанда икән зәһәр корылык...
– Ничек хәлең? – диләр...
Белсәм икән,
Булса икән шуңа җавабым...
Ком чүлендә калган дәрвиш кебек,
Арта гына бара газабым.
...Карсыз булды инде бу кышлары,
Яумас кебек яңгыр язда да...

* * *

Ник уяттың мине,
Татлы итеп
Таң йокысын йоклар чагымда?!
Төшләремдә килеп, иңнәремә
Йомшак итеп кулың салдың да:
– Әйдә, бәгырь, – дидең,
Чыклар ярып,
Иңләп кайтыйк елга буйларын...
...Сине юксынганда ялгыз гына
Яр буйларын мең кат урадым,



Агыйделдә йөзгән көймәләргә
Мин хәерле сәфәр юрадым.
Килерсең күк иде...
Яшьлегебез
Кайтарыр күк иде эндәшеп.
Мең сөюгә шаһит өянкеләр
Безнең мәхәббәтнең барлыгына,
Сафлыгына, садәлегенә
Сокланып һәм бераз көнләшеп
Шауларлар күк иде...
Сөйләрләр күк иде җилләргә:
Дастан итеп илгә сибәргә.
Кайталмадың...
Төшкә генә кердең...

Син киткәнсең...

Ф...гә!

Син киткәнсең...
Хәбәр генә килде,
Китүеңне үзем күрмәдем,
Тик шулай да йолдыз арасыннан
Күзләреңне эзли күзләрем.

Сагынмыйм да кебек инде үзем,
Өзек иде күптән аралар.
Тик җанымда җөе генә калган
Сиңа бәйле татлы яра бар...

Син киткәнсең...
Саубуллашмый-нитми,
Юри генә киткән шикелле...
Булмас инде язда очрашулар –
Тик бер якка гүрнең ишеге.

Синең белән,
Белмим, нидер китте...
Әллә сынды, әллә өзелде...
Аяз көндә «кояш тотылдымы» –
Караңгылык басты күңелне.

Тик җаныма бер тынычлык иңде –
Бакый дөнья яктырактыр инде...

* * *

Күңелемдә күптән давыл тынган,
Ярларына кайткан ярсуым.
Тыныч кына гомер иткән мәлем,
Бер могҗиза итми кар суын...
Яшим дә күк, яшәмим дә сыман,
Язлар җәйгә, көзгә тоташа,
Елларның да иске-яңасы юк,
Гомер үтә шулай тоташтан.
Әмма бүген әллә нишләп киттем:
Бәгыремне өтеп өн килде:
Язда ярсып, җәйләрендә җилсеп
Яшәмәгәч гомер ник кирәк?!
Сискәндерде җанны.
Тамырларда
Кан агышын тойдым.
Мин исән!
«Яшьлек әле үтеп бетмәгән ич,
Канат итеп җилне кил!» – дисәм...
Ишетерме берәү?
Давыл тынган,
Ярларына кайткан ярсуы,
Әллә нигә иләс-миләс итә
Бу язларда көмеш кар суы...

Үтеп барышым

Керфегемнән ап-ак карлар үбә,
Күзләремдә көзләр сагышы,
Бертуктаусыз аккан болыт булып
Минем Җирдән үтеп барышым...

Бәйләнәсем килә кыяларга
Билбау итеп саба җилләрен.
Әллә ничек, һич сиздерми генә
Уза икән гомер дигәнең...

Ышык эзлим – килеп кунар өчен,
Тояр өчен кемдер җылысын...
Бер өн килә бәгыремне өтеп
«Тукталырга инде, инде соң...»

* * *

Сорап куйды берәү:
 – Киләме? – дип, –
Яшьлегеңә кире кайтасың?

Яшьлегемнән бага
Яшел күзле,
Сары чәчле садә Кыз бала.
Кыз баланың алларында упкын –
Чү-чү, кызый, зинһар, кузгалма...
Япа-ялгыз кала уртасында,
Япа-ялгыз язмыш ярында.
Чарасыздан кылган гамәлләре,
Белмим, кайсы иңгә языла...
Күңелендә сөю бөреләнгән,
Күзләрендә наз һәм яз гына.
Бәхет өчен күп кирәкми Кызга,
Бәхет өчен кирәк аз гына.
Яшьлегемнән бага
Күз яшьләре
Чишмә булып аккан кыз бала.
Һәр тамчысы тулы әрнү, рәнҗү,
Кемгә төшәр яшең, и бала?...
Хыялларның канатлары талган,
Җан төбендә канлы яралар...
Сабыр булчы, Кызый,
Вакыт дигән
Галиҗәнап доктор дәвалар.
Уйларымны өзеп,
Тезләремә
Нәни кызым килеп сарыла...
Яшьлегемә кайтмас идем, Ходам,
Бүгенгемнән мине аерма!

* * *

Кышкы урман.
Ауган нарат,
Нәни генә учак яна.
Төтен үпкән күзләремә,
Яшьле күзләремә кара.
Төтен сарган керфекләрем
Сөюемә пәрдә түгел,
Учакка да, җаныма да
Күмер төшә,
Утлы күмер.
Бер күмердә кыза шашлык,
Икенчесе җанны өтә.
Сыкрап янган иреннәрем
Синең иреннәрне көтә.
Корымланган бармакларың
Берәм-берәм «тешләп үбәм».
Ике ара – нәни учак,
Ялкынланып янган пүлән.
Учак яна.
Төтен пәрдә
Яшерә күк чит күзләрдән.
Син янымда була торып,
Дөнья гизеп ни эзләнгән?
Ни эзләнгән?
Табылмаган...
Әрнү саркый яралардан.
Яраланган йөрәгемне
Янә ялкын чорнап алган.
Утка очкан күбәләктәй
Талпынамын сиңа һаман.
Нәрсә көтә?
Кылганыма
Никадәрле җәза калган?
Учак яна,
Уйлар ага,
Җанда ябылмаган яра.
Төтен үпкән күзләремнән –
Яшьле яшел күзләремнән
Син үзеңне эзләп кара.

PRESSA.RU

Редакциянең электрон почтасына килгән хикәяләр арасында бер авторыбыз иҗатына аеруча игътибар иттек. Свердловск өлкәсендә яшәүче Физалия Дәүләтгәрәева икән ул. Башкортстанның Борай районында туып-үскән кыз, әдәбият укытучысы Нурия апасы Солтанова дәресләреннән илһамланып, иҗат дөньясына тартыла. Унынчыны тәмамлагач, Свердловск туку комбинатына эшкә урнаша, җиңел сәнәгать техникумында укый. Соңрак болар барысы да хикәяләрендә үз урынын таба. Матбугатта еш басыла. Шигырьләренә байтак җырлар язылган. Хикәяләре китап булып дөнья күргән.



Физәлия
ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВА

ЯҢА ЕЛНЫҢ ЯҢА КАРЫ

(Хикәя)

Күбәләкләп яуган кар бөртекләрен затлы тун якасын кагыштыра-кагыштыра, Адель үз урамына табан борылды. Яңа ел табынына куярга дип алынган тәмле-татлы ризык тулы сумкасы шактый авыр гына. Ул аны арыган кулыннан икенчесенә күчерде дә якасын янә каккалап алды – өр-яңа затлы киемен әрәм итә инде бу туктый белмәс җепшек кар. Яңа ел каршыларга берничә сәгать кенә вакыт калды. Чыршылар күптән бизәлгән. Табыннарның тулы, мул чагы. Күңелләрен бәйрәм кәефе кытыклап торган кешеләр өйләренә ашыга. Кемдер кунаклар көтә, кемдер үзе кунакка бара. Адельнең дә көтәр кешесе бар... Бу кичә онытылмаслык булырга тиеш! Ул бүген, һичшиксез, Жорикның күңелен яуларга тиеш!

Светофорда урам аша чыгарга дип торганда кемдер аңа кар йомарламы тондырды. Ачуланыргамы, кисәтергәме белмичә, муенын борып караса – кар йомарлап токкан ике малай бер ирне куалый. Ә тегесе, көлә-көлә, һөҗүмнән качып, йә бер якка тайпыла, йә икенче якка чаба. Аларга якынлашып килгән хатынның кисәтү катыш шат тавышы Адельгә таныш тоелды:

– Чү, дим сезгә! Ишетәсезме? Кешегә тондырасыз бит! Кирәгегезне бирәм хәзер!

Адель янына килеп баскан хатынның йөзенә күз салса... Бәй! Бер мәктәптә, бер сыйныфта укыган Рәзидә түгелме соң? Элек тә артык зифа буйлы түгел иде, хәзер тагын да юанаеп киткән! Дәшәргәме-юкмы дип икеләнеп торганда, Рәзидә аны үзе танып алды:

– Әдилә! Классташ! Сәлам!

Адель җавап бирергә өлгермәде, светофорның яшел уты кабынды. Рәзидә бер читтә һаман да куышып уйнаган малайларын әйдәп кул изәде дә, классташын очратуына сөенә-сөенә, янәшәсеннән атлады:

– Әдилә! Бер шәһәрдә, күрше урамнарда яшибез! Очрашканыбыз юк! Хәлләрең ничек?

Адель, әйе шул, әйбәт, бер дигән, кебек кыска-кыска җаваплар бирде. Мәктәпне, классташларын искә алып, берничә минут чатта басып тордылар да, ешрак очрашырга сүз куешып, һәркем үз юлыннан китте. Бераз атлагач, Адель артына борылып карамыйча түзә алмады. Рәзидә – ир хатыны, ике бала анасы, өченчегә авырлы утыз алты яшьтәге хатын – кулына кар йомарламы тотып, чыркылдап көлә-көлә, ире, ике улы белән куыша иде. Сыйныфташын очратудан уянган хатирәләре күңелен айкады Адельнең. Адель түгел, ә Әдилә булган саф, ваемсыз чакларына кайтасы килеп китте. Артык чибәрлеге булмаган, кеше алдында авыз ачып сүз

әйтергә дә оялган Рәзидәнең тулы бәхетенә гаҗәпсенеп тә куйды. Хәер, гаҗәпсенеп кенә микән? Үзен читләп үткән бәхет кошының аңа түгел, ә Рәзидә иңенә кунуына көнләшмәде микән? Хәтта кәефе дә төште кебек. Көнченең күңелен ят бәхет яндыра түгелме соң? Күңелен көнчелек корты кимергәнен танышйсы килмәде. Һи! Нигә көнләшим әле мин аннан? Кредиты түләнмәгән фатирда яшәп ятуынамы? Тау хәтле бурычың була торып, ничек үзеңне бәхетле тоймак кирәк? Өч бала үстерәсе барлыгыннан көнләшергәме? Шулай да Адель үзе өчен анык аңлады – Рәзидә аның кебек ялгыз түгел иде. Аның тормышында сөекле ире, ике баласы, карынында йөрткән нәние бар. Рәзидәнең бәхете алардан тора. Алар әнә Адельнең затлы якасына кунып бимазалаган шушы җепшек карга да сөенә, балаларча куана беләләр... Ә Адель кыйммәтле тунын бозарга курка. Кырыкны куып барсалар да, күңелләрендә йөрткән баланы ирекка чыгарып, куышып уйный, шаяра алалар.
Ә Адель гомер буена үзе куйган кысаларда кысылып яшәде – бу ярамый, теге килешми, бу матур түгел... Ә алар, гомер буе түләячәк кредитлары, баштан ашкан тормыш мәшәкатьләре булып та, бәхетле була беләләр. Бәлки, шуларны бергә-бергә җиңә белеп яшәүдәдер аларның бәхете, кем белә?

Рәзидә хакындагы уйларын җепшек кар белән коеп төшерергә теләгәндәй, Адель тагын бер кат кыйммәтле тунын каккалап чистартты да фатирын ачып керде. Бетте, җитте бу Рәзидә турында! Тиздән Жоригы киләчәк! Бүген барысы да ачыкланачак! Дүрт ел буена очрашып йөрүгә йә нокта куелачак, йә Жорик аңа тәкъдим ясаячак! Бу икеле-микеле мөнәсәбәттән Адель күптән туйды. Хатыны, улы-кызы булса ни, икенче гаилә кору бер аңардан гына калмаган. Дөньясы шундый. Жорик Адельне ярата! Ә Адель аны! Аларның кавышырга хаклары бар! Мәхәббәт барысын да аклый!

Рәзидәне очратудан бераз бозылган кәефе Жорик искә төшүгә тагын күтәрелде. Очынып-очынып табын әзерләргә кереште. Ярый хәзер өйдә пешеренеп җәфаланасы юк, акчаң гына булсын, кибеттә бар да бар. Алып кайткан әзер салатларны өстәлгә куйды. Юып, җиләк-җимешне тезде. Затлы шешәле шәраб бәллүр бокаллар янына, түргә кунаклады. Бер телефонга күз төшереп, бер дивардагы сәгатькә карый-карый, Адель ишек кыңгыравы шылтыравын көтте. Ничә тапкыр телефонын кулына алырга ымсынса да, сөеклесенең, шалтыратма, үзем шалтыратам, дигән кисәтүен искә алып, ул уеннан кире кайтты. Ясатып кайткан прическасын бозмаска тырышып, тиз генә душта коенып чыкты. Киенде, өс-башын тәртипкә китерде. Зифа гәүдәсенә шушы тантаналы көн өчен сатып алынган кыска кара ефәк күлмәген киде, муенына кадерлесе бүләк иткән асылташларын асты. Көзгедән аңа зифа сынлы, ак йөзле чибәр ханым карап тора иде. Адель көзгедәге чагылышыннан канәгать калды. Тик барыбер нидер җитеп бетми кебек... Ләкин нәрсә?.. Әәә... Зур зәңгәр күзләренә елмаю җитми икән бит! Заманында бик күпләрне әсир иткән серле елмаюы җитми икән. Үз-үзен мәҗбүр итеп булса да, елмаеп җибәрде. Буялган иреннәр хәрәкәткә килгәч, бит очындагы ике чокырчык та «уянды». Матурлыгына иманы камил булса да, үзенең «фишкасын» яхшы белә иде ул. Бар сөйкемлелеге әнә шул иркә чокырчыкларда бит инде! Шул сөйкемле чокырчыкларны уятыр, кызны елмайтыр өчен күпме егетләр тырышты заманында. Аның баш әйләндерерлек шушы назлы елмаюына ирешкән байтак егетләр гыйшык утында яндылар. Ә горур кыз исә, салкын йөрәгән беркем дә яулый алмаган хан кызыдай, кемдер аша нечкә үкчәле туфлиләре белән атлап узды, кемнәрдер белән ярату уенын корды. Ләкин беркемне дә чын-чынлап йөрәгенә кертмәде.

Көзге каршында басып торган Адель, уйларыннан арынып, тагын дивардагы сәгатькә борчулы караш ташлады. Сәгать уклары кушылырга бик аз вакыт калганын күргәч, ясалма елмаюы эреде, бит очы чокырчыклары язылды, ирене нәүмизләнеп бөреште. Кайда йөри бу Жора? Ничә бәйрәмне, ничә Яңа елны алар бергә каршыладылар. Инде бу якынлашып килүче Яңа елны бер гаилә итеп каршы алырга иде исәбе Адельнең. Киләчәккә матур өметләр баглап... Яңа, матур уй-хыяллар белән! Яңа бәхет белән! Кайда соң син, сөеклем?! Нигә килмисең? Асыл кошың зарыгып көткәнне әллә белмисеңме? Хатынның сабырлыгы төкәнде. Ул телефонын кулына алды, таныш номерга басты. Тик колагы турында күпме генә тотмасын, автоматның чит-ят, коры тавышы гына кабатлады: «Абонент элемтәдә юк...» Абонент юк... Ничек булмасын? Ул иртән генә шалтыратты, көт, киләм, диде... Бер атна элек килгәндә уч тутырып акча калдырып китте – Яңа ел табынына... Әнә күпме киеме эленеп тора! Ә үзе, үзе кая соң ул? Алдавы шулмы? Адель бит аңа ышанды! Өзелеп яратам, дигәненә ышанды. Хатынымны аерам, бергә булабыз, дигән вәгъдәсенә ышанды. Ә бүгенге югалуын ничек аңларга? Яңа ел алдыннан? Барысы да чишелергә, ачыкланырга торганда? Шул төйнәлгән төеннәрне чишәргә көче җитмичә, дәшми-тынмый качуы шулмы? Балаларын, гаиләсен ташлый алмыйча газаплануымы? Ни булса да, ул очрашырга, аңлашырга тиеш иде! Адель уйнап туйган, кирәге калмаган җансыз курчак түгел ләбаса! Хатын ачынып көрсенде. Аны сискәндереп, дивардагы сәгать уклары кушылдылар һәм иске сәгать, Яңа ел җиткәнен белдереп, тантана белән даң-даң кага башлады. Башка чакта игътибар итмәгән сәгать чаңы нәкъ Адельнең баш миенә суга кебек. Даң-доң! Даң-доң! Яңа фатирга күчкәч, дәү әнисе, ата-бабаң төсе булып торсын дип, сәгать бүләк иткән иде – бүген Адель шул сәгатьне күралмады. Әйтерсең, аның ялгызлыгына ул гаепле! Өстәге, як-яктагы фатирларда күршеләр Яңа елны бәйрәм итәләр. Түшәм ишелерлек итеп ду килеп бииләр. Дивар кузгалырлык итеп җырлыйлар. Кешеләрдә бәйрәм – Яңа ел...

Адель әкрен генә урыныннан торды да, табын янына килеп, бәллүр бокалларга шәраб койды. Ике бокалны

PRESSA.RU


чәкәштереп, сөекле кешесен котлады: «Яңа ел белән, кадерлем!» Ә кадерлесе: «Яңа ел белән, асыл кошым!» – дип «җаваплады». Адель ике бокалны бер-бер артлы йотып куйды. Башына кинәт бәргән шәраб ачысыннан зиһене томанланып киткәндәй булды. Ашыйсы килгән өчен түгел, шулай кирәк булганга алдына салат бүлеп салды. Тагын телефонга күз төшерде. Таныш номерга басты. Автоматның коры тавышын ишеткәч, телефон трубкасын ачу белән диварга тондырды һәм өстәлгә капланып үксеп еларга тотынды. Бүгенгедәй чынлап онытылып, ихластан күптән елаганы юк иде аның. Кешегә бервакытта да күз яшеңне күрсәтергә ярамый. Шуны кагыйдә итеп аңлаган Адель, күңеле ничек тулышса да, бервакытта да кеше алдында тамчы да күз яшен төшергәне, көчсезлеген күрсәткәне булмады. Ә бүген – ярый. Бүген аны беркем күрми. Ничектер җиңеләеп калгандай булды. Эчтә тартылып торган киеренке кыл шартлап өзелде, бер дә җибәрми кысып торган кыскычлар бушанды кебек. Күз яшьләре белән күңелдән нидер юылып төште.

Күзләре ачыттыра башлагач, Адель ваннага кереп, битен сабынлап юды. Керфекләрен сирпеп караса – шешенгән күз кабаклары, кызарган борын-йөз... Макияж каплап торган җыерчыклар тагын биткә тамыр җибәргән... Сүнгән караш. Шулай да көзгедәге чагылышында үзе өчен бик кирәк, бик кадерле нәрсәне күргәндәй булды Адель. Бераз арыган, бераз бәхетсез, шулай да нәфислеген югалтмаган шушы йөздә ниндидер күңеленә бик кадерле якынлык тойды ул. Бизәнмәгән, төзәнмәгән, буянмаган йөздә ясалмалылык юк, ихласлык кына бар иде. Карашлар уйчан. Хәтта аларда ниндидер мәгънә бар кебек. Элекке бушлык юкка чыккан. Шушы йөз нәкъ Адельнең, юк, Әдиләнең үзе бит! Иннек-кершәннән арынмаган ясалма битлекле Адель түгел, шушы бит чын Әдилә! Ул чәчләрен модалы парик рәвешендә ясаткан прическасын юып төшерде. Мода артыннан куып, тәненә ясаган татуажны мунчала белән тырышып-тырышып ышкырга тотынды. Тик тиресенә сеңгән зәңгәрсу бизәк тиз генә бирешергә теләмәде. Йөрәге сыкранып куйды. Юк шул! Саф күңелле, чын Әдилә була алмас инде бервакытта да! Ул күптән коеп куйган сынлы, күпләр артыннан борылып карап, карашлары белән озатып калган чибәр йөзле курчак Адель! Шулай булуына күптән күнеккән. Матурлыгы – коралы, көче булды аның. Табигать биргән шул өстенлеген бик оста куллана да белде. Тик дөрес куллана белдеме икән соң? Меңнән берәүгә генә бирелгән чибәрлеге була торып, нигә ул һаман ялгыз? Әнә, күзгә ташланмый торган Рәзидәгә хәтле үз ишен тапкан. Ире, балалары белән кар атышалар... Ә үзен күпкә өстен санаган Адель аңардан ким булып чыгамы? Нинди бик мөһим нәрсәне аңламый калды Адель? Артыннан көтү-көтү йөргән егетләр дә булмады түгел. Аның белән язмышын бәйләргә теләүчеләр дә шактый иде. Тик кыз мәхәббәт ялкынында уйнап шаярды гына. Ут тирәли очкан күбәләк кебек, тирәсендә бөтерелгән егетләрнең канатлары тиз көйде. Адель берсен дә кызганмады. Үзен җиңүче итеп хис итте. Егетләр аның эчке матурлыгына түгел, тышкы салкын чибәрлегенә гашыйк булдылар. Хәер, Адель эчке дөньясын беркемгә дә ачмады. Берсе югалса, икенчесе табыла торды. Моңа хәтле Адель беркайчан да ялгыз булмады. Тик боз йөрәкле Карсылу кебек иде ул: күңелен беркем дә эретә, яулый алмады.

Бәләкәйдән курчакныкыдай зур зәңгәр күзле, уймак иренле кызны «матур» да «матур» диеп очындырып үстерделәр. Балалар бакчасында, мәктәптә Яңа ел бәйрәмнәрендә ул гел Кар кызы булды. Укырга әллә ни тырышлыгы булмаса да, табигать биргән матурлыгы коткара килде. Мәктәп исеменнән күп бәйгеләрдә катнашты. Җырларга, биергә өйрәнде. Үсә төшкәч, әнисе аны гүзәллек бәйгесендә катнашырга әзерләде. Анда катнашу кыз өчен дәресләрдән күпкә мөһимрәк иде. Бер әйберне яхшы үзләштерде – чибәрләр, матурлар тормышта үз урынын тиз таба, аларга бар да җиңел бирелә! Медальнең икенче ягын гына кыз аңларга теләмәде. Матурлык конкурсында катнашкан ярымшәрә чибәркәйләрне сәхнәдән мал сайлаган кебек сайлыйлар калын кесәле юан абзыйлар. Авылда яшәгән динле, иманлы дәү әнисе, бозыла инде бу бала, юлдан чыга, дип аның кыланмышларына каршы булса да, Әдилә инде матурлык корбанына әйләнә башлаган иде. Әдиләсенең Адель булып китүе белән дә дәү әнисенең килешәсе килмәде. Әлегәчә оныгын, Әдилә балам, дип йөртә бахыркай. Әтисез үскән Әдилә ата назының ни икәнлеген белмәде. Әнисенең ир-атны күралмавы кызына да йоктымы, Әдилә егетләр өчен зар-интизар булып утырмады. Ә әнисе кызын төрле кастингларга, конкурсларга йөртте. Заманча киендерергә тырышты. Кирәкле санаган кешеләр белән таныштырды. Алар икесе дә тышкы матурлык артыннан кудылар. Эчендә байлыгы ташып ашкан кыйбатлы кием-салым кибетләре, матурлык салоннары, фитнес-заллар, чибәрләнү курслары... Барысы да, килегез, чибәр булыгыз, зифа булыгыз, ир-атка ошый белегез, дип үзенә өнди. Акча гына китерегез. Шулар арасында ялгышып кына булса да кешенең эчке камиллеген үстерә, табигый ихласлыгын ача торган берәр курс, мәктәп яки оешма бармы? Кеше ишетә күрмәсен! Кычкырып көләрләр. Бу җәмгыятькә кешенең эчке байлыгы түгел, ә тышкы ялтыравыгы гына кирәк, ахрысы.

Шул салоннарда, кибетләрдә үткәргән вакыты Әдиләгә беренче тапкыр кызганыч булып күренде. Менә шушы бер уч чиста су белән юып төшерер өчен ул күпме акчасын, күпме вакытын исраф итте. Кемгәдер чибәр күренер өчен. Ә кирәк идеме соң? Ул гомере буена кеше фикере белән исәпләшеп яшәде. Болай дип уйламасыннар, тегеләй дип әйтмәсеннәр... Матур санасыннар. Матурлык аның өчен максатка, эталонга әверелде. Матур икән, димәк, дөрес. Матур икән, димәк, хаклы, урынлы. Йөзендәге беренче җыерчыгын күрү Адель өчен иң фаҗигале көнгә әверелде.

Әдилә тагын, дәү әнисен сагынып, тирән көрсенеп куйды. Гади авыл карчыгы димәссең, нинди акыллы



Рәсем: Наталья Васильева

фикерле аның дәү әнисе: «Бәбекәем, чибәрлек ул кыз балада вакытлыча. Ул барыбер бервакыт сула. Ул беткәч калырлык матурлыгың булсын...» Ул вакытта аңламады шул шәһәрдә үскән кыз авыл карчыгын. Аңламады. «Үземне югалттым, дәү әнием... Тамырларымны югалттым. Ничек табарга тагын үз-үземне? Ничек тагын Әдиләң булырга?! Адель түгел, Әдилә буласым килә, дәү әни! Арыдым мин җансыз, ясалма йөзле курчак булып! Ялгыштым, адаштым... Минем дә бит җаным бар. Ул авырта, сызлый. Ярый әле син исән, син бар, дәү әнием! Башкаемны итәгеңә салып туйганчы бер еларга! Хата-ялгышларымны күз яшьләрем белән юасым килә. Бәлки, йөрәгемдәге боз кыйпылчыгы да эрер иде... Әрнүләрең җаныңа дәва, дия идеңме, дәү әни...»

Иске сәгать зең-зең килеп Яңа елның яңа туган мизгелләрен санады. Әдилә аңа бу юлы никтер икенче караш белән, хәтта үз итеп карап куйды. Әйтерсең лә, иске сәгать Әдиләгә гомеренең яңа бер чоры башлануын, нидер үзгәрүен сөенеп хәбәр итә...

Әдилә кием-салым шкафы янына килде дә Жорикның киемнәрен юл сумкасына тутырды. Әйбәтләп төргүне дә нигәдер кирәк санамады. Элек бик татлы тоелган ирләр хушбуе исе бүген күңелен болгатты. «Асыл кошым...» Очып китә бүген тавис кошың... Дүрт ел буена аны югалтудан, ялгыз калудан куркып яшәде Әдилә. Ә бу мизгелдә күңелендә тамчы да югалту газабы тоймады. Киресенчә, күңелендә ирек кошы канат җилпеде.

...Яратам, дип ялгышканмын икән бит мин. Гафу ит, Жора-Җәмил... Ярата белмим, ахры, мин. Бөтен бәхетсезлегемнең, ялгызлыгымның сәбәбе дә шундадыр. Яраттым, тик үземнең тышкы матурлыгымны гына яраттым. Тәвә кошы сыман үз-үземә генә сокландым. Мәхәббәтемне таба алмаудан газапланып, тормыш ямен күрмәдем, тәмен тапмадым. Ә син барыбер минеке түгелсең. Кавышкан очракта да минеке булмас идең... Кайчандыр мин күпләрне ташлаган кебек, бүген үземне ташладылар... Шулай да, ярый әле кичә Яңа елны каршыларга килмәдең. Уйланмас, уянмас идем... Җансыз курчагың булып калыр идем. Нидер аңлар өчен, уяныр өчен, артык горурлыгым сынсын өчен шулай тетрәнеп алырга кирәк булган, күрәсең...

Яңа елның зәңгәрсу тын иртәсендә ихлас мөлаемлыгын югалтмаган яшь хатын подъездан чыкты һәм җәяүләп кенә якындагы урамга юнәлде. Андагы бер йортка кереп, астагы фатир ишеге төбендә зур сумканы калдырып чыккач, өстеннән тау төшкәндәй, җиңел сулап куйды. Күбәләкләп, уйнаклап Яңа ел кары ява! Яңа ел, ап-ак карларыңа төреп, кешеләргә яңа бәхет, яңа өметләр алып кил, яме? Ә иске бәхетләрен калдыр, ишетәсеңме? Әдилә, тун якасына кунган кар бөртекләренә тияргә җөрьәт итмичә, бер тын һавага карап басып торды. Күзләрен йомды. Аркасына кемдер кар йомарлап ыргыткач кына, сискәнеп, күзләрен ачты. Бер төркем яшь җилкенчәк, көлешә-көлешә җепшек кар бәреп шаяра. Бит очы чокырчыкларын «уятып» шат елмайган Әдилә дә аларга кушылып кар бәрешә башлаганын сизми дә калды. Шаярып арыган, битләре кызарган яшь ханым, кышкы һаваны күкрәк киереп сулыйсулый, тимер юл вокзалына, электричкага юнәлде.

Авылда аны, яраткан Әдиләсен, зар булып дәү әнисе бәйрәмгә көтә.

PRESSA.RU

ГОД РОССИЙСКОГО КИНО 2016

ФИЛЬМОГРАФИЯ

2012 **«Башня. Новые люди»** – Әмир

2012 **«Искупление»** – Август

2013 **«Погружение»** – Ренат

2013 **«Три мушкетёра»** – Д'Артаньян

2014 **«Екатерина»** – Сергей Салтыков

2014 **«Манекенщица»** – Иван Холодов

2014 **«Масоны»**

2016 **«Балтийское танго»** – Макс

2016 **«Икария»**

2016 **«Оптимисты»** – Аркадий Голуб

2016 **«Тэли и Толи»** – Гоча

2017 **«Кома»**

2017 **«Притяжение»**



Фотолар төрле матбугат чараларыннан алынды

РИНАЛЬ МӨХӘММӘТОВ



БАЛАЧАК

Риналь 1989 елның 21 августында Татарстанның Алексеевский районында туа. Башта малай диңгезче булырга хыяллана. Сигезенче сыйныфтан соң Суворов училищесына укырга керергә талпынып карый. Тик аны укырга алмыйлар: төгәл фәннәрдән белгеләре бик шәптән түгел икән, җитмәсә, бераз тотлыга да. Тугызынчы сыйныфта бәрмә уен кораллары белән мавыга башлый, үз төркемен оештыра. Брейк-данска гашыйк була, тхэквандо белән шөгыльләнә. Иҗатка тартылган улына әнисе Казан театр училищесына барырга киңәш итә. Ул Казан театр училищесының эстрада бүлеген сайлый. Укытучылары озын буйлы чибәр егетнең талантын шундук күреп алалар, аңа Мәскәүдә укырга киңәш итәләр.




МӘСКӘҮ
МХАТта Кирилл Серебренников үз курсына студентлар җыйган чакка туры килә Риналь. Остазы булачак артистның тотлыгып сөйләшүенә әһәмият тә бирми, уку дәверендә узачак, ди. Риналь үзе дә кыенсынып йөрми: кимчелеген өстенлеге итеп күрсәтә белә. Бөек акыл иясе кебек фәлсәфәгә бирелеп, дәшми йөрүне артыграк күрә. Дәшмәү – зирәклек галәмәте. 2012 елда театраль вузны тәмамлап, беренче көннән үк үзе яраткан Мәскәүдә кала.




ТЕАТР
Курста иң талантлы студентларның берсе була. Дикциясен дә төзәтә Риналь. Сәхнә хәрәкәтләре, фехтование, бию белән кемне дә сокландыра. Зифа буйлы егет башкаладагы төнге клубларның берсендә биюче булып эшли икән бит. Студент елларында ук дебютлары була. Укып бетергәч, Ринальны «Гоголь-центр» труппасына эшкә чакыралар. «Герой нашего времени»да ул берьюлы өч рольдә уйный! Печорин, Грушницкий һәм әлбәттә, Азамат! «Каин» мистериясендә дә Каинны да, Люциферны да уйнап, бер образдан икенчесенә күчүдә чын виртуозлык күрсәтә.



КИНО
Диплом алырга бер ел кала, Риналь Мөхәммәтовның кино биографиясе башлана. «Искупление» хәрби-тарихи фильмындагы дебютында ул яшь хәрби очучы Августның тирән трагик образын тудыра. «Башня. Новые люди» мистик триллерында Ринальны тагын төп рольгә чакыралар. Сергей Жигуновның «Три мушкетёра» картинасында исә Мөхәммәтов – Д'Артаньян! Фехтованиесе дә, иярдә утыруы да искиткеч килешле, матур килеп чыга. Ә «Екатерина» сериалында граф Салтыков образында яшь артист күп кызларны үзенә гашыйк итә. Александр Амировның «Тэли и Толи» лирик комедиясендә гашыйк грузин Гоча образы Риналька тагын дан китерә.



МУЗЫКА
Кинодан тыш, артистның тормышында музыка зур урын алып тора. Татар җырларын яратып башкара. Риналь Мөхәммәтов – гаҗәеп исемле «Корпорация «Жёлтый Асфальт» дип аталган музыка-театр труппасының фронтмены. Ул җырлый, җыр текстлары яза, бәрмә уен коралларында уйный. Коллективы чыгыш ясый торган жанрны музыкант Мөхәммәтов поп-террор дип атый.



ГАИЛӘ
Күп рольләр уйнаган актерның тагын бер хыялы була – аның чын тормышта әти ролен башкарасы килә! «Бу бик мөһим һәм җаваплы!» – ди ул журналистлар белән бер әңгәмәсендә. Һәм... быелдан ул – әти! Яраткан кызы Сюзанна Акежева белән Ринальнең кызы туа. Аңа Эвия дип исем кушалар. Сюзанна үзе дә – актриса. Мурманск театр студиясен тәмамлап, Мәскәүгә килә, МХАТта укый. Тамашачылар яшь актрисаны «Заградотряд» фильмында – Тая, «Рябиновый вальс»та Вера Митина ролендә күреп яраттылар. Сюзанна Риналь белән бергә «Гоголь-центр»да эшли.

PRESSA.RU



КҮК ТҮБӘЛӘР БИЕК ҺАМАН...

Бервакыт шулай Мөдәррис Әгъләмов китабын актарып утырам. Шигырь юллары, Мөдәррис тавышы белән яңгырап, җаннарны актара:

«Үз халкыңның киләчәген,
Үткәнен, бүгенгесен;
Кайгысының, шатлыгының
Зурлыгын белер өчен...

Мин инде Мөдәрриснең үзен күрәм кебек: куллары йодрыкка төйнәлгән, сүзләрен өздереп-өздереп әйтә, «нәни гигант» шулай шигырь укый:

Еракка китеп кара син,
Еракка китеп кара!»

Әле берсе, әле икенчесе аша Мөдәрриснең җан авазы ишетелгәндәй була:

«Ак кәгазьгә сүзләр булып кан тама,
Салкын тирләр бәреп чыккан аркама»...

Чып-чын оратор!

Һәм шунда кинәт... «Карлар ява». Мөдәрриснең кайнар, чакматаштай үткен юлларыннан соң бөтенләй башка дулкынга күчтем дә куйдым.

Ап-ак карлар ява, ап-ак карлар
Алып китә мине үткәнгә.
Ул көндә дә шулай, ап-ак карлар
Ява иде сине көткәндә...

Тымызык кына булып томан артында калган яшьлек елларым күз алдымнан үткәндәй булды. Ялтырап яткан чана юллары, кар каплаган түбәләр, тәрәзәдәге кышкы бизәкләр, ишекне ачуга дуылдап керүче салкын һава йомгагы, көртле юллар...

Карлар ява

Ап-ак карлар ява, ап-ак карлар
Алып китә мине үткәнгә.
Ул көндә дә шулай, ап-ак карлар
Ява иде сине көткәндә.
Күк түбәләр шундый биек иде,
Урамнары шундый киң иде.
Безгә сөю вәгъдә иткән урам
Бәхетләргә илтер күк иде.
Ап-ак карлар ява, ап-ак карлар
Кабатлана шулай ел саен...
Ап-ак карлар белән сөйгән ярлар
Кабатланмас инде, мөгаен.
Күк түбәләр шундый биек һаман,
Урамнар да шулай киң һаман.
Безгә сөю вәгъдә иткән урам
Ник бәхеткә илтеп куймаган?
Ап-ак карлар яуган, ап-ак карлар
Бездән соң да, безгә кадәр дә.
Бергә узган карлы кичәләрнең
Кадерен белсәң генә әгәр дә.
Күк түбәләр шундый биек булыр,
Урамнар да шундый киң булыр.
Сөю вәгъдә иткән карлы урам
Бәхетләргә илтер юл булыр.

Ак төснең әллә нинди төсмерләре күз алдымда биеште. Талгын гына карлар ява. Бар дөнья акка төренгән. Моң да, шатлык та, өмет тә бар ул карларда. Күңелдә ниндидер кыңгыраулар чыңлап алды. Буран бөтерелеп, вальска әйләнде. Китап та, Мөдәррис тә онытылды. Мин, 16 яшьлек егет, кышкы кичтә Теләче клубында, баян телләренә баса-баса, марҗа кызларын биетәм. Кызлар вальска әйләнә. Вакыт та чаба гына. Сәгать телләре кичке 9 ны да, 10 ны да уза. Ә минем 12 чакрым араны теркелдәп, туган авылым Югары Кибәхуҗага җәяү кайтасым да бар. Урамда кар ява. Ул басуларга, юлларга сара. Күбәләк карлар ак чәчәкләр булып кайтыр юлларыма сибелә. Кайтмас идем – авыл сагындыра. Анда – әти-әни, дуслар, тагын берәү бар...

Икенче бер кышкы сурәт. Мин Ерак Көнчыгышта хезмәт итәм. Иксез-чиксез тайга. Урман эченә чыгып, баянда уйнап утырам. Туган якларны сагынудан күңелдә яңа көйләр бөреләнә.

Һәм менә тагын... «Карлар ява». Болары – Мөдәррис кышы, Мөдәррис карлары. Җырлап тора! Көй сорап тора! Үземә охшаган шигырьгә мин шундук көй язам. Бу юлы да шулай хисләнеп кереп киттем дә, яңа җыр туды. Мөдәррискә әйттем.

«О-о! Мин бу шигырь барын оныткан да идем», – дигән була. Җырны ошаттылар, дигәч, канәгать елмайды тагын. Ул бит җырлар яза торган шагыйрь түгел. Аннары ул махсус җыр тексты язам дип тә утырмаган. Мөдәрриснең: «Җыр ул – күмәк хезмәт. Шагыйрьнең, композиторның, җырчының, режиссерның уртак көче кергән аңа», – дип әйткәнен хәтерлим. Тагын бер фикере истә калган: «Җыр текстлары белән артык мавыгырга ярамый. Бик өметле шагыйрьләр дә, мавыгып китеп, саегалар. Шигырь язмыйча, җыр тексты гына язалар...»

Ә теге вакытта, хәтерлим, Мөдәррис, тыйнаклык күрсәтәсе килеп: «Менә Наҗар Нәҗми карлар ява дип язган иде, анысы көчле ул!» – дип куйган иде. Рим Хәсәновның «Кышкы романс»ы турында әйтүе инде.

Менә тагын җир өстенә карлар ява,
Бөтен нәрсә калган кебек кар астында...

Мондыйрак юллар да бар:

Акты безнең кар өстендә калган эзләр,
Акты елап икәү бергә салган эзләр...

Әһә, дим, Мөдәррис тә бу шигырендә әнә шул ноталарны җиткерергә теләгән түгелме соң? Икесендә дә – Мәхәббәт темасы. Ләкин хәзерге кебек «Мин сине яратам!» дип әйтмиләр иде ул чакта. Үгет-нәсыйхәт тә юк иде. Хәзер барысы да бар – җыр гына юк!

«Карлар ява»ны радиога беренче булып Рафаэль Сәхәбиев яздырды. Кече симфоник оркестрга кушылып җырлады Рафаэль. Аның лирик баритон тавышы, күңелнең иң нечкә кылларына кагылып, рәхәт бер дулкында тибрәтте. Флейта, торба тавышлары үзенә бер аһәң белән яңгырады. Әйтерсең, нәфислек, хис, романтика җил һәм мәхәббәт канатында очты. Шатлык та, өмет тә, сагыну да бар анда. Кушымта өлешендә җыр, кульминациясенә җитеп, тагын да көчәеп яңгырый:

Күк түбәләр биек иде!
Урамнары шундый киң иде.
Безгә сөю вәгъдә иткән урам
Бәхетләргә илтер күк иде...

Зиннур Нурмөхәммәтов, Хәнәви Шәйдуллин репертуарында да яңгырады җыр. Баянчысы Ирек Галимов Илһам абый Шакировтан «Карлар ява»ны җырлатасы килеп йөрде. Мин аны «Һаман яратам» дигән җырлар китабыма да керттем. Хәзер инде яшьләрдән җырлатасы иде аны. Күк түбәләр дә биек һаман, урамнар да киң һаман...

Татарстанның халык артисты, композитор
Фәрит ХАТИПОВ истәлекләренә нигезләнеп,
Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.

■ Фотода: Мөдәррис Әгъләмов *(уртада)* иҗатташ дуслары арасында. Беренче рәттә сулдан-уңга *(утырганнар)*: Әлфия Афзалова, Риф Гатауллин, Гөлзадә Сафиуллина; икенче рәттә *(басканнар)*: Әхмәт Гадел, Фәннур Сафин, Мөдәррис Әгъләмов, Илгизәр Фазлуллин, Кирам Сатиев.

PRESSA.RU

БӘХЕТКӘ АЛЫШКАН БАЙЛЫК

Принцессаның кабат көлсылуга әверелү тарихы

Лилия ГӘРӘЕВА

КЫЗЫМНЫҢ БИК ЯРАТКАН БЕР УЕНЫ БАР. «ӘГӘР ДӘ БЕР МИЛЛИОН АКЧАҢ БУЛСА?» ДИП АТАЛА УЛ.

«Әгәр дә бер миллион акчаң булса, син нишләр идең?» Хыял миллион чикләренә генә сыймый, тә-әк... Әйтәм бит, монда берничек тә бер миллион белән генә булмый. Ә менә чынлап та миллионнары булган кеше нишли икән ул, аны кайларга туздыра икән? Балда-майда гына йөзәме алар?

Борын-борын заманда түгел, әле безнең заманда гына, Каф таулары артында да түгел, үзебезнең Казанда гына Юлия исемле көлсылу яшәгән. Көлсылу – бу очракта исем түгел, статус. Әлбәттә, аның тормышы Шарль Перро тасвирлаганча ук булмаган. Бөтенләй дә алай булмаган. Ул үзен бик яраткан әнисе һәм әтисе белән яшәгән. Аның әле сеңлесе һәм бер энесе дә булган. Юлия атлы көлсылу мәктәпне тәмамлап, институтка кергән.

Әмма көннәрдән бер көнне аларның әтиләре үлеп киткән. Юлия шушы көннән көлбатырга әйләнгән. Никме? 40 яшьтә өч бала белән тол калган әниләре көне-төне елаган да елаган. Көлбатырга әверелгән көлсылуга әнисен дә, туганнарын да кайгыртырга туры килгән. Дәресләрен әзерләшкән, борчуларын бүлешкән, матур киемнәр сатып алган. Бер дә авыр булмаган бу аңа. Ул инде кечкенәдән үк үзен җаваплы тоеп өйрәнгән кыз. Шулай көннәр үткән, һәм берсендә көлсылуга (әй лә, көлбатыр бит ул хәзер!) патша малае, ягъни принц була инде, очраган. Дөресен генә әйткәндә,

Фотолар: гаилә архивыннан

ул бер дә патша малае булмаган. Гомумән, ул гап-гади бер егет кенә булган. Ә безнең көлсылу бу вакытта Казандагы «Нәфис-косметикс» оешмасында эшләгән. Әмма аның бик тә банкта эшлисе килгән, ләкин КХТИ тәмамлаган кызны банкка алмаганнар. Шуңа да ул «Нәфис»кә урнашкан. Әмма монда ай ярымга гына чыдаган ул. Эш авыр булган өчен түгел, үзен хокуксыз итеп тойган өчен киткән. Аның бик тә бай һәм иркле буласы килгән.

Беренче яхшы тун

Мәктәптә укыганда ук балаларның ял лагеренда – тәрбияче, студент чакта инде лагерь җитәкчесе үк булып эшләгән Юлия бер дә аптырап тормаган (11 нче сыйныфта укыганда укытучылары авырып киткәч, түбән сыйныфларга физика да укыткан әле ул. Боларны ник язаммы? Аның амбицияләрен күрсәтү өчен!). Казандагы бер машина салонына кеше кирәген ишеткән дә ике атна аларга бушка эшләгән. Гаҗәпләнмәгез, шартлары шундый булган аларның, ике атна бушка эшләп, үзеңне күрсәтәсең дә, ошатсалар, эшкә урнашасың. Көтегез, шалтыратырбыз, дигәннәр. Бер-ике атна көтеп караган да, инде юктыр дип, хыялы артыннан киткән Юлия. Әллә кая еракка түгел, интерьер дизайны курсларына гына. (Хәер, соңыннан хыялының да бу булмаганлыгын ачыклаган. Шулай да белемнең артыгы юк бит, һәрхәлдә, Юлия өчен.) Ә бит шалтыраткан тегеләр, эшкә чакырганнар. Шушы кышны ул үзенең беренче яхшы тунын алып кигән. «Бер генә яңалык та, бер генә танышу да очраклы түгел, – ди Юлия. – Яңа кешеләр белән танышып, без нәрсәгә дә булса өйрәнәбез яки үзебез аларны өйрәтәбез». Дөрестән дә, бу оешмада бик күп нәрсәгә өйрәнгән ул. Сатып алучыларны ничек итеп җәлеп итәргә дә, сатылмый торган машиналарны ничек итеп сатарга кирәгенә дә... Гади сатучыдан өлкән сатучыга кадәр күтәрелгән. Бүлек мөдире вазыйфасына да ирешкән булыр иде, инженер ирен директор итеп Мәскәүгә чакырмасалар. Ләкин, бигайбә, ир белән Мәскәүгә китми булмый.

Анда да автомобиль бизнесында эшли әле ул. Ләкин иренең монда эше уңмый. Алар кабат Казанга кайталар, фатир алалар. Әйе, ипотекага! Аның каруы, үзләренеке. Иренең үз машинасы бар инде, Юлиягә дә кирәк. Алар яшәгән йортның ишегалдына тезелешкән йөз машина арасына йөз дә беренчесе булып Юлиянеке дә кайтып туктый бер көнне. Әйе, «Матиз», аның каруы, ул аңа күпме ирек, бәйсезлек бирә. Монысын машинаны үзе йөртеп караган кеше генә белә. Фатир бар, машина бар, инде Юлиягә шәп кенә акчалы бер эш кирәк – иминиятләштерү компаниясенә урнаша. Һәркемне сүзенә ышандыра белгән, үзен бик ышанычлы тоткан (бизнес өчен иң мөһим сыйфатлар) ханымның эшләре бу өлкәдә дә аршынлы адымнар белән алга китә бит. Аны зур бер банкка килешү төзергә җибәрәләр. Банклар белән беренче тапкыр эшләгән килешүе була ул аның. Икенче көнне аңа шушы банктан ук шалтыратып... үзләренә эшкә чакыралар. Ә бит банкта эшләү аның иң зур хыялы иде. Хыялың тормышка ашам дип торганда кем каршы килсен инде, Юлия дә килешә. Яхшы эшли, бүлек мөдире була. Шушыннан гына бала табарга китә. Улы бераз исәйгәч, балага нәнке яллап, эшкә чыга. Хәзер инде Юлия тагын да тырышыбрак эшли башлый: акча үзенә генә түгел, улына да, няняга да кирәк бит.

Тагын бер-ике елдан ул инде Россия банкларының берсенә директор урынбасары булып килә. Бу инде – федераль дәрәҗәгә чыгу дигән сүз. Җаваплылыгы да зур, акчасы да. Тырыша Лекарева Юлия Вячеславовна. Чөнки миллионлык килешүләр төзергә барганда син бит инде биш меңлек кенә күлмәк тә, өч меңлек кенә туфли да киеп бара алмыйсың – брендлысы кирәк. Күлмәк янына – сумка, алкасы, беләзеге, туны, итеге... Прическа, макияж... Теге тырышып тапкан акчаларның шактые дәрәҗәне асрау өчен китә. Клиентлар белән рестораннарда да очрашырга туры килә. Ресторанга кергәч, бизнес-ланч белән генә булмый, төп менюдан да заказ бирәсең. Монысы да чыгым. (Монысы язма башындагы соравыма җавап өчен, миллионнары булган кеше аны нишләтә икән, дигәнемә.)

Ире дә фирма директоры, үзе дә, директор ук булмаса да, банкта урынбасар, тормышлары шактый шәп тәгәри боларның. Бала – бакчада, бакчадан соң аны няня ала. Фатирны бер хатын килеп җыештырып китә. (Хәзер боларны искә алганда, Юлия көлеп җибәрә: «Чит-

Акча бик кызык нәрсә. Ул күбрәк булган саен, җитми башлый икән.



PRESSA.RU

тән карап торган кеше мине ялкау байбичә дип әйткәндер инде. Әмма бу – минем ялкаулыгымнан түгел, дөрестән дә өлгермәвемнән иде бит».) Ашау-эчү, әлбәттә, яхшы ресторанда гына. Анысы да Юлиянең эштән вакытында кайтып, вакытында пешерә алмаганы өчен. Кайтыр иде, тырышмый булмый, тырышмас иде, очрашасы түрәләре янында үз дәрәҗәсен күрсәтү өчен акча кирәк. Менә шундый йомык боҗра – күп итеп эшли, эшләгәнен кабат шул эш өчен туздыра, туздырганны кабат тутыру өчен эшли...

Берзаман исемә килсәм, мин бөтен хыялларымны бонусларга алыштырганмын бит!

Улының Кыш бабайга язган хаты кулына килеп кермәсәме?.. Әтиәнисен туя күрмәгән сабый аннан уенчык та, хәтта кыйммәтле гаджет та түгел – ә әнисенең аның янында булуын теләгән: «Кадерле Кыш бабай, – дип язган ул, кәкре-бөкре басма хәрефләр белән (кечкенә булган чөнки. Менә боларны сөйләгәндә Юлия көлми инде, улын кызганып, эчтән генә үкси), – син миңа бүләк итәсе машинаны әнинең буш вакытына алыштыра алмыйсыңмы? Мин бик тә әнине сагынам».

Принцессадан – кабат көлсылуга

Юлиянең кабат көлсылуга әверелүендә хат кына «гаепле» булмагандыр инде ул. «Башкача алай эшләп тә, алай яшәп тә булмый иде, – ди Юлия. – Акча кешедән кол ясый. Мин аның чып-чын колы идем. Акча дип чаба торгач, барлык хыялларымнан ваз кичтем. Берзаман исемә килсәм – минем иң зур хыялым күбрәк бонуслар гына эшләү икән бит. Ә бит әле кайчан гына шәп итеп фотога төшерергә өйрәнәсем килде. Фотоаппаратым да бар, шуны кулыма алып карарга гына вакытым юк».

Үзе биш бармагы кебек яхшы белгән иминиятләштерү, банк бизнесы турында бик ачылып сөйләмәсә дә (ярамый), күңеле кабул итә алмаган кайбер нәрсәләрне шулай да әйтми булдыра алмый. «Соңгы ике-өч елда «процессны оптимальләштерү» дигән матур термин әйләнешкә керде. Матур яңгыраса да, максаты яман – оешмада хезмәткәрләр санын киметеп, киткәннәрнең эшен калганнарга бүлеп бирү. Эше артты, хезмәт хакы гына шул килеш. Кул астымда эшләүчеләрне тагын да тырышып эшләргә ничек өндәргә белми йөди идем. Аларның болай да соң дәрәҗәдә тырышуларын күрә идем бит. Банкта бонуслар эшләү дип сөйләшәләр. Әмма андагы система шундый итеп корылган – күпме генә тырышсаң да, ул бонуслар урынына шымытыр тоттыралар!»

Мин аның инде акчалы, бер өйрәнгән эшеннән китүенең сәбәбен беләм. Җитәкчесеннән акыллырак булган өчен киткән ул. Дөресрәге, җибәргәннәр. Әлбәттә, аны шунда ук икенче банкка эшкә дә чакырганнар, тагын да күбрәк акчалар белән кызыктырганнар. Юк, риза булмаган. «Фотога төшерүдән тыш, минем тагын бер зур хыялым бар иде: 107 килодан, һичьюгы 90 килога кадәр булса да ябыгасым килә иде (хәзер ул 68 кило). Яңа ел каникуллары вакытында ял алдым да, фитнес-залга йөри башладым. Велотренажерга утырдым шулай, аяклар – тәбәлдеректә, уйлар – әллә кайда. «Юлия, тормышыңның мәгънәсе нәрсәдә инде синең? – дидем үз-үземә. – Син улыңның үскәнен дә күрмисең, үзең теләгән эш белән шөгыльләнә алмыйсың. Иртән эшкә кил дә, хезмәткәрләрне ничек итеп тагын да ныграк эшләтергә икәнен уйла. Шушымы инде синең тормышыңның мәгънәсе?» – дип, үз-үземә сорау бирдем.

...Каршымда гап-гади бер ханым утыра. Әлегә ул эшсезлек буенча биржада тора, фотографияләр белән мавыга, бик күп йөри, өйрәнә.

– Иң авыры – көн дә иртән эшкә бармыйча өйдә калуым булды, – дип искә ала эшсез калган беренче мәлләрен Юлия. – Бик сәер иде бу. Ә акчасызлык баштарак чынлап та куркытты. Бер гадәтләнгәннән ваз кичүе ул һәрвакытта да авыр. Ирем эшләп торгач, без ач та, ялангач та түгел анысы. Әмма хәзер брендлы күлмәкләр дә, затлы салоннар да минем өчен түгел инде. Дөресен әйткәндә, аларны киеп кая да булса барасым да юк. Элеккеге тормышымнан калган киемнәрнең кайсын бүләк иттем, кайсын саттым. Алар хәзер миңа бар да мул. Кием-салымның арзанлысын алам. Матурлык салоннарына да йөрмим. Чынлыкта, супер модалы кыйммәтле салон клиентларны җәлеп итәр өчен генә ялтырый. Яхшы белгеч өендә генә кабул итсә дә, нәтиҗәсе – салондагыча, ә бәясе шактый арзанрак булачак. Мин менә хәзер шулай итәм. Ә чәч, тырнак ясауны үзем дә булдырам, аларга акча сарыф итеп тә тормыйм. Мине бүген урамда күреп, элеккеге танышларым танымый. Аларны аңлыйм, чөнки бөтен җиргә фотоаппарат асып, һәр күренешне сурәткә алырга әзер йөрим, киемнең дә уңайлысын, пычранса да җәл булмаслыгын киям – фотога бит кайвакыт җиргә ятып та төшерергә кирәк була.

Шулай да бүгенге хәлемне вакытлыча гына дип саныйм. Тиздән үз фотосалонымны ачарга ниятлим. Кайчандыр иминиятләштерү бизнесына берни дә белми килеп кереп, тиз арада аның бар серенә төшенгән, уңышларга ирешкән идем. Бу юлы да шулай булачак, минем моңа иманым камил. Мине хәзер банк та, иминиятләштерү дә кызыктырмый. Банкка барып, кемне күбрәк «савасы» яки иминиятләштерүгә барып кемне ничек «кәкре каенга терисе» дип уйлыйсым да, инде кырыктан узып килгәндә, кемгәдер буйсынып, теләмәгән эш белән шөгыльләнәсем дә килми. Акча җитәр-җитмәс яшәү минем өчен яңалык түгел, без кечкенә вакытта әти-әнием гел шулай яшәде. Акчага омтылсам, бүген үк яхшы эшкә урнашып, шәп акчалар эшли алам. Ләкин ул миңа кирәкми. Миңа иреген кыйммәт. Акчаны мин бәхеткә алыштырдым.



ТҮБӘН КАМА КЫЗЛАРЫ

«Әни булу шундый күңелле!» Әниләр көне уңаеннан бәйрәмгә җыелган Түбән Кама хатын-кызларының һәркайсы үзе дә сизмәстән шул сүзләрне кабатлады. Әйе, бөтен район әниләрен бер залга тупладылар ул көнне. «Түбән Кама хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы гүзәл затлар өчен бәйрәм әзерләгән иде.

«Хатын-кыз – «двигатель» ул. Тик аңа да ял кирәк. Шуңа күрә бүген кадерле хатын-кызларыбызны ял иттерү өчен бирегә җыйнадык та инде», – дип башлады сүзен оешманың җитәкчесе, Түбән Кама районы башлыгы урынбасары Эльвира Рәфгать кызы Долотказина. «Түбән Кама хатын-кызлары» оешмасының эшчәнлеге турында ел әйләнәсе ишетеп-белеп торабыз инде. Әле җәй уртасында гына «Авылым хуҗабикәсе» бәйгесен уздырган иде алар. Авылда яшәүче хатын-кызларга гына хас булган үзгә бер гүзәллек вә нәзакәтлелек бәйгесе ул. Райондагы барлык унбиш авыл җирлегенең һәркайсыннан берәр хатын-кыз килгән иде анда. Конкурсны оештыручылар алар өчен нинди генә сынаулар уйлап тапмаган: аш-су әзерләү һәм җыр-бию генә түгел әле, шәһәрдән килгән жюри әгъзаларын гаҗәпләндереп, чалгы белән печән чабуны, хәтта балта тотып утын яруны да булдыра алуларын күрсәтте Түбән Кама хатын-кызлары.

Хатын-кызлар оешмасы Ватанны саклаучылар көнендә ел саен традиция буенча «Әни бәлеше» пешерә: Түбән Камада хезмәт итүче солдатларны камыр ризыклары белән сыйлап кайта. «Чит балалар юк бит. Кем белә, безнең газизләребезне дә шулай сыйлап сөендерүче булыр, бәлки. Өйгә кайткан кебек булабыз, дип куана егетләр», – ди Эльвира Долотказина.

Һәр елның ноябрь ахырында – Әниләр көне. Гадәти очрашу һәм концерт форматында гына үтмәде ул Түбән Камадагы чара. Әниләр өчен төрле мастер-класслар әзерләнгән иде. Эшмәкәр Ләйсән Гарипова, мәсәлән, ана булу белән беррәттән, уңышлы бизнес-леди булу серләрен ачты. Табиб Юрий Почитаев хатын-кыз сәламәтлеге турында сөйләшү уздырды. Балаларны да онытмаган иде оештыручылар: әниләре итәгенә утырып, сабын да ясап карады сабыйлар, матур открытка да әзерләде...

Бәйрәмгә 2 яшьлек улы Саша белән килгән Эльмира Давыдова бөтен яшь әниләрнең фикерен яңгыратты дисәк тә, ялгыш булмас: «Без бит көннәр буе өйдә утырабыз. Үз дөньябызда гына кайнап, әле тагын бер зур дөнья барлыгын да онытабыз. Шуңа күрә бу чара көндәлек мәшәкатьләрдән бераз арынып торырга булышты».

«Түбән Кама хатын-кызлары» оешмасының юбилее да бит әле быел. Эшчәнлеген башлап җибәргәнгә биш ел тулды. Тыйнак кына итеп билгеләп үтте аны оешма әгъзалары. Үзләре тыйнак булса да, эшләре күркәм, дәрәҗәләре зур аларның. Югыйсә һәр оештырган чараларына районның төрле почмакларыннан хатын-кызлар очып килеп җитмәс иде.

Фәнзилә МОСТАФИНА

PRESSA.RU

«КҮҢЕЛ» – КҮҢЕЛЛӘР КҮРЕГЕ

ЭШЛЕКЛЕЛЕК ҺӘМ РОМАНТИКА... БЕР-БЕРСЕННӘН БИК ЕРАК ТОРГАН ТӨШЕНЧӘЛӘР.

Ә менә «Күңел» радиосы мөхәррире Рузилә Гатинаны тыңлап, күзәтеп утырсаң, гаҗәпкә каласың: ул бит эшлекле романтик! Кара син, шулай да була ала икән!



Ризидә РӘХМӘТУЛЛИНА

Романтика

Кечкенә вакытта ул тракторчы булырга хыялланган булган. «Минем чылбырлы тракторга да, тәгәрмәчле тракторга да «правам» бар», – дип көлеп сөйли бу хакта Рузилә. (Нәкъ шулай: чылбырлы, тәгәрмәчле, дип, аерып әйтә.) Якыннарына гаҗәп тә тоелмагандыр, бәлки, аның бу хыялы. Рузилә – гаиләдәге өч кызның берсе, гел ир-ат эше эшләп үскән. Утынын да кискән, көтүен дә көткән, бозавын да арканлаган, печәнен дә чапкан... Әтисе күрше-тирә алдында: «Минем бер кызым биш егеткә тора», – дип мактана торган булган. Әмма холкы-табигате белән ир-атка тартым булса да, хатын-кыз барыбер хатын-кыз булып кала инде ул. Мәктәпне тәмамлагач, әнисе һөнәрен сайлый кыз – Алабуга педагогика институтының тарих-филология факультетына укырга керә. Институттан соң, туган ягына – Зәйгә кайтып, 8 нче мәктәптә башлангыч сыйныфларда рус балаларына татар теле укыта. Тик тынгысыз күңел генә чагыштырмача тыныч-ипле бу вазыйфаны үз итеп бетерә алмагандыр. Нәкъ шул 1997 елда газета битләрендә кызның игътибарын җәлеп итәрлек хәбәр күренә – Чаллыда татар телендә туры эфирда эшләүче радио ачылачак икән...

– «Күңел» редакциясе Чаллы телевидениесендә урнашкан иде, ә безгә туры эфирга чыгу өчен КАМАЗ заводларының берсенә урнашкан радиоүзәккә барып йөрергә туры килде, – дип искә ала ул чакларны Рузилә. – Бәйрәм көннәрендә завод иркенләп ял итә, ә без басудан, кар күмгән сукмаклардан, кайбер урыннарда билдән көрт ерып дигәндәй, эшкә барабыз. Мин ярый озын буйлы, ә безнең кечкенәрәк гәүдәле кызларыбыз – Гөлияләр, Лилияләр, Зөһрәләр ничек йөрделәр икән ул юллардан?

Җирле мәгълүмат чаралары беренче чиратта җирле иҗат көчләренә игътибар итә (һәм бу шулай булырга тиеш тә) – «Күңел» дә Чаллы төбәгендә яшәп иҗат итүче бик күп җырчыларга дөньяга чыгарга, халык арасында танылырга ярдәм иткәндер. Әдәбият, мәдәният әһелләре белән дә даими хезмәттәшлектә булды «Күңел» радиосы. Җирле авторның яңа китабы дөнья күрә икән, бу хакта радиотыңлаучыларга да хәбәр итте, аларны әдипнең җыентыкка кергән кыскаматур хикәясе белән дә таныштырып китте. Шул ук вакытта җирле кысалар белән генә дә чикләнеп калмадылар кызлар. Рузилә алып барган «Бер җыр тарихы» тапшыруы татар мәдәни дөньясының иң якты йолдызлары белән очрашулар булып хәтерләргә сеңеп калды. Рузиләнең коммерция бүлегенә күчүе, «Күңел» радиосы өчен акча табучыга, эшлекле ханымга әйләнүе дә, нигездә, шушы тапшыру белән бәйле...

Эшлеклелек

Товарны җитештерү – бер хәл, аны әле сата да белергә кирәк. Без бу хакта йөз кат ишеткәнбездер һәм йөз мәртәбә килешкәнбездер, әмма моңа карап кайсыбыз гына сатарга

өйрәнде икән? Үз хезмәтеңне сату – сәүдәнең дә иң кыенлыдыр әле ул.

– Мин беренче тапкыр «Бер җыр тарихы» тапшыруын сатып карадым, – дип искә ала хәзер Рузилә. – Ягъни шушы тапшыруым вакытында эфирга чыгару өчен реклама таптым. Башта бер тапшыру, аннары икенчесе өчен...

Мин акча өчен эшләмим, дип үз-үзеңне бик озак алдап йөрергә буладыр, әмма сүз акча турында гына да бармый бит әле бу очракта. Хезмәтеңә ихтыяҗ булу, җитештергән «продукция»ңнең файда китерүе кыйммәт. Рузиләнең коммерциягә дә сәләтле икәнен күреп, Чаллы телевидениесенең ул чактагы җитәкчесе Рахман Шәфигуллин реклама бүлегенә күчәргә тәкъдим итә.

«Күңел» радиосы җитәкчесе буларак, бүген Рузилә ханымга коммерция турында да, иҗат турында да бердәй дәрәҗәдә уйларга туры килә. Иҗат кынамы соң – хәтта «Күңел»не үзгәртү турында да.

– Без 35 яшьтән алып 55 яшькә кадәрле тыңлаучыларны күздә тотып эшлибез, – дип сөйли Рузилә. – Тормышта үз урынын тапкан кешеләр инде бу, нигездә.

Аудиториягә бәйле рәвештә, радионың юнәлешен дә яңабаштан тәгаенлиләр. Ул, һичшиксез, оптимистик булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килә коллектив. Бүген «Күңел»дә күңелле хәбәрләргә, дәртле көйләргә өстенлек бирелә икән, гаҗәпләнмәгез – бу сезнеңбезнең кәефне күтәрү өчен эшләнә. Коллективны яшьләр, димәк, яңа тапшырулар белән дә баеталар. «Җитәкчегә соравым бар», «Күңелдә калган җырлар», «Җомга вәгазе» кебек җитдирәк тапшыруларга җиңелрәкләр – «Кем? Кемне? Кайда?», «Автомунча», «Тор, уян, киен, җырла», «Фото-шәп» сәхифәләре дә өстәлә... Яшьләр, дигәннән, Динар Вәлиев, Алинә Хисмәтуллина кебек креатив, кызыклы яшьләр эшли бүген «Күңел»дә. «Түребездә кунак бар» тапшыруы Чаллы телевидениесеннән туры эфирда да күрсәтелә. «Күңел»не бүген интернет аша чит илләрдә дә тыңлыйлар.

Һәм тагын романтика

«Күңел»дә Рузиләнең журналист буларак даими алып барган темаларының икенчесе – экология. Ул бу темага бик күп тапшырулар эшли, күп мәртәбәләр республикакүләм бәйгеләрдә катнаша һәм, әлбәттә, җиңә дә. Әмма сүзем әле җиңүләр турында түгел. Иң мөһиме – бу һәрвакыт актуаль булган проблема Рузиләне урман белән дуслаштырып калдыра.

– Түбән Кама милли паркы җитәкчесе Афанасий Данилов белән күп кенә тапшырулар әзерләгән идек, – дип искә ала Рузилә. – Урман хуҗалыгы белән төрле чорда җитәкчелек иткән министрлар Әбүзәр Гаянов, Наил Мәһдиев, бүгенге министр Алмас Нәзиров белән дә. Журналист буларак, бу тармак кешеләре белән чынлап та еш очрашырга туры килде миңа. Бу тапшырулар минем өчен кызыклы булып, урманчылар – үзгә бер халык булып күңелгә кереп калды да.

Лубян урманчылык техник колледжының 95 еллык юбилеенда да булырга туры килә әле Рузиләгә. Һәм тема белән дистә елларга сузылган менә бу дуслык аны шушы урманчылар әзерли торган уку йортына читтән торып укырга керергә этәрәдер дә. Нинди дә булса бай хатынының инглиз теле курсларына йөрүенә мин үзем гаҗәпләнмим. Тик Рузилә очрагы башка бит. Тормышында аерылышу кебек авыр чорлар кичергән, бөтенесен яңабаштан башлап җибәргән, бүгенге көндә сәләтле бер егет үстерүче (улына инде 11 яшь), кыскасы, мең төрле мәшәкатькә күмелгән ханым ул.

Алар күптән радио тыңлаучыларның ахирәт-дусларына әйләнеп беткән.

– Син укып чыккач, чыннан да урманчы булырга уйлыйсыңмы?

– Анысын инде кем белгән, – дип елмая Рузилә. – Бүген минем урыным, әлбәттә, «Күңел»дә. Белгән, яраткан эшем бу! Мин үзем эштән дә, үзгәрештән дә курыкмыйм. Мин бер урында таптанудан куркам...

Күңел дигәннән... Язмабыз азагында сезгә «Күңел»нең тагын бер зур яңалыгын да җиткерик әле – тиздән радионың тулысынча FM ешлыгына күчеп бетүе көтелә икән. Ә бу аны Чаллы төбәгендә генә түгел, бөтен республикада тыңлый алачаклар, дигән сүз. Димәк, «Күңел» дә үсештә!



■ «Күңел» коллективының «төше» бүген дә шушы булдыклы кызлар – Зөһрә Сибгатова, Алсу Вәлиева, Резеда Шакировалар! Нәкъ менә алар тырышлыгы белән «Күңел» инде дистә еллар буе Чаллыда һәм тирә-юнь районнарда яшәүчеләр өчен аерым бер рухи үзәк ролен үти. Рәсми оешмалар беренчелекне бәлки телевидениегә, матбугатка бирә торганнардыр, бәхәсләшмим. Гади татар кешесе өчен җыр-моң, үзебезчә сөйләшү, аралашу мөмкинлеге кирәк бит.

PRESSA.RU

БӘБИ ЯЛЫНДА – ЭШТӘ



















Бәби ялына чыгар алдыннан яшь әни ни дип уйлый? «Ял» дигәч, ял итәрмен» диптер инде? «Тормышымны тәмам үзгәртәм» дигән акыллы сүзтезмәләр дә баш калкыта. Өйдә кечкенә бала белән бер-ике ел «ял» итеп алгач, үлеп берәр нәрсә эшлисе килә башлый. Ул эш, гадәттә, яраткан шөгыльдән борынлап чыга. Кемдер хоббие өчен күбрәк вакыт таба башлый, шуннан ләззәт кичерә. Ә кемдер, яраткан эшенең әҗерен күрә башлый (шулай ук ләззәтләнеп, әлбәттә).
Минем дә бер кулымда балам булса, икенче кулымда бәйләү энәләре яки ыргак иде. Сәйләннәр үреп, алка-муенсалар җыйдым, пледлар, йомшак уенчыклар бәйләдем. Әҗере булдымы? Анысын белми-сизми калдым. Саткалаган булдым инде шунда – анысы да ләззәт алыр өчен, чөнки ул акчага яңадан материаллар алып, бүләккә һәм кабат сатуга бизәнү әйберләре ясадым. Кыскасы, минем өчен процессы мөһимрәк булды. Башка яшь әниләрдә ничек икәнен белешер өчен журналыбызның социаль челтәрдәге бер төркемендә сөйләшү ачып җибәрдем. Тиктормас әниләр бихисап икән. Кемдер минем кебек яңа эшнең процессыннан да канәгать, ә кемдер өстә әйтелгән «перезагрузка» вакытында үз-үзен башка шөгыльдә табып, элеккеге эшеннән китеп тә барган.

Альбина ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА: «Каш остасы мин. Юк, белгечлегем буенча мин – икътисадчы. Транспорт компаниясендә логист булып эшләдем. Декретка чыккач, башкалар кебек үк мин дә, туктап, үземә сорау бирдем: «Биш елдан соң үземне кем итеп күрәм соң мин?!» Бу сорауны мин үземнең, апамның, дус кызларымның кашларын рәткә китереп, барысыннан да чибәркәйләр ясаган мәлдә бирә идем. Яратам мин бу эшне. Яшүсмер вакытта абыемның кашларын йолкыганда чәчәк аткан мәхәббәт бу. Кешегә карап: «Кашларың синеке түгел. Килешми. Сиңа башка кашлар кирәк», – дип әйтә алам. (Кондукторлар кешегә күз ташлаган саен, 25 сум күрәдер, мин дә шулай ук, кешегә тыныч кына карый алмыйм – кашын тикшерәм, төрлеләрен «тагып карыйм»). Әйе, мин косметолог булырга теләдем. Әмма моның өчен медик белеме булырга тиешлеге кикригемне шиңдерде...

Ә бер көнне иремнең: «Салонга бар да ясаттыр инде кашыңны, ник интегәсең?» – диюе мине сискәндереп җибәрде. Нишләп барыйм? Миңа килсеннәр! Ирем бу идеямне хуплады! Шуннан соң тормышым үзгәрде дә куйды. Семинарлар, лекцияләр, дәресләр... Әмма мин алган белемемнән һаман канәгать түгел идем. Юк! Бу – үзешчәнлек кенә! Профессионал булыр өчен Мәскәүдә укып кайттым. Менә хәзер мин канәгать! Клиентларым да.

Баштагы авырлыклар онытыла бара. Хәзер минем карамакта өч мастерым һәм зур булмаган студиям бар. Кызлар! Егетләр дә! Онытмагыз! Тышкы матурлык – каштан башлана!

Элеккеге эшемә кайтумы? Ә мин моңарчы кайда эшли идем әле?..»

Эльмира ГАЛЛӘМОВА: «Алдан ук әйтеп куйыйм – өч бала белән декрет ялында утырганда, ике югары белем алдым. Әйе.

Икенче балам белән декретта булганда ук бик күп фәнни хезмәтләр язарга булыштым, ул вакытта конкуренция юк иде – балалар бакчалары, мәктәпләр өчен бик күп татарча стендлар ясау, текстлар язу һәм башка хезмәтләр башкардым. Хәтта туйлар өчен плакатлар да ясадым! Миңа бик ошый иде!

Өченче балам белән берлектә икенче дипломны якладык! Ә аннары рәхәтләндереп, тәмләп открыткалар (скрапбукинг) ясауга күчтек (сатар өчен түгел, укытучыларга, туганнарга, дусларга бүләк итәр өчен).

Кул эшләрен яратуым әниемнән кучкәндер. Камыр ашларын бик яратып, оста пешерә. Бала чагымда әтием аңа станок ясап бирде дә, әнием шарфка кадәр сукты!

Декретка кадәр мин нотариаль конторада, пенсия фондында эшләдем. Анда кайту турында уйларга иртә әле. Бәхетле декрет ялым дәвам итә!»

Руфина ГАЛИЕВА: «Бала белән өйдә утыру кемгәдер җәза, кемгәдер бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләр чоры. Мин – икенчеләр рәтендә.

Декрет ялына китүемә... алты ел булды быел. Аңа кадәр мәктәптә эшләдем, мин – инглиз теле укытучысы.

Бервакыт кибеттә балага кием карап йөргәндә кулдан ясалган чәчкә-брошкага күзем төште. Сатып алдым мин моны. Ул миңа шулкадәр ошады, шундыйрак бизәнү әйберен үзем дә ясый алмыймммы икән, дип, интернеттан мастер-класслар эзли башладым. Таптым да!

Шуннан башланып китте дә инде! Балалар, хатын-кызлар өчен бик күп чәч аксессуарлары ясадым. Сатып алдылар бит! Аннан соң интерьер агачлары-топиарийлар ясарга өйрәндем. Аларны сату өчен социаль челтәрдә төркем булдырдым. Кул эшләремә кызыксыну уяту өчен үземә үзем фотограф та, дизайнер да булырга туры килде.

Монысында да туктамадым. Тора-бара газетадан кәрзиннәр үрү белән мавыгып киттем. Моңа кирәкле материал тулып ята, әллә ни авырлыгы да юк. Газета битен берничәгә бүләсең дә, бәйләү энәсе ярдәмендә бөтереп, көпшәчекләр ясыйсың. Шул көпшәләрдән,

PRESSA.RU

талдан үргән кебек үк, савытлар үрәсен, аннан буяп, лаклагач, менә дигән эшләнмә килеп чыга. Белмәгән кеше күрсә, ул савытларның гап-гади газетадан ясалганын башына да китерми!

Хәзерге вакытта миңа буяулар ярдәмендә савыт-саба, киемнәр бизәү ошый. Милли орнаментлар төшереп буйыйм, бик матур килеп чыга. Иң мөһиме: көндәлек эштән ял иттерә, бертөрлелектән качарга ярдәм итә, җанга ләззәт бирә. Шуңа күрә үзебезнең татар кызларына әйтәсем килә: кул эшләренә өйрәнегез! Хәзер ничек өйрәним икән дип баш ватасы юк, интернетта нинди генә мастер-класслар очрамый. Материал кирәк булса, кибетләр күп. Анда барырга вакыт булмаса, өйгә үк китереп бирәләр. Аңа бит акча кирәк дисәгез, кул эшләренең күп чыгым сорамаганнары да шактый, мәсәлән, чигү, шул ук кәрзин үрү.

Миннән булмый ул, дип кул селтәмәгез. Йөзләгән төр хобби арасыннан үзегезгә туры килгәнен табарсыз.

Үзем өчен хоббилы булуның бик күп уңай якларын ачтым:

Кечкенә бала белән өйдә утыручы ананың сыйфатлы ял итәргә мөмкинлеге юк, аның бик тиз «аккумуляторы» утыра, менә шунда яраткан кул эше аңа «зарядка» ролен үти, өйдәге эшләрне башкарырга да, бала белән шөгыльләнер өчен дә үзенә энергия ала. Кем әйтмешли, «песиләр чигеп утырган әни кеше эшсезлектән интекми, бу – аның «нормаль» хатын булып калу омтылышы».

- Ире эштән кайтып кергәндә аны арыган, йончыган, чәчләре тузган хатын түгел, ә күзләре янып торган яшь ханым каршы ала.
- Эш белән мавыккан ана – балаларына менә дигән үрнәк. Кызыма 4 яшь булганда, «мин топиарий ясыйм» дип уйный иде, хәзер аңа 6 яшь, миннән күреп открыткалар ясый башлады.
- Яраткан кул эше үзе бер ләззәт булса, үз кулың белән, күңел җылыңны кушып ясаган әйберләрне якыннарыңа бүләк итү – үзе бер рәхәт.
- Ясаган әйберләрне сатып, кесәгә әз-мәз акча да тама. Анысына яңадан хобби өчен материал аласың инде.

Альбина ГАЛИЕВА: «Кечкенә вакыттан ук әни токмач кискәнен карап тора идем. Ул миңа: «Өйрән, тормышта кирәк була ул!» – дия иде. Мин елмаеп: «Әни, токмачны сатып алырмын әле, йә син безгә җибәреп торырсың», – дип әйтә идем. Чыннан да, әнинең сүзләре дөрес булган. Токмач баса белүемнең кирәге чыкты. Токмачлы аш шулкадәр тәмле бит ул!

Шуннан башыма бер уй килде: туктале, мин әйтәм, татар милли ризыгын безнең Казан халкына да ясап ашатырга була бит. Су өстәмичә, авыл йомыркасыннан басып кискән сап-сары токмачларымны яратып алдылар. Мантый, пилмәннәр дә сорый башладылар.

Яңа рецептлар уйлап таба торам – шоколадлы озынча токмач дисеңме, төрле төсле токмачлар, төсле мантый һәм пилмәннәр. Бүген клиентны гаҗәпләндерә белергә кирәк!

Миңа бу хобби бик ошый, мин аны эш дип тә санамыйм. Эш бит ул авыр нәрсә – хәлне ала кайчак. Ә хобби ул – күтәренке кәеф чыганагы!

Кеше белән аралашырга яратам, ә инде башкаларны тәмле ризык белән сыйлауга килгәндә – мин беренче!

Бу эшемне бисмиләәһир-рахмәәнир-рахиим дип башлап җибәрәм.

Аллага шөкер, бу һөнәрем чәчәк ата – заказларым күп! Миңа рәхәт!

Мин тормыш иптәшем Илсурга бик рәхмәтлемен. Улым Ислам гел шатландырып тора. Алар мина көч өсти!

Әмма ни дисәң дә, декреттан соң да эшкә чыкмыйча булмый, чөнки социаль ипотекага фатир алырга телибез. Эшкә чыккач та бу хоббины ташламам кебек әле».

Гүзәл ХӘСӘНОВА: «Декрет ялына кадәр «Татфондбанк»та эшләдем. Икътисад магистры мин.

Улыбыз Азамат тугач, аның беренче сүзләре «әти», «әни» булуын теләдек. Гаиләбездә ана телебездә сөйләштек. Азаматны беренче китаплар белән таныштырырга вакыт җиткәч... нәниләр өчен татар телендә катыргыдан ясалган бер генә китап та булмавы ачыкланды. Нәкъ шул вакытта (2011 ел иде ул) Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы социаль эшмәкәрләргә ярдәмгә грантлар өләште. Грантның күләме 300 мең сум иде. Шуны белдек тә, тәвәккәлләдек. Бизнес-проект яздык, аны якладык һәм грант оттык!

Үз һөнәрләренең осталарын – мөхәррирләрне, рәссамнарны, дизайнерларны бер командага җыйдык, һәм алар ярдәме белән грант акчасына беренче ике катыргы китабыбызны чыгардык. Аларны Ростов шәһәрендәге «Проф-пресс» типографиясе бастырды. Ник дисәгез? Татарстанда мондый төр китапларны бастырырлык нәшрият юк.

Китапларны без 2012 елның маенда сата башладык, аларның татар телендә нәниләр өчен катыргыда бастырылган беренче китаплар булуына горурланабыз.

Бүгенге көндә яңа китапларыбызны инде нәшриятыбызның үз акчасына чыгарабыз. «Юлбасма» дип исемләнгән үзебезнең китап нәшриятының интернет-кибетен булдыру белән мәшгульмен. Быел ике телдә китаплар бастырып чыгардык – «Иске татар бистәсе» һәм «Кырлай әкиятләре». Планда тагын дүрт китабыбыз бар. Эш гөрли. Элеккеге эшемә чыгу турында уйларга вакыт та юк...»

Сөмбел ГАФФАРОВА әзерләде.



ИБРАҺИМОВА Фәнилә

Казан дәүләт педагогика институты

Кияүдә, өч кыз әнисе

Карьера: Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумы

Тормыш шигаре: «Яшәү матур, яшәү шундый ямьле, якыннарга сөю өләшеп...»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Җылы сүз гел кирәк...

Үз гомеремдә шигырь язып карамаган кеше юктыр ул. Мин дә каләм тибрәткәлим. Күңел түрендә булган хисләр, йөрәкне әрнеткән уйлар шигъри юллар аша яңгырый. Шул иҗат җимешләремне бергә туплап, ниһаять «Бер җылы сүз...» дигән шигырьләр җыентыгымны чыгардым. Үзебезнең «Минзәлә» газетасы редакциясе хезмәткәрләренә рәхмәт: алар китап итеп бастырды. Авылыбызда – Тауасты Байлар мәдәният йортында китапны тәкъдим итү кичәсе булды. Туганнарым, хезмәттәшләрем, авыл халкы – барысы да килделәр. Бер сулышта узды ул! «Кеше күңеле гел җылы сүз көтә», – дигән сүзне барысы да кабат-кабат әйттеләр.


Театр яктыга, нурга илтә!..

Үз театры булган район, аның халкы бик бәхетледер ул, минемчә. Безнең С. Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт театры күптән түгел үзенең 80 еллык юбилеен билгеләп узды. Минзәләлеләр өчен генә түгел, республика халкы өчен дә зур бәйрәм булды ул. 80 ел буена халыкка хезмәт иткән театр коллективын котларга республикабызның төрле шәһәрләреннән мәртәбәле кунаклар, җитәкчеләр килде. Театр коллективы кичәнең беренче өлешендә котлаулар кабул итсә, икенче бүлектә тамашачы хөкеменә Кәрим Тинчуринның «Каракүз» спектакленең премьерасын тәкъдим итте. Көлдек тә, еладык та, уйландык та бу кичтә. Үз артистларыбыз белән горурландык!

«Кешеләргә ярдәм итү рәхәт...»

Моңарчы Ник Вуйчич турында без ишетеп яки аның үз китаплары аша гына белә идек. Инде менә ул Казанга үзе килде! «Татнефть-Арена» боз сараенда халык белән очрашты. Менә кемнән үрнәк алырга безгә! Австралиядә туган бу егетнең аягы да, кулы да юк. Ә ул боегуны белми! Тулы канлы тормыш белән яши: ике югары белеме бар, компьютерда яза, гольф уйный, серфинг белән шөгыльләнә, балык тоту белән мавыга, йөзә... Ник – менә дигән гаилә башлыгы: аның искиткеч чибәр хатыны һәм ике баласы бар. Берәү булса, язмышына үпкәләп утырыр иде, ә ул дөнья буйлап йөреп, башкаларга булыша!

сөендерде





көендерде


сөендерде





көендерде

сөендерде





көендерде

Әнкәйләрне сакла, Ходаем!..

Тормышыбызга күптән түгел килеп кергән Әниләр бәйрәме үзебезнекенә әйләнеп бара. Шулай булмыйча, безнең өчен дөньядагы иң якын кеше бит ул әнкәйләребез. Һәм без аларны Әниләр көнендә – бәйрәмдә генә түгел, көн саен, сәгать саен истә тотсак, кадерләсәк икән. Үзем күптән әни, инде дәү әни булсам да, киңәш сорап һаман аңа киләм бит әле... Әнкәй авырып тора әле менә, табиблар операция кирәк, диләр. Күңелдәге борчуның иге-чиге юк... Көн туса, әнкәемнең исәнлеген-саулыгын сорап, Ходайга ялварам. Барысы да яхшы булыр дип өметләнәм.

Безнекеләр дә ким түгел бит...

Соңгы вакыт үзәк телевидение каналларында балалар белән бәйле әллә ничә яңа тапшыру дөнья күрде. «Лучше всех», «Синяя птица», «Голос. Дети»... Бу проектларның һәрберсен көтеп алып, яратып карыйбыз. Талантлы балалар шундый күп, һәм алар бик төрле. Арада татар фамилиялеләр килеп чыкса, улыбыз, кызыбыз кебек күреп, алар өчен бигрәк тә сөенәбез. Әйе, башкаларга күрсәтерлек талантлы балалар үзебездә дә җитәрлек. Алар да берәүдән дә ким түгел. Тик нигә бездә боларга охшаш тапшырулар юк соң? Теләк юкмы, әллә мөмкинлекләрме? Өметле малай-кызларга киләчәктә юл шундый тапшырулар аша да ачыла бит.

Ул үзе бер дәвер иде...

Фидель Кастро вафат. Август аенда аңа 90 яшь тулган иде. Кубадагы революция лидеры дип атыйлар аны. Әмма алай дип кенә әйтү аз бугай. Фидель Кастро һәм аның дусты Че Гевара портретлары, ирек һәм бунтарьлык символы буларак, дөньяның төрле почмагында яшәүче яшьләрнең майкаларын бизи. Кастрога кадәр Куба бай америкалыларның ял итү урыны була. Революциядән соң аларның затлы виллалары тартып алына – Американың борын төбендә Куба яңа тормыш кора... Үзенең фикере белән бөтен дөньяны санлашырга мәҗбүр иткән мондый шәхесләр сирәк. Кастро белән генә түгел, ул яшәгән тулы бер чор белән хушлашабыз...

PRESSA.RU



ЯЗМЫШ САБАГЫ

Ризидә
ГАСЫЙМОВА

АЛДАН УК КИСӘТЕП КУЯМ – ҮЗӘКЛӘРНЕ ӨЗГЕЧ КЫЗГАНЫЧ ТАРИХ ТҮГЕЛ БУ, Ә ГАП-ГАДИ КЕШЕЛӘР ҺӘМ АЛАР АРАСЫНДАГЫ ГАҖӘЕП МӨНӘСӘБӘТЛӘР ТУРЫНДА ХИКӘЯТ.

Автобуста, бертуктамый артка таба йөгергән көзне, көзге манзараны күзәтеп, Чаллыга кайтып барам. Яныма арткы урыннарның берсеннән заманча, әмма тыйнак, пөхтә киенгән мөлаем гына ханым күчеп утырды.

– Сезнең яндагы урынның буш булуын яңа күрдем, – диде ул. – Хатын-кызга бер-берсе янында утыру уңайлырак инде.

– Әйе шул, – дип килештем мин дә. – Сөйләшеп кайтырбыз, ичмасам, юл буе.

Бу болай, сүз булсынга гына әйтү иде инде, дөресен әйткәндә. Әмма, ни гаҗәп, ул көнне чыннан да сөйләшеп сүз бетмәде безнең. Икебез дә яшьтәшләр һәм хәтта ки адашлар да булып чыккангамы, уртак темалар табылып кына торды, хәтта «сингә» күчүебезне дә сизми калдык. Ул бәян иткән истәлекләрнең, кызыклы вакыйгаларның арадан берсен аерып алып, бүген сезгә дә сөйләмәкче булам.

Сүзне, мөгаен, шуннан башлау кирәктер – бердәнбер кызлары университет тәмамлау сөенеченнән алар аңа машина бүләк итәләр. Һәм кыю, тәвәккәл кызый шундук җилдереп йөри дә башлый.

– Мин ул көнне Чаллыдан кызым янына Казанга кунакка килгән идем, – дип сөйли адашым. – Ул, дус кызларым белән йөреп кайтабыз, дип, кичке биләмгә чыгып китте, мин фатирда ялгызым калдым. Кинәт телефон шалтырый. Чаллыдан ирем шалтырата икән.

– Нишлисең әле? – дип кызыксына бу ничектер сак кына.

– Нишлим инде, Алинәне көтәм, – дим.

– Син... курыкма гына инде, яме. Ни бит... Алинә авариягә очраган. Ул инде больницада икән, ашыгыч ярдәм машинасы алып киткән. Хәле алай начар түгел, диләр. Син борчылма, яме. Бар дә әйбәт булыр. Мин юлда, Казанга килергә чыктым.

Борчылма, дип әйтүе генә ансат... Ничек борчылмыйсың, ди?! Үзем ашыга-ашыга киенәм, үзем дер-дер киләм. Минут дигәндә әзерләнеп бетеп, ишек төбенә килеп бассам – ишек бикле! Алинә, төнлә кайтып мине уятмас өчен, бердәнбер ачкычны үзе

белән алып киткән иде. Инде нишләргә соң? Нишләргә?!

Минем, мөгаен, үз гомеремдә моннан да кыен хәлдә калганым булмагандыр... Тукта, дим, шушындый чакларда кемнәрнедер ярдәмгә чакыралар түгелме? Кешегә ярдәм итәргә тиешле махсус хезмәт тә булырга тиеш кебек. Чит илләрдә коткару хезмәте дип атала бугай ул. Ә бездә ничек соң? МЧСмы?

Трубканы бер ир-ат алды. Һәм мине, дулкынланып, ашыгып-кабаланып сөйләгән җиремнән, тыңлап та бетермичә туктатты:

– Ә сез бездән ни телисез соң?

– Миңа ничек тә кызым янына больницага барырга кирәк. Бәлки ишекне ачып бирә алырсыз? Бәлки тәрәзәдән төшәргә булышырсыз? Бушка түгел бит, мин сезгә түлим! Түлим!

– Квартира сезнекеме?

– Юк, кызым снимать итеп яши.

– Бәлки сез фатир карагыдыр, ялгыш бикләнеп калгансыздыр. Без каян белик?

Мондый җавапны, дөресрәге, сорауны ишеткәч, мин инде артык сүз озайтып торуны кирәксенмичә, трубканы куйдым. Барыбер килмәячәкләрен ап-ачык аңлаган идем инде. Башка яңа фикер килде – әллә янгын сүндерүчеләргә шалтыратып караргамы икән?

Трубканы алган кырыс тавышлы ханымны үземнең фикердәшем, аркадашым дип санап, ашыга-кабалана күңелемне бушаттым. Тавышым калтыранып чыккандыр, еларга әзер булуымны, әлбәттә, сизгәндер. Шуңа да сүзне озакка сузмагандыр.

– Адресыгыз ничек? – диде ул. – Борчылмагыз, мин хәзер сезнең янга егетләрне җибәрәм.

Мин шундук балконга чыгып, тәрәзәгә капландым. Биш минут көттемме, унбиш минутмы – хәтерләмим. Кызыл төстәге янгын сүндерү машинасын күргәч, сөенгәнем, аның безнең тәрәзәгә якын килә алмыйча, кире чигенгәнен күргәч, (тротуар тулы машина!) көенгәнем хәтердә. Чигенделәр, әмма китеп бармадылар, рәхмәт төшкерләре! Җәяүләп килделәр дә, тәгәрмәчләренә типкәләп, берәм-берәм безнең тәрәзә каршындагы машиналарны «уята» башладылар. Шулай тырыша торгач, юлны «ачтылар» һәм баскыч белән дүртенче катка менеп, мине тәрәзәдән алдылар. Аннары биргән акчама борылып та карамыйча, тиз арада китеп тә бардылар.

...Больницада кызым янында утырып чыккан ул төн минем өчен мең кат бәхет һәм мең кат газап булгандыр. Бәхет – чөнки балам, ничек кенә булмасын, исән. Мин аның җылы, йомшак кулларыннан сыйпый алам. Газап, чөнки күңелдә әле күпмедер дәрәҗәдә билгесезлек бар, сәламәтлегенә никадәр зыян килүен белмәгәнгә күрә хафалану бар.

Икенче көнне, табиб белән очрашып сөйләшкәч кенә, бераз тынычландык без. Тик күңелне шундук икенче төрле борчу биләп алды – ЮХИДИ хезмәткәрләренең юл һәлакәтендә Алинәне гаепле дип табасылары килә икән бит. Юк, моны безгә ачыктан-ачык әйтмиләр, әмма ничектер сиздерәләр. Без, бәлки, килешкән дә булыр идек, Алинә каршы килә:

– Юк, – ди. – Нигә сез миңа ышанмыйсыз? Үзе тиешсез урында борылды, үзе каршы юлга чыкты ул.

«Үзе»нең кем булуын да безгә башта әйтмәгәннәр иде, йөри торгач кына ачыкладык: шактый югары урында утыручы җитәкче икән. Аварияне шаһитлары да табылды тагын – чыннан да, барысы да нәкъ Алинә сөйләгәнчә булган. «Кем соң ул безнең кызга килеп бәрелгән кеше, нигә яшерәсез? Ул бәлки исерек булгандыр?» – дип, мин дау күтәрә башлагач, ЮХИДИ инспекторы, кызып китеп, кулыма ниндидер белешмә тоттырды. «Һәркайсыгыз артыннан йөрергә вакытым юк, – ди. – Алайса аның нинди хәлдә булуы турында мәгълүматны больницадан үзегез барып алыгыз».

Әле ярый барганмын! Теге кешенең авария көнне исерек хәлдә булуы турында язылган кәгазь алып кайттым бит мин. Шуннан соң гына үзенең гаепле булуын таныды ул.

Стресс вакытында кеше күп нәрсәгә сәләтле була, диләр – «01» номерын икеләнеп тә тормыйча җыйдым.

Бу ыгы-зыгыларның азагы, Аллага шөкер, безнең файдага тәмамланды. Очраштык, сөйләштек һәм ахыр чиктә... килешүгә бардык без. Ул кеше Алинәнең ярамсызга чыккан машинасын элеккеге бәясенә сатып алды. Ә без эшне зурга җибәрмәскә ризалаштык. Югыйсә аны эшеннән алырга мөмкиннәр дип аңладык. Безгә аны эшеннән алдыру ник кирәк? Гаебен тануы гына мөһим иде. Югыйсә Алинәнең күңелендә мәңгелек җәрәхәт булып калачак иде.

– Монда минем өчен иң гаҗәбе, беләсеңме, нәрсә? – дидем мин чын хикәят шушы урынга җиткәч. – Сиңа янгын сүндерүчеләрнең ярдәмгә килүе. Бу бит аларның эше түгел! Яхшы күңелле кешеләр туры килгән инде. Ә авария ясаган җитәкче, минемчә, ансат котылган. Шушы хәлдән соң сабак алса ярый ла...

– Алгандыр, – дип җавап бирде адашым.

– Нигә алай бик ышанып әйтәсең?

– Алинәнең туган көненә ел саен чәчәкләр китерә. Онытмый! Хәер, онытырга, туган көннәре дә бер көнне бит аларның!

– Ә Алинәнең сәламәтлеге ничек хәзер?

– Болай ярыйсы. Әйбәт кенә кияүгә чыкты, Аллага шөкер. Оныгыбыз үсеп килә.

Авария турында сөйләшкәндә икебезнең дә күзләр яшь белән тулган иде, чәчәкләргә һәм оныкларга күчкәч, күз яшьләре аша елмаештык. «Тормыш дәвам итә һәм... безнең кырыс күңелләрне дә йомшарта ала, күрәсең», – дип уйладым мин бу минутта. Юкса кемдер ярдәм итеп булмас җирдән дә ярдәмгә килер, кемдер кичереп булмастайны да кичерергә әзер булыр идемени соң? Гаҗәп...

PRESSA.RU



МУКАМ САРАЕНДА...



Рәмзия КАШАПОВА

АХАЛТӘКӘ ЮРТАКЛАРЫ, КУЛДАН ТУКЫЛГАН КАБАТЛАНМАС КЕЛӘМНӘР МӘРКӘЗЕНӘ – МУКАМ (МОҢ) САРАЕНА «СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ ОЕШТЫРГАН «ХӘЗЕРГЕ ТАТАР МИЛЛИ СӘНГАТЕ» КҮРГӘЗМӘСЕН АЛЫП КИЛДЕК.



■ Төрекмәнстан башкаласы Ашхабад шәһәренә 1881 елда нигез салынган. Шәһәр Иран чигеннән 25 км төньякта, Копетдаг тау итәгендә урнашкан. 2013 елгы рәсми статистика буенча анда 1 миллион кеше яши.





Казан рәссамнары һәм осталары белән Санкт-Петербургта Россия этнография музее күргәзмәсендәге экспозицияләрне карап йөргәндә, Төрекмәнстан витринасы янында озаккарак тукталдык. Искиткеч матур келәмнәр, таслап өелгән йон юрганнар, милли киемле манекеннар, йорт кирәк-яраклары, төрекмәннәрнең көнкүреше безне таң калдырды. «Их, үз күзләрең белән күреп, тотып карасаң иде боларны!» – дигән уй һич баштан чыкмады. Ул фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килгәндер: күп тә үтми шул ук төркем белән Төрекмәнстан башкаласы Ашхабадка очтык.

Татарстан Президентының Төрекмәнстанга эшлекле визиты кысаларында Татарстан һәм Төрекмәнстан арасындагы күпьяклы хезмәттәшлекне үстерү һәм бәйләнешләрне ныгыту максатында узган мәдәни чараларда әнә шулай итеп без дә катнаштык.

Кояшлы Ашхабад – ак мәрмәр кала – октябрь аенда 25 градус җылылык белән балкып каршы алды безне.

Төрекмәнстан башкаласы – дөньяның иң якты ак мәрмәр каласы (ак мәрмәр белән йөгертелгән 543 яңа бина), дөньяда иң биек әләм колгасы (133 метр), иң зур фонтан комплексы (27 синхронлашкан фонтан), ябык типтагы иң зур күзәтү боҗрасы һәм – телебашнядагы сигез кырлы Угыз-хан йолдызы – иң зур архитектур йолдыз булган шәһәр – берничә тапкыр Гиннесс рекордлар китабына кертелә.

Шәһәрне күзәтеп барабыз, тәрәзәдән шәйләнүче берсеннән-берсе матур биналар белән кызыксынабыз. Машина йөртүче: «Монысы – төзүчеләр сарае, Төрекмәнбашы хөрмәтенә шулай атала, үзәк никахлашу сарае да Төрекмәнбашы исемен йөртә», – дип, юл буе безне биналар белән таныштыра. Ашхабадта урамнар, проспектлар, мәйданнар, төрле учреждениеләр аның исемендә. «Төрекмәнбашы» (бөтен дөнья төрекмәннәре башлыгы), соңрак «Бөек Төрекмәнбашы» титулы мәҗлес карары буенча рәсми рәвештә беренче Президент Сапармурат Ниязовка бирелә. Каспий диңгезе ярында Төрекмәнбашы дигән шәһәр дә бар хәтта, совет чорында ул Красноводск дип аталган. Бер шәһәр исемендә тулы бер илнең тарихы чагылган! Бездәге юллар һәм автомобильләр белән чагыштырганда, урамда кешеләр аз, машиналар да сирәк очрый. «Халык кайда?» – дигән сорауга, шофер, елмаеп: – «Эштә», – дип җавап бирә.

Шәһәр яшеллеккә күмелгән. Тарихи өлеше ачык һавадагы музей итеп сакланган, ялт иткән чисталык соклану уята. Кунакханә тәрәзәсеннән таулар күренә, таулар артында – Иран... Чит ил күренеше төрле хисләр уята.

Биредә биналарны фантазия белән төзиләр икән: Мәгариф министрлыгы бинасы – ачык китап рәвешендә, Нефть һәм газ министрлыгы бинасы – чакматашны хәтерләтә. Яңа матур йортларда кемнәр яшәве белән кызыксынабыз. Фатирлар, нигездә, министрлык хезмәткәрләренә бирелә икән. Аларда хәтта дәүләт кредит программасы да бар: әгәр кеше бер министрлыкта 10 ел эшләсә, фатирны кредитка сатып ала; ярты бәясен министрлык түли, ә калган өлешен үзе, процентларсыз гына, бүлеп түләп бетерә.

Төрекмәнбашы хөрмәтенә бөтен нәрсә аның исеме белән йөртелә.

Аэропортка килеп төшү белән милли киемле кызлар күзгә ташланды. Һинд хатын-кызлары гел саридан йөргән кебек, төрекмән хатын-кызларыннан кайда да милли костюмнан йөрүе хакында ишеткәнем бар иде инде. Ләкин XXI гасырда инде яшьләр джинсыга күчкәндер дисәм, бөтенесе милли киемнән, милли баш киеме «курте»дан һәм «чырпы»дан. Анда яшәүче рус хатыннары да төрекмән костюмын яратып кия икән.

Соңгы вакытта калфаклар белән кызыксынам. Кая гына барсам да, шунда яшәүче хатын-кызларның баш киемнәренә игътибар итә башладым. Кияүгә чыккан төрекмән кызы яланбаш күренергә тиеш

PRESSA.RU







түгел. Аларның баш киеме яулык белән бәйләнгән зур шиньонны хәтерләтә. Сере – мондый шиньон цилиндр формасындагы катыргы кәгазьдән ясала һәм аңа милли бизәкле яулык бәйләнә, бер белмәгән кеше, чәчләре озын һәм калын икән, дип уйлый инде. «Болай йөрү уңайсыз түгелме соң?» – дигән соравыма: «Җайлы да түгел, әмма бездә тәртип шулай, түзәргә туры килә», – дип җавап бирделәр. Баш киеме зуррак булган саен, хатын-кыз зифарак, матуррак күренә. Башта сәер тоелган иде. Уйлана калдым, җентекләп тагын бер күздән кичергәч, бөтен сере аңлашылды! Башында мондый катлаулы әйбер булганда, үзеннән-үзе гәүдәне төз тотып атлыйсың икән бит. Менә ни өчен төрекмән ханымнарының олыгайгач та буй-сыннары зифа, үзләре яшь күренәләр икән!

Нәкъ менә төрекмән хатын-кызы милләтнең бизәге булып тора.

Нәкышләргә бай, колоритлы хатын-кыз костюмнарын мода белән киенүче төрекмән кызлары аеруча яратып кия. «Яка» чигүе төрле яшьтәгеләр арасында да популяр, һәм ул татар «изү»ен хәтерләтә. Яшьләр, эшлекле стильне бераз эклектика белән аралаштырып, бик яратып тахьядан йөри. Өлкән яшьтәгеләр чигүләр белән бизәлгән «дон», «койнек», «чавыт» кебек уңайлы милли күлмәк-халатларга өстенлек бирә.

Шунысы ошады: киемнәрнең мөселманнарныкын хәтерләткән бернинди гарәп-төрек вариантлары юк. Барысы да үзләренеке, милли, күз карасыдай саклана. Төрекмән хатын-кызларына сокланмый мөмкин түгел!

Алар һәр заманда да ирләрне сокландырып кына калмаган, илһамландыра да белгән, алар белән иңгә-иң торып, үз халкының тарихын тудырган, гаилә учагын саклау, балалар үстерү белән бергә, гаҗәеп гүзәл сәнгать әсәрләре иҗат иткән.

Безнең эраның V меңьеллыгыннан башлап, Төрекмәнстанда бөек алиһә-анага, җир, уңыш һәм йорт учагы алиһәсенә табынганнар. Шәрыкны өйрәнгән галим М. Морозова Төрекмәнстанда булганнан соң болай дип яза: «Төрекмән хатын-кызлары турында аерым әйтергә кирәк. Алар кабатланмас матурлыклары, күз явын алырлык милли киемнәре, зифа буй-сыннары белән сокландыра. Алар ишле гаиләләрен дә карый, балалар да үстерә, ирне һәм әти-әниләрен дә хөрмәтли, өйдән тыш эшләрдә – кырда, фабрикада, мәгариф һәм медицина өлкәсендә, дәүләт хезмәтендә армый-талмый эшли. Дәүләт хакимиятенең хатын-кызга күрсәткән игътибары һәр төрекмән гаиләсенә карата сак һәм кайгыртучан мөнәсәбәте булып гәүдәләнә».

Төрекмән хатыннарының төп казанышы – ирләренең кадерләве. Алар алдынгы, заманча, белемле, юмор хисенә бай – үзем күреп кайттым!

Җай чыгу белән чын төрекмән тормышын күрер өчен базарга чыгып чаптык. Ни гаҗәп, ул «Рус базары» дип атала икән. Хуш исле кавын-карбызлар, җиләк-җимеш, борынны ярып кергән төрле тәмләткечләр исе безне тәмам ымсындырды – тәмен татып карыйсы килә башлады. Шәрык базарларына гына хас булганча, безне авыз итеп карарга чакыралар, җитмәсә. Кунакчыл елмаеп, һич ялкытып бәйләнмичә, алыгыз дип аптыратмыйча гына. Кечерәк кенә кафега кереп утырып, сыр, яшел тәмләткечләр белән самса алдык. Катламлы юка камыр кетердәп тора, үзләре әзерләгән брынза телеңне йотарлык. Хушланып, тагын юлыбызны дәвам иттек. Кызларыбыз сувенирлар дуканын камап алган! Дөя йоныннан атаклы озын оекбашлар, түбәтәйләр, күз тиюдән саклаучы амулетлар, кулдан ясалган бизәнү әйберләре, кечкенә җыйнак сумкалар – берсе дә игътибардан читтә калмады, бөтенесен җыйдык!

Базарда бәяләр арзан, сезонлы җимешләр, яшелчәләр бер дә кыйммәт түгел. Кавынны, мәсәлән, 50 сумга алдык. Ни генә юк: кара уылдыкка кадәр саталар! Кипкән җимеш, чикләвек, күз тиюдән, башка авырулардан булыша торган төрле үләннәрнең хуш исе җыенысы бергә кушыла.







Бераз арырак кулдан тукылган келәмнәр кызыктыра. Гасырларны кичеп, төрекмән хатыннары келәм тукуның, киез басуның, милли чигешләрнең филигрань сәнгатен бүгенге көнгәчә китереп җиткерә алган. Келәм сата торган дуканда халык мыжлап тора. Күз явын алырлык бизәкле келәмнәрне мин хәтта Истанбулда да очратмадым. Ул төсләр балкышы, әкияти бизәкләр, геометрик күчешләр тәмам әсир итте. Келәм өчен йонны манганда, бары тик чын буяулар гына кулланалар ди! Келәмнәрнең шома йон өслекләре тотып карауга ефәк кебек тоела. Алар кулдан тукыла, бер келәмне әзерләү ике елга сузылырга мөмкин. Төсләр, бизәкләрнең катлаулылыгы, келәмнең үлчәме – барысы да исәпкә алына. Шушы туку эше белән шөгыльләнүче хатын-кызлар династияләре бар икән хәтта! Төрекмәнбашының яраткан үз осталары бар ди! Аларга Төрекмәнстанны дөнья базарында танытырлык затлы бүләкләр әзерләү вәкаләте тапшырыла. Келәмнәр арзан түгел, алар гаиләнең буыннан-буынга күчә торган кадерле ядкаре булып саклана ала.

Тукымалар кибетенә сугылсак, сатучылар анда яңа товар куеп ята икән. Милли бизәкле тукымаларга ихтыяҗ да зур. Игътибар иттем: барысы да чын йон-ефәктән, чын киҗе мамыктан. Мода яратучы төрекмән кызлары контраст бизәкләрне хуш күрә. Кара, кызыл, сары төсләр бик популяр анда. Түзмәдем, мин дә үзебезнең татар бизәкләрен хәтерләтүче тукыма сатып алдым – җәйгә күлмәк тегәчәкмен! Ахирәтләремә төрекмән хатын-кызлары бәйли торган бик модалы, матур бизәкле яулыклар алдым. Аларны төргәге белән саталар, өйдә кисеп, берничә яулыклы буласың. Бүләккә менә дигән! Чит-читләрен чуклап куйсаң да була әле.


Төрекмән хатын-кызлары ирләрнеке саналган һөнәрләрне дә үзләштергән. Алар менә дигән зәркән осталары. Күбесенчә затлы металл белән эшлиләр. Милли зәркән эшләнмәләре бик авыр. Алар аны ничек тагып йөридер – анысы табышмак менә! Кайберләренеке утызар килограммга ук җитә бит! Күбесенчә ул көмеш, кайчак бакыр була, асылташлардан, әлбәттә, якут, фирүзә өстенлек итә.

Ир-атлары ачык йөзле, шат күңелле. Кунакханәгә барыр өчен машина туктаткач, моңа тагын бер кат инандык. Сөйләшеп кайта-кайта, бензинның литры 18 сум (безнең акча белән) икәнен дә, бушлай бензинга лимит каралганын да, коммуналь түләүләрнең өлешчә бушлай булуын да, газ белән электрга түләмәгәннәрен дә белдек. Тоз да бушлай икән Төрекмәнстанда. Хезмәт хакы кечкенә дип зарлансалар да, аена уртача 30 мең (безнең акча белән!) чыга дигән җавапны ишеткәч, аптырап калдык. Безнең акчалар, коммуналь хезмәткә киткән түләүләр белән чагыштыра башласаң...

Төрекмәнстанда тел проблемасы юк кебек. Һәрхәлдә, Ашхабадта ул сизелмәде. 1948 елгы җир тетрәүдән соң шәһәрне торгызырга бик күп руслар килә һәм биредә урнашып кала. Шәһәр өр-яңадан төзелә. Һәр тарафта русча сөйләшкәннәре ишетелә. Кырын карауларны тоймадым. Күпләр совет чорын сагынып искә төшерә.

Әйтерсең, урта гасырлардагы Шәрык базарына килеп эләктек!

Кешеләрен ошатып кайттым Ашхабадның. Төрекмәннәр тырыш, булган, үз илләрен ярата торган халык. Аралашучан, ярдәмчел үзләре. Теләсә нинди соравыңны үтәргә әзерләр. Төрекмәнстан – ябык ил, болай гына барып чыгып булмый анда. Ялга барсаң гына инде... Интернет һәм яшьләрне җәлеп итәрлек башка төр әйберләр чикләнгән анда. Бәлки әле шуңа да һәрнәрсә белән кызыксыну, ихласлык, тормышны ярату бөркеләдер якты карашларыннан...



Видео һәм язманың тулы варианты – сайтыбызда.

PRESSA.RU

16+

ИР ДӘ ХАТЫНЫНА ИЛҺАМ БИРСЕН



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Илнар НИЗАМИЕВ,
Габдулла Кариев исемендәге
Татар яшьләр театры артисты,
Татарстанның атказанган артисты;
гаилә стажы – 18 ел;
Өч бала әтисе.

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Күзенә, әлбәттә. Хатын-кызның карашыннан барысын да аңлап була, минемчә. Ир-атны җәлеп итәргә, яраттырырга, үзенә бәйләп куярга күп вакыт аның шул бер карашы да җитә...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Күп сөйләшүен! Хатын-кызларның барысы да күп сөйләшергә ярата бугай. Кайвакыт, телләренә салынып, дөньяларын тәмам онытып җибәрәләр. Менә шул вакыт без – ир-атлар кирәк тә инде. «Булды, җитте инде!» – дип исенә төшерергә. «Соңга калабыз», «Эшеңне кара» дип әйтергә.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтен. Статистика мәгълүматларын тәгаен белмим, әмма күзәтүләремнән чыгып та әйтә алам: аерылышучы парлар бик күп хәзер. Сәбәпләрен заманга гына сылтау ялгыштыр. Шул сәбәпләрнең берсе булган хыянәткә дә бер-береңне китереп җиткермәскә кирәктер, миңа калса. Гаиләнең ныклыгы күбрәк ир-аттан тора. Хатын-кыз кызган вакытта акыллы ир-ат күп вакыт аңа юл бирә белергә тиештер. Сүрелгәч, хатының моның өчен сиңа рәхмәтле икәнен сиздермичә калмый. Телдән әйтмәсә дә, карашыннан, мөнәсәбәтеннән барыбер беленәчәк.

Савыт-саба шалтыратмыйча, тавыш-гаугасыз гына яшәүче гаиләләр барына мин бик үк ышанып бетмим. «Безнең беркайчан бер-беребезгә тавыш күтәргәнебез юк», – диючеләр, минемчә, чын дөресен сөйләми бугай. Тормыш ич бу! Бер үпкәләшеп яңадан татуланмагач та гаилә буламыни ул?! Үзара мөнәсәбәтләр шундый чакта ныгый төшә бит.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Илһамландыручы. Әгәр хатын-кыз илһамландыра икән, ир-ат таулар күчерергә дә сәләтле бит ул! Һәм, киресенчә, ир-ат та хатынын илһамландырырга тиештер. Гел: «Яратам!» сүзен кабатлап кына түгел (хатын-кыз колагы белән ярата диган гыйбарәне һәр ир-ат беләдер инде анысы. Тик барыбер бу сүзне без сирәгрәк әйтергә тиештер – тәмен, кадерен җуймас өчен булса да). Хатынының ярату кайвакыт, әйтик, аңа өй эшләрендә булышуың белән күренсен. Нәрсә өйрәтеп торам – мең юлы бар!
Ә гаиләдәге яшәү шартларын, уңайлыкларны ир-ат тудырырга тиеш. Менә шуннан комфорт килеп чыга инде. Шул комфортка җылылыкны исә, әлбәттә, хатын-кыз өсти...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Озак еллар бергә гомер иткәч, чын аерылмас дусларга әвереләсең икән ул. Менә без өйләнешкәнче 4-5 ел дус булып йөрдек. Тик ул вакыттагы дуслык белән хәзергесен чагыштыра торган да түгел. Беренди мәшәкатьләр булмаганда, берең – егет, икенчең кыз чакта дус булуның авырлыгы бармыни аның?! Гаилә коргач, тормыш баскач, мәхәббәтнең үзе кебек, ул тагын да кирәккә әйләнә. Бу вакыт ике арадагы дуслыкны югалту куркыныч та – гаилә таркалырга мөмкин хәтта.
Алла сакласын!

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– 1992 ел. Актерлык бүлегенә керергәме, әллә биюгәме дип, аптырап йөргән чак. Үлчәү тәлинкәсенә әле берсен, әле икенчесен салып карагач, актерлык бүлеген сайларга булдым. Имтиханнар бирәбез. Кызлар-егетләр кайсы шигырь сөйли, кайсы мәсәл укый. Шул вакыт бер шәһәр кызына (аның каланыкы икәнен соңрак белдем) игътибар иттем. Үзен шундый табигый тота! Күренеп тора – әзер актриса. Иң мөһиме – тәртипле, акыллы, тәрбияле... Гашыйк булганымны сизми дә калганмын... Икенче курста очраша башладык. Әмма безнең йөргәнне курсташлар соңгы курска кадәр белмәде. Хисләребез шулкадәр саф, чиста иде... Һәр бәйрәмгә бер-беребезгә бүләк бирешә идек без. Иң көтеп алган бәйрәм – 14 февраль. Гашыйк җаннар өчен Гашыйклар көненнән дә зур

бәйрәм була аламы?! Бүләк бирешү гадәте безнең гаиләдә хәзер дә бар: бер-беребезгә дә, балаларга да бирәбез.

...Укып бетергәч, безне курсыбыз белән эшкә Чаллыга чакырдылар. Биш кеше ике дә уйламыйча киттек. Ә Лилиянең иҗаты II курстан соң Камал театрында башланды. Беребез – Казан, икенчебез Чаллы сәхнәсендә төп рольләрдә уйнадык: Йосыф-Зөләйха, Исмәгыйль-Сәрвәр, Исмәгыйль-Галиябану... Аннан очраклы рәвештә генә абыйлар минем Лилия белән очрашып йөргәнне белделәр. Рәхмәт аларга: «Өйләнергә телисең икән, без каршы түгел, әнигә әйтәбез дә, туй итәбез», – дип, сүз башладылар. Үзем җөрьәт итмәс идем. Әйтергә генә җиңел: ике ел рәттән ике абый өйләнде, мин – өченче. Тормышлар да шактый авыр вакыт бит... Лилия, ризалыгын биреп, мине бәхетле итте. (Хәер, бергә буласыбызны без алдан ук белә идек!) Әнигә, төп йорттагы абый-апага рәхмәт – истә калырлык итеп бик матур туй ясадык. Ул чакта туйлар берничә көн уза иде әле.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Бу фикер белән килешмим. Әни бит берәү генә, аңа тиңләшерлек хатын-кыз башка юктыр... Әтиемне бөтенләй белмим: ул фаҗигале рәвештә вафат булганда мин әле өч айлык сабый гына булганмын. Әни, апа һәм абыйларым белән үстем. Ата тәрбиясен миңа абыйларым бирде. Хәер, алар гына да түгел... Хәзер дә бик еш кына уйлыйм: әни минем өчен кайвакыт әни генә түгел, әти дә була белде. Сигез бала белән тол калса да, берүзе безне аякка бастырды ул, һәммәбезне башлы-күзле итте. Авылда әнине үрнәк итеп сөйлиләр. Безнең гаилә өчен дә үрнәк ул. Мин кайчак Лилиягә: «Син менә моны дөрес эшләмисең бугай, әни безне болай тәрбияли иде», – дип әйткәлим. Әнинең әйткән сүзләре, биргән киңәшләре истән чыкмый...

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Һичшиксез, ир-ат малны күбрәк табу ягын кайгыртырга тиеш. Ир-атка эш бетмәгән! Хатын-кыз өйгә акчаны иренә караганда күбрәк алып кайта башласа, ул азына, ирен тыңламый, хөрмәт итми башлый. Мондый мөнәсәбәтләр исә гаиләне, иртәме-соңмы, барыбер тарката. Шуңа күрә, төрле сәбәпләр аркасында ире мал таба алмый икән, икәү бергә утырып сөйләшергә, моннан чыгу юлларын эзләргә кирәк. Югыйсә артык соң булуы бар.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Юк, хатын-кыз гашыйк булуын үзе башлап белдерергә тиеш түгел. Ул бу адымга бара икән, аның бөтен серлелеге югалачак, минемчә. Гүзәл затларыбыз шактый серле бит алар: шул серне аңларга, ачарга теләп тартылабыз да инде без аларга. Ә ир-ат үзенә карата булган игътибарны, бигрәк тә мәхәббәтне барыбер сизәчәк, барыбер аңлаячак.

10 Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Әчке дөньяма. Идеаль ир дә, идеаль хатын-кыз да була алмыйдыр дип уйлыйм. Синең плюсләреңне дә, барлык минусларыңны да хатын-кыз күрә, аңлый һәм кабул итә икән, димәк, сезнең тормышта барысы да әйбәт булачак.

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Мин көчле, матур хатын-кызларга сокланып карыйм. Ә менә куркырлык сәбәп тапмыйм. Шул соклануыңны күңел түренә салып куясың да, алга – яңа җиңүләргә таба атлыйсың.

12 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Ир кеше хатынының ниндидер сыйфатларга ия булуын тели (әмма теләүдән ары уза алмый!), ә хатын-кыз, һичшиксез, таләп итә.

13 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Мин хаклы икән – кабатлап әйтәм, үземне хаклы санасам, юл куярга тиеш түгел дип беләм. Андый очракта уртага салып сөйләшергә, яхшылап аңлатырга кирәк. Үтемле итеп аңлатсаң, хатын-кыз синең белән килешә ул. Әгәр инде алай да үз туксаны туксан икән... Ул чагында... Безгә – ирләргә «хатын-кыз һәрвакыт хаклы» дигән әйтемне онытмаска кирәк, миңа калса. «Ярый, синеңчә булсын», – дисең дә, үзеңнең барыбер хаклы икәнеңне соңрак аңлатасың.

14 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Сабыр итеп көтәм. Мин сабыр иткәч, хатын, әлбәттә, аш-су әзерләүне тизләтә. Әле шунда аз булса да ярдәм итеп тә җибәрсәң... Бу – хатын-кыз эше, ә монысы ир-атныкы, дип, вазыйфалар бүлешүне бигүк аңлап бетермим. Кулыңнан килсә-килмәсә дә, нигә кайвакыт пешермәскә, җыештырмаска, юмаска? Ир кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз дигән мәкаль нәрсә өчен?!

15 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан.

– Әйе, менә монысы дөрес. Килешәм, хатыннарыбыз бик озак әзерләнә. Һәм бу аларның, минемчә, иң зур минуслары. Ишетеп беләм – бик күп гаиләләрдә очрый торган хәл бу. Элек ачу да килгәли иде: гел көтеп торасы бик рәхәт түгел бит ул. Аннан бик җиңел генә җаен таптым: барасы җир булса, берничә сәгать алдан әзерләнә башлыйбыз. Эше бар икән – булышып җибәрәм: көттерергә сәбәп тә калмый.

16 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Ошамаган бүләкләр алганымны хәтерләмим әлегә. Һәрберсен шатланып кабул итәм. Хатын-кызның ир-атка иң зур бүләге барыбер бала инде ул. Чын ир-ат моны бәяли белергә тиеш. Миңа да Лилиям берсеннән-берсе матур өч бала бүләк итте. Нәсел шәҗәрәмне дәвам итүчеләрне. Моннан да зур бүләк була алмыйдыр, юктыр. Ә менә балаларга дөрес тәрбия бирү күбрәк ир-ат җилкәсендә булырга тиештер. Бигрәк тә ир балаларга ата кулы кирәк.

PRESSA.RU



45-50 яшьтә менопауза башлану хатын-кыз организмы өчен табигый хәл санала. Ләкин аның бик иртә – әйтик, 30 яшьтә башлану очрагы да булырга мөмкин. Нәрсәдән шулай була ул? Организмны мондый үзгәрешләргә нинди сәбәпләр этәрә? Хатын-кыз өчен ни дәрәҗәдә куркыныч бу халәт? Һәм иң мөһиме: нәрсә эшләргә мондый очракта? Бу сорауларны без ОНКОпрофи медицина клиникасына юлладык.

КЛИМАКС ЯШӘРӘ!

Сәбәбе

Климаксның беренче билгеләре, гадәттә, 45 яшьтән соң башлана. Ә инде аның билгеләре 30-35 яшьтә үк күренсә, хатын-кыз, һичшиксез, моның сәбәпләрен ачыкларга, иртә картаясы килмәсә, кичекмәстән чарасын күрергә тиеш. Аналык бизләренең организм өчен кирәкле эстрогеннар бүлеп чыгаруны киметүенең (шул исәптән, прогестерон һәм андроген) нәтиҗәсе әнә шундый.

Вакытыннан алда башланган климаксның сәбәпләре бик күп:

- аналык бизләре үз функциясен тиешенчә үтәми; нәселдән килү очраклары;
- эндокрин система чирләре;
- күкәйлекләр дискинезиясе;
- балага узмау;
- күп тапкырлар бала төшертүләр;
- аналык бизләренә операция;
- җенси хромосомалар санында тайпылышлар белән бәйле үзгәрешләр;
- оча сөягенең ялкынсынуы һәм имгәнүе;
- нурланыш һәм химиотерапия нәтиҗәләре;
- бәвел юлында яман шеш авырулары һәм башкалар.

Беренче билгеләре

Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- биткә кан йөгерә: әле эссе, әле салкын булып китә. Мондый вакытта кан басымы күтәрелергә дә мөмкин;
- тахикардия башлана;
- йокысызлык җәфалый яки киресенчә, бертуктаусыз йоклыйсы килә;
- баш авырта, баш әйләнә;
- эмоциональ тотрыксызлык күзәтелә: кәеф гел алышынып тора, депрессия, тиктомалдан ярсып китү ешая;
- интим җирдә үзгәрешләр (кычыту, бәвел тота алмау, җенси акт вакытында авырту) башлана;
- хәтер начарлана;
- чәч коелырга мөмкин.

Болары гына бер бәла. Иң яманы – ул сөякләргә «һөҗүм итә». Организмда эстроген җитәрлек булганда гына кальций сөякнең тыгызлыгы өчен җавап бирә, ә инде кими башласа, сөяк тә уалучанга әйләнә – ә бу остеопорозга китерә.

Аннары, эстрогенга кытлык булу сәбәпле, канда холестерин күбәя, ул баш мие һәм йөрәк эшчәнлегенә тискәре йогынты ясый. Атеросклероз шуннан килеп чыга да инде. Һәм соңгысы: кан тамырларының начар булуы нәтиҗәсендә, кан басымы күтәрелә, баш әйләнә. Инфаркт һәм инсультка китерүче сәбәпләр бу.

Иртә башланган климакс яман шеш авыруына да китерергә мөмкин. Шуңа күрә хатын-кызга елына кимендә бер мәртәбә маммография үтәргә; ярты елга бер мәртәбә гинекологка күренергә, денситометрия, ягъни сөякнең тыгызлыгын тикшерергә; рентгенография үтәргә; аналык

һәм аның тирәлеген, кан тамырлары системасын УЗИдан каратырга кирәк. Әлбәттә, диагнозны дөрес кую өчен канга гомуми һәм биохимик анализ, бәвелгә, аналык җиңсәсеннән бактериологик һәм бактериоскопик анализ ясатырга кирәк. Организмда эстроген күләмен билгеләү өчен ФСГ үтәргә, эстрадиол һәм прогестеронга да анализ алу комачауламас.

Яшәү рәвеше

Хатын-кыз үзенә карата бик игътибарлы булырга тиеш. Климакс үзен вакытыннан элек сиздерә башлый икән, шундук чарасын күрә башларга кирәк. Шул чагында сез иртә башланган менопаузаны гына туктатып калмыйча, җитди чирләрдән, иртә картаюдан да сакланып кала аласыз. Нинди дарулар эчәргә кирәклеген табиб диагностика үткәннән соң гына әйтә ала. Биредә төрле гормональ препаратлар кулланыла. Депрессиягә төшкән пациентка антидепрессантлар (бенактизин, гидроксизин, клобазам, феназепам һәм башка препаратлар) билгеләнә. Ә менә ничек яшәргә? Монысын инде һәркем үзе булдыра ала. Мисал өчен, күбрәк үсемлек продуктлары белән тукланырга, аксым һәм углевод күләмен мөмкин кадәр киметергә, терлек майларын, супермаркетларда сатыла торган консервантларны, тәмләткечләрне, ярымфабрикат продуктларын гомумән дә рационга кертмәскә, спорт белән шөгыльләнергә, туйганчы йокларга тырышыгыз. Симерүдән сакланыгыз! Спорт белән шөгыльләнү дә бик файдалы.

Витаминнар һәм минераль препаратлар

Мондый пациентларга остеопороз янауны күз алдында тотып, чирне кисәтү максатында витамин-минераль препаратлар тәкъдим итәләр. Аның нигезен бисфосфонатлар: фосамакс, памифос, бонефос, синд-ронат һәм башкалар тәшкил итә.

Кальций кушылмаларыннан торган препаратлар да бик файдалы.

Организмда фосфор-кальций алмашынуын көйләп торучы Д витаминыннан (аквадетрим, вигантол, альфадол, оксидевит) башка да булмый.

ХАТЫН-КЫЗ СӘЛАМӘТЛЕГЕНӘ КЛИМАКСНЫҢ НИНДИ КУРКЫНЫЧЫ БАР?

Климакс чорында хатын-кызларда була торган проблемалар күкәйлек функцияләренең зәгыйфьләнүе белән бәйле.



- **Авыруларның иң югары чиге: аналык миомасы, аналык муентыгында яман шеш, күкәйлектәге шешләр һәм башкалар**
- **Мускул һәм сеңерләрнең көчсезләнүе**
- **Бөерләр эшчәнлегенең сизелерлек кимүе**



ПРОФИЛАКТИКА ОНКОЛОГИЧЕСКИХ ЗАБОЛЕВАНИЙ

РЕКЛАМА

- Высококвалифицированная консультация онкодерматолога.
- Удаление родинок, папиллом, бородавок.
- **Ведущие профильные специалисты:**
- Маммолог • Уролог-онколог, уролог • Гинеколог, гинеколог-онколог • Проктолог • Эндокринолог-онколог • Хирург-онколог • ЛОР-онколог, ЛОР • Невролог • Терапевт • Пластический хирург.
- **Кабинет УЗИ экспертного класса.**
- **Лаборатория.**
- **Лечение эрозии шейки матки радиоволновым методом и методом криодеструкции.**

Казань, Сибирский тракт, 23; тел.: 8(843) 273-95-03.

Часы приема: пн.-пт. с 8.00 до 20.00; суббота: с 9.00 до 18.00; воскресенье – выходной.

Лицензия № ЛО-16-01-003675 от 16.09.201

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

ВНИМАНИЕ! АКЦИЯ! Подробности на сайте: **www.oncoprofi.ru**



СКИДКА НА ОНКОСКРИНИНГ ДО 15%!

Комплекс "Женский онкоскрининг"
- Консультация гинеколога, онколога-маммолога
- мазок на степень чистоты и онкоцитологию
- УЗИ органов малого таза и молочных желез
- Забор крови + анализ на онкомаркеры

4 777 ₽ вместо ~~5 210 ₽~~

Комплекс "Мужской онкоскрининг"
- Консультация онколога-уролога
- УЗИ предстательной железы (трансабдоминальное)
- Забор крови + анализ на онкомаркеры

2 777 ₽ вместо ~~3260 ₽~~

PRESSA.RU











«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.

Бу юлы мастер-классыбыз гадәти генә түгел. Максаты бик зур аның – Казандагы «Роналд Макдоналд йорты»нда яшәп, республика клиник хастаханәсендә каты авырудан дәваланучы балаларның азга гына булса да күңелләрен күтәреп, аларга бәйрәм ясау. Бу изге эшне оештыручылар – «Роналд Макдоналд йорты» директоры Юлия МАРКОВА белән «Рамада» отеленең «Американо» рестораны шеф-повары Илья ФРОЛОВ һәм без – «Сөембикә» журналы. «Роналд Макдоналд йортын»да мондый мастер-класслар даими булып тора. Иң кызыгы шунда: анда балалар үзләре дә катнаша. Илья, балалар сөенсен дип, тортны Микки Маус рәвешендә пешерде, ә балалар үзләре бизәде.

ЯҢА ЕЛ ТОРТЫ







Торт пешерү берничә этаптан тора. Беренче этапта бисквит әзерләнә (аны чикләвекле меренга яки даккуаз дип тә атыйлар).

Кирәк:

- 200 г шикәр комы;
- 6 йомырканың агы;
- 100 г миндаль оны (зур супермаркетлардан табарга мөмкин. Һичьюгы миндаль чикләвеген алып, аны кофе тарткычта тарттырырга була);
- 100-150 г цукат (без күрәгә һәм камыр ризыкларын бизи торган вак шарлар (посыпка) алдык). Цукатлар яратмасагыз, кушмаска да була.

Эш барышы:

■ йомырка агын кашык аумаслык булганчы күпертәбез, аннан шикәр комы, он һәм цукатлар кушып, сак кына туглыйбыз.

■ Гадәттә, даккуазны табага кашык белән салмыйлар, ә кондитер капчыгы ярдәмендә кысып чыгаралар.



■ Безгә диаметры 20 см булган 3 меренга, диаметры 12 см булган 6 меренга кирәк булачак. Моның өчен коры табага җәелгән пергамент кәгазенә карандаш белән кирәкле диаметрны сызып, камырны шуның чикләреннән чыгармыйча гына салып чыгабыз да 120 градус кызулыктагы мичтә 1 сәгать чамасы пешерәбез. Пешереп бетерергә 10 минут кала, мичнең капкачын бераз ачып куярга кирәк.

Корж араларына сылар һәм торт өстенә ягар өчен ике төрле крем кирәк булачак. Беренчесе – пешерелгән (заварной) крем.

Кирәк:

- 4 йомырканың сарысы;
- 100 г шикәр комы;
- 35 г кукуруз крахмалы (бер аш кашыгына 10 г крахмал керә);
- 40 г он;
- 0,5 л сөт;
- бер чеметем ванилин.

Эш барышы:

■ Сөтне кайнатырга куябыз. Йомырка сарысына шикәр комы, он, крахмал, ванилин кушып, яхшылап туглыйбыз да аз-азлап кына кайнаган сөткә салып, бик ныгытып болгатабыз. Сөт кабат кайнап чыккач, уттан алып кремны суытабыз.

Ә хәзер инде чиз-крем әзерлибез.

Кирәк:

- 150 г куе каймак (майлылыгы 33%);
- 300 г эремчекле сыр ("Филадельфия" дигәне әйбәт);
- 300 г пешерелгән крем.

Эш барышы:

■ Каймакны блендер белән күпертеп (яхшы сыйфатлы атланмай да ярый, шулай да каймак яхшырак), аңа кашык белән азлап-азлап кына эремчекле сыр кушып болгатабыз. Ахырдан пешерелгән крем кушабыз.

Тортны җыю.

■ Тортны матур итеп җыю өчен безгә диаметрлары 20 см һәм 12 см булган түгәрәк формалар кирәк (төбе һәм капкачы юк). Аны өйдә кулдан гына ясап була. Моның өчен катырак полиэтиленнан ясалган папка да ярый. Папкадан озынлыгы форма диаметрыннан чак кына зуррак, биеклеге 10-15 см булган турыпочмаклык кисеп алып, боҗралап бөгәбез дә, очларын скрепка белән кыстырабыз.

■ Форманың зуррагына 20 см диаметрлы коржны салып, өстенә чизкрем сылыйбыз. Өч коржны да шулай, крем белән чиратлаштырып, берсе өстенә икенчесен куябыз. Иң өскә крем сылыйбыз. Кечкенә формалар 12 сантиметрлы коржлар өчен. Аларны да нәкъ шулай ук катлыкатлы итеп тезәбез.

■ Коржларның зуры – Миккиның башы, кечкенә коржлар колаклары булачак. Формаларны алып, «колак» дигәннәренең бер читеннән 3-4 см эчкәрәк кереп, турысызык буенча кыеп алабыз. «Колакларны» «башка» терәтеп куябыз.

■ Тортны бизәү өчен 150 г каймакны күпертеп (майлылыгы 33%), 50 г шикәр комы кушабыз. Шикәр каймакта эреп бетәргә тиеш. Шикәр оны куллансаң да була. Шикәрле каймакка 1-2 аш кашыгы пешкән крем кушабыз (каймак формасын сакласын өчен кирәк). Әзер кремны 4 өлешкә бүлеп, берсенә – кызыл, берсенә – яшел, берсенә – сары, берсенә шәмәхә ризык буявы салып болгатабыз. Дүрт төскә буяу мәҗбүри түгел. Буяу булмаса, кремны ак килеш кенә дә калдырырга мөмкин. Буяу матурлык өчен генә.

■ Буяулы кремны кондитер капчыгына салып, тортның өстен бизибез. Капчык «борынына» кигертү өчен төрле диаметрлы махсус җайланмалар сатыла кибетләрдә. Кечкенә диаметрлысы белән тортның читен каймалап чыгып, зуррагы белән чәчәкләр, бормалар ясыйбыз. Бизәү эше һәркемнең үз фантазиясенә бәйле. Без тортның өстен ваклап туралган җиләк белән дә бизәдек.

PRESSA.RU

Бу юлы, уйладык-уйладык та, матур да, гади дә, кирәкле дә дип, укучыларыбызны әтәч-тоткыч тегәргә өйрәтергә булдык. Яңа елда бүләк бирешү гадәте бар, ә 2017 ел – Әтәч елы. Дус кызларыгызга, әниләрегезгә Яңа ел символы да булган шушындый матур тоткычлар тегеп бүләк итсәгез, алар куанырлар иде. Боларны кухняга матурлык өчен генә элеп куйсаң да бүлмәгә бертөрле ямь кереп китә. Мастер-классны исә журнал укучыларыбызга инде алдагы саныбыздан таныш Гөлназ ГЫЙБАДУЛЛИНА үткәрә.






ӘТӘЧ КИЛЕР ЯРДӘМГӘ

Кирәк:

- 1 пар тоткыч тегү өчен иңе – 80 см, буе 50 см булган ситсы тукыма (аны төп тукыма дип атарбыз);
- аскы якка куяр өчен иңе – 80 см, буе 26 см җитен тукыма (ситсы да ярый, әмма җитен чыдамрак, тиз генә тузмый);
- эчкә куеп калдыру өчен иңе – 80 см, буе 50 см булган ватин (синтепон ярамый, ул кайнарга чыдамсыз); каймалар өчен 3 м кыйгач тасма (косая бейка);
- канат, кикрик, сакал ясар өчен иңе – 8-10 см, буе 40 см чамасы булган кызыл төстәге фетр (калынрак башка төрле тукымада да ярый);
- томшык өчен саргылт яки кызгылт тукыма кисәге (5 см җитә);
- күзләр өчен 4 төймә;
- элмәк ясар өчен тар гына тасма.





Эш тәртибе:

■ Өлгеләрне кәгазьгә аерым-аерым итеп күчереп алырга һәм каләм эзеннән кисәргә.

■ Тоткычның өске ягы булачак төп тукыманы үтүкләп, урталай бөкләргә һәм өске якның өлгесен куеп («башлысы»), акбур белән эзен төшереп алырга. Кискәндә тегү өчен кырыйдан 1 см ара калдырырга. Бу – бер тоткычның уң ягы гына булды, сул ягын да нәкъ шулай кисәргә кирәк.

■ Җитен тукыманы урталай бөкләргә һәм аскы якның өлгесен салып (өске як өлгесенең гәүдә өлеше), эзен төшерергә, 1 см тегү өлеше калдырып кисәргә. Бер тоткычка аскы өлешләр икәү кирәк.

■ Ватинны өстәлгә җәеп, шулай ук урталай бөклибез һәм аскы өлешнең өлгесе белән – бер, өске өлешнеке белән 2 кисәк кисәбез.

■ Бу мөһим: ватинны кискәндә тегү өлешләре калдырылмый!

■ Кызыл фетрдан 2 кикрик, 4 канат, 2 сакал кисәбез. Саргылт тукымадан зурлыгы 2,5 см булган 2 шакмак кисәргә кирәк булыр.

Тоткычны җыю:

■ Төп тукымадан киселгән уң як өлешнең эчке ягына ватин тыгып калдырып, кырыйдан машина белән җөй салабыз. Җөй тукыма кырыеннан 0,5 см эчкә кереп салына. Тегеп бетергәч, тегү өчен калдырылган араны җөйдән 2-3 мм гына калдырып, кайчы белән кисеп тарайтабыз. Инде сул як өлешне дә шулай ук тегәсе була.

■ Кызыл канатларның тегеләсе урынын билгеләп, аларны тар зигзаг җөй белән тукыма өсләтеп кенә тегеп куябыз (аппликация салу). Теккәндә, урыныннан күчмәсен өчен, энәләр белән чәнчеп торырга була. Канатлар уң як өлешкә дә, сул як өлешкә дә тегелә.

■ Бу мөһим: уң як белән сул як өлешләрне бер-берсенә каплагач, канатлар тышкы якта калырлык булсын!

■ Төп тукымадан тегелгән өлешләрнең өске чите буйлап кыйгач тасма тегәбез («муен астыннан» «койрык очына» кадәр). Тегү тәртибе болайрак: кыйгач тасманың читен детальнең сул ягыннан машина җөе белән тегеп тоташтырабыз. Җөй тукыма кырыеннан 0,5 см эчкәрәк кереп салына. Артыграк чыгып калган өлешен кайчы белән кисеп ташлыйбыз. Тасманың икенче читен төп детальнең уң ягына кайтарып бөкләп, уң яктан тагын бер җөй салабыз. Бу юлы инде эчкә таба 0,5 см керәбез.

■ Бу мөһим: Тасманы «баш түбәсенә» теккәндә, аны машина табаны астына аз-аз гына этеп кертеп, бәләкәй генә бөкләмнәр ясап калдырабыз. Ә «канат өсте» кырыен теккәндә, киресенчә, тасманы чак кына тарта төшәбез.

■ Аслыкка дигән җитен өлешләрне уң яклары белән тышка каратып салып, уртасына ватин кыстырып калдырабыз да, төп өлешне теккәндәге кебек, кырыйдан 0,5 см кереп, машина җөе салабыз. Артып калган өлешне кисеп тарайтабыз.

■ Әзер аслыкка төп тукымадан тегелгән уң һәм сул якларны салып, кырыйларын тигезлибез. Урыныннан күчмәсенгә энәләр белән чәнчеп торып, кырыйдан кыйгач тасма тегеп чыгабыз. Тасманы «муен астыннан» тегә башлыйбыз. Тасма очын 0,5 см бөкләп, эчкә тыгып калдырабыз. Тасманың баш-башлары «муен астында» очраша. Икенче очын да шулай ук 0,5 см эчкә бөкләп калдырабыз. Җепне кисеп, төенлибез.

■ Инде «кикрик», «сакал», «томшык» тегәсе калды. Аларны тиешле урынга энә белән беркетеп, кыйгач тасма тегелгән җөй эзеннән машина белән тегеп куябыз. «Күзләр» урынына кечкенә төймәләр тегелә.

■ «Койрык» очына тар тасмадан элмәк тегәбез. Анысы инде эчке якка кулдан гына тегеп беркетелә. Менә бит, тырышкач, булдырдык!

PRESSA.RU

КЫЗЫЛ, ЧАЯ, ЮМАРТ... ӘТӘЧ



Фото: Олеся Чегаева

Менә тагын бер елны озатабыз. Алда – 2017 ел – Әтәч елы. Аны әле Кызыл Әтәч дип тә атыйлар. Алдагы ел нинди булыр, әтәчтән нәрсәләр көтәсе икән безгә? Маймыл – маймылланырга яраткан булса, Әтәч әтәчләнеп күрсәтәчәкме?

Әтәч – таң кошы, башкаларның да йоклап ятканын өнәми. Өстәвенә, ул үзен зур хуҗа итеп тоярга ярата. 2017 ел тырыш, уңганнар өчен үсеш елы булачак. Аның гел игътибар үзәгендә булырга яратуы да сер түгел. Үз холкына туры килүчеләргә ел хуҗасы хәерхаһлы булыр.

Ул көтелмәгән сюрпризлар ясарга ярата, аларына да әзер булып торыйк (хәер, без андый нәрсәләргә күптән иярләнгән инде!). Көязлеге һәркемгә дә мәгълүм. Аның күңелен күрер өчен үзебезгә дә бераз көязләнеп алу комачауламас.

Әтәч – теләсә кайдан үзенә-үзе ризык таба торган тырыш кош. Юмартлыгы да бар (тапкан ризыгын ул һәрвакыт якыннары белән бүлешә). Әтәчнең бу сыйфатлары ел дәвамында үзен сиздереп торачак, шулай булгач, алдагы ел шактый ук уңышлы, юмарт, игелекле ел булыр кебек тоела. Ул әле максатчан җан иясе дә – үз дигәненнән нык торучыларга ул ярдәм итми калмас.

Йолдызбагарлар сүзенә ышансаң, Әтәч – яңарыш символы икән. Шуңа да киләсе елда һәркемнең тормышында ниндидер яңалык, үзгәреш булыр. Үзгәрешләргә беркем дә каршы түгел, алар фәкать яхшы үзгәрешләр генә була күрсен. Илдәге, дөньядагы вазгыять тә бераз үзгәреш кичерәчәк, имеш.

Әтәч елын каршылыйбыз

Әтәчнең ялгызлыкны сөймәвен, йорт җанлы булуын һәркем белә. Шуңа да бу елны өйдә, гаилә, якын дуслар белән каршы алырга кирәк. Әгәр дә каядыр барасыз икән, фәкать гаилә белән генә! Аеры-чөере йөрүне Әтәч һич өнәми.

Кием мәсьәләсенә килгәндә, узган елдагы кебек, быел да төп төс – кызыл төс. Кып-кызылны ук киясегез килмәсә, аның башка төсмерләрен – алсу, куе кызыл, чия төсен сайларга була. Сары һәм әфлисун төсләре дә килешә.

Яңа елга нәрсә әзерлик диючеләргә – быел тулы ирек. Ит ризыклары, төрле салатлар, балык – болары да Әтәчнең яраткан сые. Йолдызбагарлар фаразынча, имеш, табынга ит белән балыкны янәшә куйсаң, ел бик уңышлы килеп, рәхәттә узачак икән. Шулай ук табын уртасындагы вазага өелгән җиләк-җимеш тә муллык юрый ди.

Табын бизибез

Узган елдагыча, бу Яңа елның да билгесе – ут. Эреле-ваклы шәмнәр, кызыл төстәге шарлар, вазалар, шәмдәлләр, тастымаллар – болар барысы быел да актуаль. Артык чуарлык белән генә мавыгырга кирәкмәс. Әтәч матурлык һәм затлылык ярата. Яраткан ризыкларыгызны кызыл төстәге вак помидор, кызыл уылдык яки анар төшләре белән бизәргә мөмкин. Бу да Әтәчнең күңелен күтәрәчәк икән.


Кучкар. Яхшы, уңышлы, иҗади ел килә. Эше дә, әҗере дә, хөрмәте дә тиешенчә булыр. Каршылыклар булса да, сез аны тиз һәм җиңел хәл итәчәксез. Өстәвенә, алар сезне тагын да көчлерәк кенә итәр.


Үгезбозау. Быел иң уңышлы кешеләрнең берсе булырсыз. Моны инде гыйнвар башында ук тоярсыз. Моңарчы уегызга да кереп карамаган файдалы тәкъдим (ул яңа эшкә чакыру да булырга мөмкин) алырсыз.


Игезәкләр. Эш-мәшәкатьләрнең барысын да иске елда төгәлләп бетерү өчен көчегез дә, мөмкинлегегез дә җитәрлек. Бүгенге эшне иртәгәгә калдырмасагыз, бик күп нәрсәгә ирешәчәксез. 2017 ел күңелле вакыйгалар белән истә калачак.


Кысла. Үзегезне шәхес итеп тә, кайгыртучан туган итеп тә, башка күркәм сыйфатлар да күрсәтә алырсыз. Күпләр сезне яңача бәяли башлар.


Арыслан. Уңышка ирешү өчен бераз сабырлык кирәк булыр. 2017 ел сезнең өчен дә уңышлы булачак. Яңа эшкә күчү, фатир алыштыру, тормышыгызга үзгәреш кертү ихтималы зур. Дөрес, үзегезгә дә бик тырышырга туры килер.


Сөмбелә. Тормышыгызда көтелмәгән җиңеллек тоярсыз. Үтеп баручы ел сезнең өчен киеренке булды, яңа елдан хезмәтләрегезне күрә башларлар. Моңарчы тәнкыйтьләп торучылар хәзер инде мактауга күчәр.


Бизмән. Елның беренче яртысы төрле кичектергесез мәсьәләләрне хәл итеп үтәр. Тәвәккәллек һәм үҗәтлек кирәк булачак. Каршылыклар алдында бирешмәсәгез, елның икенче яртысында дәрәҗәгез дә, keremegez дә сизелерлек артачак.


Чаян. Иң кыю идеяләрегезне тормышка ашыру форсаты туар. Тормышыгызга үзгәрешләр кертү өчен уңай ел. Күңел сизгерлегегез гаҗәеп булыр, үз-үзегезгә ышаныгыз.


Укчы. Ниһаять, күңел тынычлыгына ирешерсез, гади генә нәрсәләрдән дә куаныч табарсыз. Борчулар үткән елда калыр. Аз гына тәвәккәллек һәм үҗәтлек күрсәтсәгез, әллә нинди уңышларга ирешерсез.


Кәҗәмөгез. Үзгәрешләр елы. Ул җисми тормышта гына түгел, уй-фикерләрдә, үзара мөнәсәбәтләрдә дә чагылыр. Киләсе ел көтелмәгән күңелле вакыйгалар белән исегездә калачак. Быел әҗәткә зур акчалар алмый торуыгыз хәерле.


Сукояр. Ачыш елы булыр бу сезнең өчен. Моңарчы кичермәгән хисләр, үзегездә барлыгын да белмәгән сәләт, зур мөмкинлекләр ачарсыз. Күңел тоемыгыз искиткеч, үзегезгә ышаныгыз. Башкалар сүзе белән йөрсәгез, хаталанырсыз.


Балык. Барлык сәләтегезне, көчегезне кулланырга туры киләчәк. Уңышлы ел булса да, мәшәкате дә булыр. Тормышыгызны үзгәртергә теләсәгез, язмыш кулай форсатын да чыгарачак. Элек тотынырга кыймаган эшкә алынсагыз, ахыры яхшы тәмамланыр.

Татарстан | *Россия* | *Чит илләр* | ***декабрь*** *дә кабынган йолдызлар*



Фәһимә Хисамова (1.12.1936) – **тел галиме, профессор. Татарстанның атказанган укытучысы, атказанган фән эшлеклесе.**

Ютазы районы Кәрәкәшле авылыннан. 1955 елда Казан дәүләт университетына укырга керә. 1967–1970 елларда аспирантурада укый. Җитәкчесе – профессор Диләрә Тумашева. Бу вакытта Фәһимә ханым инде өч бала анасы була. Балалар үстерү белән кандидатлык диссертациясен язуны бергә алып барырга туры килә. Әлбәттә, фәнни уңышларында ире – күренекле галим Нурмөхәммәт Хисамовның да ярдәме зур. 1995 елда ул инде докторлык диссертациясен яклый. 1998 елдан – университетта профессор. 1999–2007 елларда КДУның (хәзерге КФУ) татар филологиясе һәм тарих факультетында татар теле кафедрасы мөдире була.



Клара Новикова (12.12.1946) – **Россиянең халык артисты, юмор остасы.**

Киевта туа. Мәктәптә укыганда ук комик рольләрне бик шәп башкара торган була. Туган шәһәрендә эстрада-цирк сәнгате студиясен тәмамлап, Мәскәүгә килә, ГИТИСта укый. Эстрадада беренче адымын 1974 елда ясый – эстрада артистларының Бөтенсоюз конкурсында катнашып, Аркадий Райкин кулыннан приз ала. 1976 елда «Москонцерт» оешмасында эшли башлый. 1992 елдан – миниатюралар театрында. Танылу аңа «Аншлаг» тапшыруы аша килә. Хәзер Клара Новикованың «Тетя Соня»сын белмәгән кеше сирәктер.



Патрисия Каас (5.12.1966) – **танылган җырчы һәм артист.**

Дөньядагы иң популяр җырчыларның берсе. 1988 елда «Мадемуазель блюз җырлый» дип аталган беренче альбомы чыкканнан соң, аның җырлары дөнья буйлап таралып, альбомнары 17 миллионлык тираж белән сатыла. Патрисия күп балалы шахтер гаиләсендә туа. Алман милләтеннән булган әниләре аны кечкенәдән җыр дәресләренә йөртә. Аның тавышын Эдит Пиаф, Марлен Дитрихныкына охшаталар. Җырчы карьерасын кыз 13 яшендә үк башлый. 1985 елда аны актер Жерар Депардье күреп алып, җырлар язучы Франсуа Бернхейм белән таныштыра. Патрисиянең беренче пластинкасы да Депардье акчасына яздырыла. 1990 елда ул дөнья буйлап беренче гастролен оештыра. Дөньяның 12 илендә 196 концерт куя. Берничә тапкыр Россиягә дә килә, русча да җырларга өйрәнә. 2010 елда ул Мәскәүдә – Кремльнең концертлар залында чыгыш ясый, бу концертны Россия телевидениесенең Беренче каналы бөтен илгә күрсәтә.

Ноябрь саныбызда гемологның телефон номеры ялгыш күрсәтелде.
Язылу һәм консультация өчен – тел.: +7 (919) 689-44-29 (эксперт-геммолог Регина)

PRESSA.RU

Асия ЮНЫСОВА

ҺӘР ЯҢА ЕЛДАН АДӘМ БАЛАСЫ МОГҖИЗА КӨТӘ. КЫЗЛАР ХАЛКЫ БИГРӘК ТӘ...

ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК

Разия, Сафия, Тәнзилә – өч ахирәт Яңа елны өчәү генә каршыладылар. Сәгать телләре төнге 12 дә кушылганда шампан шәрабы да эчеп куйдылар. Тылсымлы мизгелләр иде бу ел алыштырган секундлар. Курантларның тантаналы музыкасы басылганчы кызлар тып-тын тордылар. Тынлыкны беренче булып Тәнзилә бозды: «Кызлар, күрегез дә торыгыз, мин быел кияүгә чыгам. Шампан йотканда сез ни теләгәнсездер, ә мин быел ялгызлыкка нокта куям. Минем теләгем шул!»

Калган ике кыз ахирәтләренең тәвәккәллеген беләләр. Әнә, бу юлы да бит оялып, сырланып тормады. Максатын – ие шул, теләк булудан узып, максат булган иде бугай инде бу кияүле булу нияте – ярды да салды. Хәзер инде ул шул максатының колы. Ярылса да, ирешәчәк ул аңа!

Кызлар җанланып китеп, көлешеп алдылар. Алда торган туй аларны да кызыктыра. «Чур, беребезне дә туйдан калдырмыйсың! – диде садә күңелле Сафия. «Синә ышансаң, мыштым гына никахлашып куярсың әле», – дип өстәде һәрвакыт шикләнүчән Разия. «Кызлар, туйның уртасында булырсыз. Сездән якын кемем бар минем», – диде, дусларының шиген таратып, Тәнзилә. – Әйдәгез, кинолардагы кебек, урамга чыгып, кияү аулап керәбез!»

– Тезеп куйганнар, ди, анда кияү егетләрен. Булганнарын ычкындырмагыз. Егетләрегез бар бит инде. Ник дип чакырмагансыздыр, бергә-бергә миңа да күңелле булыр иде. Берәрсе иптәш егетен ияртеп килмәс идеме әле. Дус булган



булып йөрисез, ахирәтегезгә бер егет табып бирә белмисез, – дигән булып, назлы гына итеп үпкәсен белдерде сөйкемле сөяк Сафия. – Үзләре генә кияүгә чыгасылар...»

Тәнзиләнең Салихы бар инде анысы. Тик быел ук өйләнер микән әле егет? Әтиләре янгыннан соң өй җиткереп йөри. Аларда туй кайгысы түгел. Дөрес, Тәнзилә кайнана өенә сыя торган килен булмас. Районда дәрәҗәсе дә бар – эше шундый. Мөгаен, берәр почмак юнәтер. Хәзер кызлар да «өй»ләнә. Башлыкүзле булуны өйләнешү дип әйтүдә хаклык зур инде анысы.

Инде ел да үтеп бара. Тәнзилә белән Салих туе турында хәбәр-хәтер ишетелми. Аралары да бозылып тора бугай. Салихны районга эшкә кайткан зоотехник кыз бик ошата икән, диләр. Салих та битараф булмаса, хәлләр катлауланыр кебек. Ул имеш-мимешләр, әлбәттә, Тәнзиләгә дә ирешкән. Алай да ул әле ахирәтләренә сер бирми йөри. «Кызлар, була туй. Әзерләнеп торыгыз!» Алда торган Яңа ел бәйрәмендә Тәнзилә Хәялигә кияүгә чыга икән, Хәяли Тәнзиләгә өйләнә икән, дигән яңалык район үзәген урап узды. Көне, сәгате билгеле!

Туй буласы көнне кызлар бергә иделәр. Килен булып төшәсе кәләш идәндә ауный-тәгәри елый. Сәбәбен дә әйтми. Хәер, сәбәбе дә тиздән мәгълүм булды: Тәнзиләнең кияүгә җыенуын ишеткән Салих та тиз генә теге зоотехник кызга өйләнеп куйган икән. Авылларына кайтканнар да язылышып килгәннәр. Тәнзилә «гаепләләрне» бик тиз ачыклаган: үзенең әти-әнисе гөнаһлы икән ләбаса. Салих, Тәнзиләне ычкындырмас өчен, кыз сорарга яучы җибәргәч, бу бичаралар яучыга, без кызыбызны вәгъдәләштек инде, бер кызны каткат бирә алмыйбыз, дип калганнар. Алар Тәнзиләнең озак уйланып йөргән егетенә ятьмә корганын, ягъни кызлар хәйләсен каян белсен соң?!

Ике туй да уйналды. Ике бәхетсез гаилә корылды. Тәнзиләнең Хәялие кәләш кочагына керә алмыйча бер ел йөдәгәч, аерылды. Салихлар гаиләсе бер баланы ятим итеп, ике елдан таркалды. Әмма Салих Тәнзиләне гафу итә алмады, күрәсең. Буйдак булып йөрде-йөрде дә Себер ягына эшкә китеп барды. Хәяли, яшь гомерен аны уйлап, төннәрен йокламый саргайган Хәкимә белән кавышты. Гаҗәп матур торалар ди.

Аннан соң әллә ничә Яңа ел Җиргә килеп китте инде. Тәнзилә дә бәби табар яшьтән узып бара. Бәбиен генә түгел, тиңен дә таба алмады бугай. Яшь чактагы каты күңелле, тәвәккәл Тәнзилә түгел инде ул. Ләкин аның бу сыйфат үзгәрешләрен бәяли белерлек егетләр барысы да өйләнеп беткән шул инде.

сөембикә

ИЮЛЬ

Д		3	10	17	24	31
С		4	11	18	25	
Ч		5	12	19	26	
П		6	13	20	27	
Җ		7	14	21	28	
Ш	1	8	15	22	29	
Я	2	9	16	23	30	

АВГУСТ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	29
Ч	2	9	16	23	30
П	3	10	17	24	31
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

СЕНТЯБРЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	

ОКТЯБРЬ

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

НОЯБРЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

ДЕКАБРЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31

Татарстан Республикасында язылу индексы: П2204
Россия Федерациясендә: 73002
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

Язык һәм телевизор от!

1 Языл
30.12.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!



БҮЛӘКЛӘР
2017 елның 17 февралендә
УЙНАТЫЛАЧАК





Акцияне үткәрү вакыты: 20.10.2016 - 20.03.2017

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама